Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 12 (1428) 31 март 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

2

Милли һөнәрчелекне үстерүгә күп тырышлык салынса да, хәлләр чуртан, кысла, аккош арбасын хәтерләтә.

8

Татар милләте өчен өч тапкыр ачлык тоткан Айдар Хәлим телне саклап калу мәсьәләсенең бүген генә калкып чыкмавына басым ясый.

12

Бер булганнан бар да була – бу сүзләр каллиграф, мөгаллим Рамил Насыйбуллов-ка бик туры килә.

Сез тел аша иман иңдерәсез, Ана теле мөгаллимнәре!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов указы белән 2023 елда Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен үткәрү көннәре (21 апрель һәм 28 июнь) билгеләнде.

- Татарстанда «Ел укытучысы» исеменә быел Иннополис лицеенда математика укытучысы Арман Костанян лаек булды.

- КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтына караган Рус һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбендә киносценаристларны әзерләү буенча магистрлык программасы ачыла.

- Чистай шәһәрендә күренекле галимнәр, язучылар катнашында Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган XI республикакүләм фәнни-гамәли конференция узды.

- Бөтендөнья татар конгрессы Татарстаннан читтә нәшер ителә торган татар телле газеталар, эфирга чыга торган теле-радиотапшырулар редакцияләре һәм журналистлары арасында «Хәбәр» конкурсын башлап җибәрде.

- Саба гимназиясе базасында күренекле татар галиме, Г.Тукай бүләге лауреаты Әбрар Кәримуллин исемендәге VII республикакүләм фәнни-гамәли конференция үтте.

- Түбәннән Ялутор шәһәрендә гөрләтеп татар мәдәнияте көннәре оештырылды.

- Свердловск өлкәсенең Әҗегол авылы мәдәният йортында өлкәнең татар компонентлы белем бирү учреждениеләре арасында «Театрда кунакта» театр коллективлары фестиваль-бәйгесе узды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Дәүләт Советы депутаты:

«Без бит «Туган тел»не җырлаганда, бөтен тарихыбызны күз алдына китерәбез. Һәйкәлгә карагач та, без халкыбызның үткән юлын күз алдына китерергә тиеш. Күңелдә горурлык хисе уянырга тиеш. Бу инде фигуралар бастырып кую гына түгел. Монда киң масштаблы философ рәссам-скульпторлар кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

Март азагында кар тиз эресә һәм гөрләвекләр акса, яңгырлы җәй көтелә ● 1 апрельдә көн нинди булса, 1 октябрьдә дә шундый булачак ● 4 апрельдә кояш җылытса, мул уңыш көтелә ● 5 апрель төне җылы булса, яз дәррәү килә ● Тау итәкләрендә үги ана яфрагы иртә чәчәк атса, апрельдә җылыта ● Яз иртә килсә, ташу көчле була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 19 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 18 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 59 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **7 апрельдә 13 сәгать 31 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

1 апрель – шагыйрь, журналист Мөнир Хәсән улы Мазуновның тууына 105 ел (1918–1987);

– солист, инструменталист, Татарстанның атказанган артисты Альберт Ганс улы Сәйфуллинга 55 яшь (1968).

5 апрель – шагыйрь Рамазан Муллагали улы Байтимеровның тууына 100 ел (1923–1989);

– актер, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Равил Шиһап улы Шәрәфиевкә 85 яшь (1938);

– рәссам-проектлаучы Рәшит Лотфулла улы Фәттаховка 70 яшь (1953);

– журналист, продюсер, тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Миләүшә Ләбиб кызы Айтугановага 60 яшь (1963).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Март-апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 31 март, 1 апрель.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(29 март-6 апрель)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 9 нчы көне

ЭШЛЕКЛЕ МӘҖЛЕС

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА

ӨЧ КҮЛМӘК ТЕГӘСЕЗ ДӘ... *яки* Милли һөнәрләрне ничек сакларга?

Глобальләшү заманында татар милли гамәли-бизәү сәнгатен ничек саклап калырга, халык һөнәрчелегенә ни рәвешле җан өрергә? Бу хакта Татарстан Рәисе каршындагы мәдәният һәм сәнгать шурасының чираттагы утырышында сөйләштеләр.

Башта Р.Миңнеханов сүз алып, халык һөнәрчелеге өлкәсендә бүгенге вәзгыять турында сөйләп китте. Илбашы утырышка Казан Кремленең җәмәгать урыннарында оештырылган зур халык гамәли бизәү сәнгате күргәзмәсен карап, андагы осталар белән аралашып килде, шуңа күрә сөйләгәндә бик тәэсирләнгәне, һәр сүзенең йөрәгеннән чыкканы сизелә иде. Мәсәлән, ул республикабызда халык һөнәрчелеге тармагында 1,5 мең кече һәм урта бизнес субъекты була торып та, рәсми мәгълүматларга караганда, шуларның кырык берсенең генә халык һөнәрчеләре буларак теркәлүе, үвеченең социаль предприятие статусын алуы җәһәтеннән борчылуын белдерде. Күпчелеге исә рәсми теркәлмичә генә эшли дигән сүз. Дөресрәге, сәнгать эшләнмәләре ясаса да, йә аяк киеме сипләүчеләр, яисә белем бирүче оешма буларак теркәлгән. Шуңа күрә күпчелек һөнәрчеләр продукциясенең сәнгати кыйммәтен тикшереп бару бик кыен. Халык һөнәрчелеге буларак теркәлмәгәч, бу осталар дәүләт ярдәменнән дә коры кала, мәсәлән, иң яхшы халык һөнәрчеләре эшләнмәләре өчен 2013 елдан бирле кертелгән грантка дәгъва кыла алмый.

Республикабыз җитәкчесе Р.Миңнеханов эшләүдән туктаган Арча милли аяк киеме, Казан музыка уен кораллары фабрикаларын искә төшереп уфтанды. Кукмара киез итек комбинатын, Алексеевский туку фабрикасын уңай мисал буларак телгә алды.

Республикабызда гамәли-бизәү сәнгатен торгизү өчен шартлар да бар кебек. 2021 елдан бирле, мәсәлән, «Ел һөнәрчесе» бәйгесе үткәрелә. Быелтыр 22 оста конкурста төрле дәрәҗәдәге бүләкләргә ия булды. Ике ел рәттән республикабызның Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы ярдәме белән «Яшәү стиле – мәдәни код» фестивале үткәрелде, бөтен Россиядән модельер, дизайнерлар килеп, борынгыдан килгән милли һөнәрләрне бүгенге көндә терелтү турында фикер алышты, үзләренең коллекцияләре белән таныштырды. «Шулай да халык һөнәрләребез үсә, чәчәк ата, дип мактана алабызмы?» – дип илбашы республикабызның мәдәният министры Ирада Әюповага сүз бирде.

Ирада ханымның сүзләренә караганда, бүген 11 милли һөнәр төре торгызылган. Шулардан каюлы күн, агачны, тимерне сәнгатьчә эшкәртү, керәч сәнгате, челтәр бәйләүне мисалга китерергә мөмкин. Әмма мәдәниятебез тарихында 35 милли һөнәр төре теркәлгәнне исәпкә алганда, алга таба башкарасы эшләребез байтак әле. Бүгенге көндә югалган һөнәрләр арасында келәм туку, зәркән сәнгатенең катлаулы, озак вакытны ала торган төрләре, ташка, сөяккә бизәк ую, кәҗә мамыгыннан бәйләү һ.б. бар. Чабакса авылы тимерчеләренең сәнгать әсәрләрен дә сагынып сөйләргә генә калды. Заманында исә алар Әби патша арбасы өчен тәгәрмәчләр эшләгән. Бүген Чабакса тимерчеләренең элеккеге данын Татарстан Язучылар берлеге урнашкан бинаның капкасыннан, Ушков йортындагы тимер эшләнмәләрдән чамаларга була. Шул дәрәҗәгә яңадан кайта алырмы осталарыбыз?

Министрның доклады вакытында кайбер мәсьәләләр турында фикер алышу да булды. Мәсәлән, Ирада ханымның милли күлмәк, камзул, калфаклар белән барыннан да бигрәк үзебезнең республикада яшәүчеләрне кызыктырырга кирәк, Һиндстанда 45 ил вәкилләре катнашында булып узган гамәли бизәү күргәзмәсендә күренгәнчә, һиндстанлылар милли һөнәрләрен үзләренең ил халкын исәптә тотып үстерә, диюенә, илбашы, өч күлмәк тегәсез дә, берсен мәдәният министры үзе кия, болай милли һөнәрләрне үстереп булмаячак, дип каршы төште. Чыннан да, үткән гасыр башында Париж, Лейпцигта һ.б. шәһәрләрдә халыкара күргәзмәләрдә татар читекләре түр урынны алып торган икән, нигә безгә өч татарны киендерүдән зурракны өмет итеп, кире халыкара мәйданга омтылмаска? Әмма Ирада ханымның да сүзләрендә хаклык бар. Милли күлмәкләрне, алка, беләзекләрне үзебез кимәсәк, балаларыбыз шуны күреп үсмәсә, киләчәктә халкыбыз һөнәрләрен кем дәвам итәр? Ләкин милли күлмәкләргә бәя бик зур булып, үзебезнең республика халкы ул бәяне күтәрә алмыйча, тәмле каймактан авыз итә алмаган кебек, яланып кына калса, шуннан кемгә нинди файда? Һөнәрчеләребезнең эшләнмәләре сатылган ярминкәләр янына якын килерлек түгел ләбаса! 200 сумлык футболканың бәясе «Мин татар малае» яки «Без булдырабыз» дип язгач, 5 000 сумга сикергәннән генә милли һөнәрләребезнең үсүе бик шикле, үзебезнең сатып алучының исә гайрәте чигүен, осталарыбызга хәтере калуын көт тә тор.

Бер караганда, осталарны да аңлап була кебек. Эшмәкәр яки үзмәшгульләр булып теркәлгәнне генә көтәләр дә, тотыналар алардан салым каерырга. Аннары халык һөнәрчеләре булып ник теркәлмиләр, дип баш ватабыз. Ирада ханым докладындагы кайбер саннарны күргәч, чәчләр үрә торды. Һөнәрчеләребезгә патент сатып алу гына да 58767 сумга төшә. Чагыштыру өчен, Мәскәүдә патент бәясе – 29836, Түбән Новгород өлкәсендә – 9041, Свердловск өлкәсендә 15904 сум. Һөнәрчелек юлына кермәс борын шул кадәр акчаны чыгарып салырга кирәк булгач, кемнең муенына камыт киясе килсен? Илбашы, кул осталарын талаудан баемыйбыз, дип патентлар күләмен яңабаштан карарга, ташламалар ясарга чакырды.

Һөнәрчелекне үстерү юлында сикәлтәләр хәттин ашкан. Buro Banu ширкәтен оештыручыларның берсе Элара Шәйхи мәсьәләгә тагын да ачыклык кертә төште. Милли күлмәкләрнең эшләү вакытын һәм бәясен киметү өчен, кулдан чигәсе урынга, тегү машинасы белән бизәк төшерергә тотынган булганнар. Әмма кул эше югала икән, ширкәт милли халык һөнәрчелеген үстерүче статусын да югалта һәм дәүләтнең һәртөрле ярдәменнән дә колак кага. Шул ук вакытта Buro Banu ише вак ширкәтләр сәнәгать оешмасы дәрәҗәсен дә ала алмый, чөнки милли күлмәкләр зур күләмдә түгел, аз санда җитештерелә. Бериш осталар, эшне җиңеләйтергә, җитештерелгән күлмәк, камзулларның бәясен бераз киметергә теләп, ярамаган юлга – стилизациягә кереп китү нәтиҗәсендә, татар күлмәкләре милли төсмерне югалта бара. Кайбер җитештерүчеләрнең милли сәнгать, мәдәният турында белем дәрәҗәләре бик түбән, татар бизәген якынча да күзаллдына китермиләр. Ярым-кытай, ярым-япон бизәкле татар күлмәкләре туристларга яраса да, үзебезнең бабаларыбыз, бу тамашаны күреп, каберләрендә йөзтүбән борылып ятмасмы соң?

Илбашы Р.Миңнеханов та, министр И.Әюпова да, утырышта катнашучылар да бер мәсьәләдә уртак фикергә килде – милли мәдәнияткә мәхәббәт бала чактан тәрбияләнергә тиеш. Очрашуга, мәсәлән «Адымнар» мәктәбенең җитәкчесе Айдар Шәмсетдинов чакырылган иде. Ул «Адымнар»да халык һөнәрләренә зур игътибар бирүләре турында сөйләде. Чыннан да, бүген бу мәктәпләрдә республика буенча 4 мең бала укый, аларга 300 ләп укытучы белем бирә, тагын 110 хезмәткәр хезмәт күрсәтә икән, уку-укыту эшендә 8 мең эти-әни дә катнашканын исәпкә алганда, саллы сан килеп чыга. Бу кадәр халык милли һөнәрләрне үстерүдә катнашса, шәп булачак!

(Дәвамы 4 нче биттә).

Әлмәттә – «Тантана»лы тантана

● К.Тинчурин театры «Туктамыш»ы Ирек Хафизовны җырчы, композитор Роберт Андреев бүләкләде.

● Ф.Зариповка олуг бүләкне күренекле табиб Линиз Ризатдинов тапшырды.

Быел «Тантана» театраль премиясен тапшыру тантанасы Әлмәт татар дәүләт драма театрында үтте. Бәйрәмне Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагуманов һәм республикабызның мәдәният министры Ирада Әюпова башлап җибәрде.

Җиңүчеләр 15 номинация буенча билгеләнде. Иң шәп дебют төрендә Тинчурин театрында «Хан кызы Турандык» спектаклендә Турандык ролен башкарган Адилә Хәсәнова һәм Бөгелмә рус драма театрында «Бездонное озеро» тамашасында Лева ролен уйнаган Тимур Абдрахманов бүләкләнде. Иң әйбәт эпизодик роль өчен Чаллы театрының «Хәлбуки... Хәсән Туфан» спектаклендәге Клавдия роле өчен Индира Маликовага премия эләкте.

Быел Казан рус яшь тамашачы театры күп бүләк җыйды. Жюри театрның 90 еллыгын истә тотып шулай юмартланган булса кирәк, юкса иң шәп актерлар ансамбле өчен бүләккә ия булган «Руслан и Людмила» пластик спектакле дә, «Здесь был Кай» тамашасында Герданы уйнаган Эльмира Рәшитова һәм «Шварц, человек, тень» куелышында Шварцны гәүдәләндергән Сергей Мосейко бүтән театрларныкыннан әллә ни артык түгел.

Гадәттәгечә, Камал театры артистлары мул премияләр алып кайтып китте. Жюри елның иң шаулаган премьерасы – М.Галәү буенча, 60 яшенә үзенә һәм тамашачыларга бүләк йөзеннән, режиссер Фәрит Бикчәнтәев куйган «Болганчык еллар. Мөһәҗирләр»не, анда сурәтләнгән вакыйгалар милли трагедия югарылыгына күтәрелә алмыйча, татарның бәхет эзләвенә кайтып калса да һәм Европага хас салкын бер стильдә куелса да, елның иң шәп спектакле дип билгеләгән. Моннан тыш анда Зөһрә ролен башкаручы күренекле артистыбыз Алсу Гайнуллина икенче пландагы иң шәп актер төрендә бүләккә ия булды. Цензура көнннән-көн котырган, ирекне кысу киң колач ала барган заманда режиссер Айдар Җаббаров япон драматургы Коко Митанинның цензураның нинди абсурдка барып җитәргә мөмкин булуын күрсәткән әсәрен куеп шәп эшләде. «Көл»нең кече формадагы иң шәп спектакль төрендә бүләкләнүенә берәү дә каршы төшмәс.

Мул уңыш җыючылар арасында «Экият» театры да бар. Кече сәхнәдә куңелгә үтәрлек итеп нечкә, нәфис куелган «Серая шейка» иң шәп балалар спектакле төрендә бик лаеклы бүләкләнде. Н.Гумилевның әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Дитя Аллаха» спектаклендә өч роль башкарган Айвар Гыймаев өчен дә сөенерлек.

Әдәбият белгечләре, тарихчылар Тинчурин театрында сәхнәләштерелгән «Идегәй» спектакленең тетмәсен тетте. Шулай да вакыйга буларак аны билгеләп үтү кирәк булгандыр, чөнки тарих сәхнәләребездә көн саен җанланмый, горур ханнарыбыз татар сәхнәсендә – үтә сирәк күренеш. Әмма кемне билгеләп үтәргә? Төп роль Идегәйне уйнаса да, Илнур Гарифуллинның татарча сөйләме куандырмады. Аның каруы Туктамыш ханны гәүдәләндергән Ирек Хафизов күп тамашачыларның һәм «Тантана» премиясе жюриенең күңеленә кереп калган. Афәрин, Ирек!

Театр сөючеләр «Кави-Сәрвәр» милли операсын бик зарыгып көткән иде. Әмма ул күпләрнең өметен акламады, чөнки татар тамашачысына милли аһәң җитенкерәмәде. Шуңа да карамастан, төп рольләрдә чыгыш ясаган Эльза һәм Артур Исламовлар музыкаль спектакльдә иң шәп роль башкаручылар буларак бүләкләнде. Хәтта композиторы Миләүшә Хәйруллинага да бүләк тиде. Балыксыз урында кысла да – балык, дигән мәгълүм мәкальнең сүзләре бу очракка бик урынлы.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бүләк алмыйча калган вакыт бармы икән? Юктыр, мөгаен, чөнки республикада музыкаль театрлар да бүтән юк. Быел иң яхшы музыкаль спектакль төрендә «Щелкунчик» балеты һәм анда Щелкунчик, Патша улы рольләрендә биегән Олег Ивенко бүләкләнде.

Моннан тыш Дамир Сираҗиев исемендәге премияне алган театр белгече Айгөл Габәши өчен сөенәбез. Быел 70 яшен тутырган, байтак еллар Әлмәт театрында иҗат итеп, бүген исә Минзәлә тамашачысын шатландыручы Фоат Зариповны «Намус һәм тугрылык» төрендә «Тантана» премиясенә ия булуы белән тәбриклибез. Әлмәт театрының күренекле режиссеры Зәкия Туишева исемендәге махсус премия булдырылуы һәм аны Минзәлә театры артисты Рәзилә Муллина белән Әлмәт театры артисты Ләйсән Заһидуллинага бирүләре – быелгы «Тантана»лы тантананың сөенечле мизгелләренең берсе.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

1 нче биттә – «Россиядә ел укытучысы» илкүләм бәйгесенең тәбәк этабын ябу тантанасында иң яхшы татар теле укытучыларын бүләкләү. Фото: mon.tatarstan.ru.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

#ҺӘР ЯКНЫҢ – ҮЗ УЕНЫ

Россия Президенты В.Путин 20-21 март көннәрендә Мәскәүдә зур әзерлек белән үткән Кытай-Россия сөйләшүләренең икътисади һәм сәяси нәтиҗәләрен югары бәяләгән. Аның әйтүенчә, очрашуда имзаланган программа эчтәлекле ике уртак белдерү бүген чын стратегик хезмәттәшлек вә колачлы партнерлык үрнәге саналган һәм үз үсешенең иң югары ноктасына җиткән Кытай-Россия мөнәсәбәтләренең аерым характерга ия булуын бөтен тулылыгы белән чагылдыра. КХР рәисе Си Цзиньпин да бурычлы булып калмаган. Россия президенты белән ике арадагы сөйләшүләрен ул эчкерсез һәм дусларча аңлашу дип атаган һәм Кытай-Россия элемтәләренең дөньяви тәртип өчен дә бүген хәлиткеч әһәмияткә ия булуы турында әйткән. Ике арада товар әйләнеше артуын исә Кытайга һәм Россиягә социаль-икътисади үсеш өчен импульс бирә торган фактор буларак та бәяләгән. Ә очрашуда ике як исеменнән дә әйтелгән иң мөһим искәртү дип, мөгаен, аларның бүген урнаштыра торган мөнәсәбәтләре ниндидер өченче илгә каршы юнәлдерелгән гамәл булмавы турындагы белдерүләрен санарга кирәктер. Мәгәр, аның кем колагына әйтелүе дә хәзер яхшы аңлашыла булыр. Инде сәфәр барышында ирешелгән анык нәтиҗәләргә кыскача гына булса да тукталып үтик.

Ун сәгатькә сузылган сөйләшүләр ябык ишекләр артында да, ачык режимда да үткән. Нәтиҗәдә, Кытай вә Россия лидерлары ике ил икътисади хезмәттәшлеге төп юнәлешләрнең 2030 елга кадәр үсеш планы турында, шулай ук гомумколачлы партнерлык вә стратегик хезмәттәшлек мөнәсәбәтләрен ныгыту турында да уртак белдерү ясалган. Әлбәттә, әлеге сөйләшүләрдә сәясәт өлкәсендә дә җитди карарлар кабул ителгән: Кытай һәм Россия атом-төш сугышын башлап җибәрүгә юл куелмаска тиешлеге турында белдергәннәр; яклар гомумтанылган халыкара хокук нормаларын үзгәртүгә чик куелырга тиеш, дип саный; Мәскәү һәм Пекин Украинадагы низагны киңәйтүгә һәм БМО КШны әйләнеп кертелгән санкцияләргә каршы чыга; Мәскәү Тайваньны Кытайның аерылгысыз бер өлеше, дип таный; Кытай һәм Россия үзләренең төп мәнфәгатьләрен яклаганда бер-берсенә ярдәмләшү яклы; яклар АКШ ның глобаль ПРО системасын булдырудагы активлашуы җәһәтеннән үзләренең борчылуларын белдерә; Мәскәү һәм Пекин ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне хәрби берлек түгел дип саный, әмма уртак хәрби өйрәнүләрне регуляр рәвештә үткәреп торырга җыена; Кытай һәм Россия теләсә кайсы дәүләтләр һәм блокларның өченче илләргә зыянга эш итүенә каршы чыга; Мәскәү һәм Пекин COVID-19 ның килеп чыгышын сәясиләштерүгә дә каршы. Күрүебезчә, сәяси белдерүләргә кытлык юк. Әмма игътибарны аларның кайбер очракларда үзара каршылыкка керүе дә җәлеп итә. Шуңа күрә бәхәсле мәсьәләләр дә әлегә бик күп кала.

Әлбәттә, аерым игътибарны Украинадагы хәлләр белән бәйле проблемалар җәлеп итә. Билгеле инде, сүз иң элек Кытайның 12 пункттан торган «тынычлык планы» турында бара. Си Цзиньпин ул планның, Украина буенча сөйләшүләрне яңартып, якларны татуландыруга ярдәм йөзеннән, БМО уставы принциплары нигезендә, риясыз әзерләнүе турында белдергән. В.Путин да аны хуплаган. Көнбатыш белән Киев моңа әзер булган очракта, Кытай планын ул Украинадагы низагны тыныч юл белән җайлауда нигез итеп тә алырга мөмкин, дип саный. Әмма Россия лидеры бу җәһәттән, әлегә андый әзерлек күзәтелми, дип уфтануын да яшерми. Әйе, АКШ Кытай планын өнәми. План нигезенә ул суверенлык һәм территориаль бөтенлек принцибы салынырга тиеш, дип саный. Киевнең исә узган ел G20 саммитында бәян иткән үз планы бар. Иң элек ул үз территориясеннән Россия гаскәрләрен чыгаруны төп шарт итеп куя. Асылда, монда каршылык юк та кебек. Чөнки Кытай планының да (ә ул глобаль мәгънәгә ия) 1 нче пунктында сүз БМО уставын төгәл итеп үтәү һәм «барлык илләрнең дә суверенлыгы, бәйсезлеге һәм территориаль бөтенлеге гарантиялəнгән булырга тиеш»леге турында бара. Димәк, бу яктан ул Киев планына каршы килми һәм аны бары тик төгәл үтәргә генә кирәк.

Мәскәүдә үткән очрашу зур сәясәттә бүген кемнең кем булуын да бик ачык күрсәтте. Кытай белән Россия арасында 2022 елда товар әйләнеше 185 миллиард долларга җиткән. Алга таба чимал (газ, нефть һ.б.) сатуны тагы да киңәйтү, сигез өлкәдә (финанс, транспорт һ.б.) хезмәттәшлекне кат-кат арттыру карала. Чөнки Россия икътисады бүген башкача яши алмый. Азия, Африка, Латин Америкасы илләре белән исәп-хисапта Россия юаньга күчәргә мәҗбүр. Экспертлар мондый хәлне, КХДР кебек, Кытай бәйлелегенә күчү буларак бәяли. Кытай өчен бу отышлы. Ул арзан бәягә чимал сатып ала, Ерак Көнчыгышны үзләштерә, үз йогынтысын да арттыра. АКШ исә Россия белән конструктив дипломатиягә әзер булуы турында белдерә. Зур сәясәттә аларның, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүен дә онытмыйк.

Фоат УРАЗАЙ.

«Шәҗәрәм» бәйгесенә йомгак

Казан кооператив институтының Дәрдемәнд исемендәге Татар үзәгендә гаҗәеп зәвыклы эшләнгән шәҗәрәләр саклана. Арада Татарстанның Әлки районына караган зур шәҗәрә игътибарны җәлеп итә. Ул – Татарстанның атказанган икътисадчысы Мансур Ганиев бүләге. Шулай ук Г.Тукай, Ш.Мәрҗани, А.Алиш һәм башка шәхесләрнең нәсел агачлары үзәк диварларны бизи. Рәссам Әлфия Нурхәммәтова да мәдәният үзәгендәге күргәзмә өчен махсус үз нәселенең шәҗәрәсен иҗат иткән.

Узган атнада Татар мәдәнияте үзәгендә республикакүләм «Шәҗәрәм» конкурсына йомгак ясалуы да бик табигый иде. Бәйге быел 4 нче тапкыр оештырылды. Аны Татар мәдәнияте үзәге, Казан шәһәре мәгариф идарәсе, Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлары оешмасы, Әлки районы «Якташлык» җәмгыяте белән берлектә уздырды.

Үзәк җитәкчесе Флюра Абдуллина хәбәр иткәнчә, Татар шәҗәрәләрен өйрәнүдә Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин кебек мәшһүр дин әһелләре һәм галимнәребезнең традицияләрен дәвам итүче, аны фән дөньясында дөньякүләм күтәрүче, меңьеллык татар тарихын бүгенге көн белән тоташтыручы шәхесләр бар. Шуларның берсе – шәҗәрәләр төзүче әдәбият галиме, танылган рәссам-хаттат Нәҗип Исмәгыйлев. Ул конкурсның жюри рәисе булды. Конкурсантларның эшләрен, жюри әгъзалары буларак, тарихчы-галим Марсель Әхмәтҗановның шәкерте, филология фәннәре кандидаты Гөлнара Зәйниева, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, рәссам Әлфия Нурхәммәтова, Татарстанның халык артисты Азат Тимершәех бәяләде.

Йомгаклау кичәсендә Флюра Абдуллина Россия кооперация университеты ректоры, Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» хатын-кыз депутатлары оешмасы рәисе Алсу Нәбиеваның котлауларын җиткерде.

«Конкурска 30 га якын эш кабул ителде, – дип сөйләде Флюра Абдуллина. – Бәйгедә Киров өлкәсе Малмыж районы Иске Йөрек авылы мәктәбе, Татарстанның Балык Бистәсе районы Балтач, Югары Тегермәнлек мәктәбе, Әлки районы Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе, Казан шәһәре мәктәп-гимназияләре укучылары, Казан медицина көллиятендә белем алучылар актив катнашты. Араларында 18 буынын белүчеләр бар».

Әлбәттә, бу – конкурка йомгак ясау гына түгел, бәйгедә катнашучылар үзара тәҗрибә уртаклашты, Нәҗип Исмәгыйлев кебек остазлардан киңәшләр тыңлады. Аңлашыла ки, конкурска үзенчәлекле, кызыклы эшләрнең күп килүе җюрига эшне авырлаштырды.

«Казан медицина көллиятендә белем алучы Алинә Әгъләмованың үз нәселе шәҗәрәсен шигъри юлларга салып сөйләве, Казанның 199 нчы балалар бакчасыннан 6 яшьлек Яна Озерова, 112 нче балалар бакчасыннан 6 яшьлек Талия Лотфуллинаның да чыгыш ясау осталыгы күпләргә үрнәк булып торгандыр. Конкурста катнашучылар нинди яшьтә булуларына карамастан, чыгышларын, үз нәселебезгә тап төшермәбез, дигән сүзләр белән төгәлләве дә игътибарга лаек булды», – диде Ф.Абдуллина.

Сөембикә КАШАПОВА.

Районнар көч сынаша

«Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсында җиңгән район быел 3 млн сумлык сертификат ала. Ул акча мәдәни проектларны алга таба үстерүгә юнәлдереләчәк. Бу хакта Татарстан Премьер-министрының урынбасары Ләйлә Фазлыева матбугат конференциясендә хәбәр итте. «Акча матди-техник базаны үстерүгә, яңа спектакльләр әзерләүгә тотылачак», – диде ул.

Шулай итеп, җиңүче акчаны үз районында федераль яки төбәк мәдәни проектын гамәлгә ашыруга сарыф итә ала.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сүзләренчә, быел бер төп приз уйнатыла. Әмма конкурста үзен күрсәткән башка катнашучылар өчен дә махсус бүләкләр каралган.

Республика муниципаль берәмлекләре арасында «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елында башлана. 31 марттан 24 ноябрьгә кадәр Казанның 13 төрле мәйданчыгында Татарстан районнары милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр белән бәйле үз программасын күрсәтә.

Бүген «Татарстанның мәдәни башкаласы» бәйгесе кысаларында үзенең уникаль мәдәни кодын Халыклар дуслыгы йортында Лениногорск районы тәкъдим итәчәк. Үзәкләштерелгән китапханә Татарстан әдәбиятын үстерүгә сизелерлек өлеш керткән Лениногорск районы шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләреннән күргәзмә туплаган. Балалар һәм олылар өчен осталык дәресләре (фетрдан баш киемнәре, брошкалар, балчыктан милли бизәкле муенсалар, агачтан кечкенә йортлар ясау) уздыру да каралган.

ӨЧ КҮЛМӘК ТЕГӘСЕЗ ДӘ...

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Министр И. Әюпова һөнәрчелекне тарихи җирлектә торгызу һәм үстерү кирәклеген дә әйтте. Арча районы башлыгы Илшат Нуриев, бу җәһәттән Мәдәният министрлыгы белән эшләнгән һәм Мәскәүгә юлланган кызыклы проект турында бәян итте. Ул «Сафьян» дип атала. Билгеле булганча, Арчада милли аяк киемнәре җитештерү 1885 елдан бирле килә. 1960 елда производство фабрика статусын ала. 1970 еллар ахырында бирегә тәүлегенә 600 пар аяк киеме җитештерелгән. 2006 елда фабрика ябыла. 1,5 мең кеше эшсез кала. Бүген 60 ка якын оста бар. Әмма күбесе олы яшьтә. Менә шул тарихи җирлектә «Сафьян» исеме белән элеккеге производствоны торгызып, аны туристлык маршрутына кертмәкчеләр. Осталар эшләп кенә калмас, яшь буынга күнекмәләрен дә бирер, җитештергән товарларын шунда ук сатыр да. Проектны тормышка ашыру өчен, 100 миллион сум акча кирәк. Биектау районы Ямаширмә авылында да кызыклы бер үзәк булырга ошап тора. Аны Мәдәният министрлыгы һәм «Туран» фонды җитәкчесе Суфия Хәйбрахман бергәләп эшләгән. Ул шулай ук милли һөнәрләрне популярлаштыруны күз уңында тота, яшьләргә осталык дәресләре оештыруны да үз эченә алган. Ямаширмәдәге үзәк шушы елның сентябрендә сафка басар дип көтелә.

● **Buro Banu ательесын оештыручыларның берсе Элара Шәйхи.**

Казанның үзәгендә исә Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк үрнәгендә һөнәрчелек йорты ачмыйча һич мөмкин түгел. Илбашы бу максатта бернечә бина да карап куйган. Эре Европа компанияләре илебездән китү сәбәпле, зур сәүдә үзәкләренең бушап калган павильоннарын кул осталарыбызга бирү дә һөнәрчелекне үстерергә ярдәм итәчәк. Кыскасы, алда башкарасы эшләр бик күп әле...

● Махсус операция барган бер елда Украинага АКШ – 44,3 миллиард евролык, Британия – 4,9 миллиард евролык, Европа Берлеге – 3,6 миллиард евролык, Польша һәм Германия – 2,4 ешәр миллиард евролык, Франция – 660 миллион евролык хәрби ярдәм күрсәткән.

● Австралия стратегик сәясәт институты тикшеренүеннән күренгәнчә, иң мөһим технологик тармаклардагы фәнни эшләнмәләр саны буенча Кытай дөньяда беренче урында тора – барлыгы 44 төп өлкәнең 37 сендә ул әйдәп бара: наноматериаллар һәм робот техникасыннан алып алдынгы радиоешлыклы коммуникацияләр, саклану һәм космос технологияләренә кадәр. Мәсәлән, соңгы биш елда заманча авиация двигательләре буенча аеруча мөһим фәнни эшләрнең 48,49 проценты кытай галимнәренә туры килә, әлеге тармакта җиһанда иң алдынгы ун гыйльми үзәкнең җидесе бу ил территориясендә урнашкан. Технологияләр узышында икенче урында – АКШ, ул җиде өлкәдә беренчелекне бирми. Рейтингка башка бер ил дә кертелмәгән.

Бүген Татарстан язучы, журналист, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тормышы, иҗаты һәм эшчәнлеге белән азмы-күпме таныш. 1990 елларда Исхакыйның иҗаты үзенең асыл ватанында да өйрәнелә башлады. Галимнәр Төркиягә дә барып, Гаяз Исхакыйга кагылышлы документларның электрон күчермәләрен алып, шулар нигезендә фәнни мәкаләләрен яза, гыйльми эшчәнлек алып бара. Бу материаллар соңыннан Исхакыйның 15 томлыгы өчен нигез була. Язучының вафатыннан соң, аның архив материалларын туплап, шулар нигезендә «Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал вакыфы» фонды оештырыла. Фондның җитәкчесе Түләй Дуран 2008 елда Татарстанга килеп, әлеге архив материалларының электрон күчермәсен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына бүләк итте.

Гаяз Исхакый көндәлекләре



Түләй Дуран 2018 елның сентябрендә кабат Татарстанга килә һәм материалларның төп нөсхәләрен институтка тапшыра. «Материаллар язучының асыл ватаны булган җирдә сакланырга лаеклы», – ди ул. Бүген бу материаллар Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирасы үзәгендә саклана. Аның җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров «Татар-информ» мәгълүматлык агентлыгында матбугат очрашуында хәбәр иткәнчә, монда барлыгы 366 саклану берәмлеге хисаплана. Алар арасында Гаяз Исхакый әсәрләренең кульязмалары, аның 1919 елдан алып вафатына кадәр алып барылган хатирә дәфтәрләре, эш кәгазьләре, төрле оешмаларга юлланган мөрәҗәгатьләре, хатлары, фотосурәтләре һ.б. бар. Аларның күпчелеге – Гаяз Исхакыйның үз кулы белән язылган, татар, төрек, инглиз, алман телләрендәге төп нөсхә документлар. Фонд биш бүлектән тора. Беренчесендә, язучының иҗат мирасына мөнәсәбәтле язмалар, ягъни әсәрләренең кульязмалары, әдипнең үзе редакцияләгән караламалары тупланса, икенчесендә – иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән бәйле материаллар, төрле оешмаларга мөрәҗәгатьләре, төп нөсхә чыганаклар, өченчесендә – Исхакыйның үзе аралашып яшәгән кешеләргә, чордашларына язган хатлары. «Ул, белгәнебезчә, Финляндиядә яшәгән Зиннәт Вафин гаиләсе белән, аның кызы Халидә Вафина белән элемтәдә яшәгән. Америка консуллыгына, Азәрбайҗан Язучылар берлегенә язылган хатлары һ.б бар», – дип искәртә И.Гомәров. Тагын бер тасвирлама – 58 саклану берәмлегеннән торган фотосурәтләр. Язма мирас үзәге мөдире ассызыклаганча, алар архивның шактый бай өлешен тәшкил итә, сурәтләрне карап Гаяз Исхакыйның Төркиядәге яшәешен, сәяси-иҗтимагый җәһәттән актив тормыш алып баруын күрергә мөмкин. «Монда Япониядә, Мукденда, Берлинда, Төркиянең үзендә һ.б. төбәкләрдә төшкән фотосурәтләр. Бердән алар әдипнең көндәлек тормышын күрсәтеп торса, икенче яктан кемнәр белән аралашканын ачыкларга ярдәм итә», – диде И.Гомәров.

Филология фәннәре кандидаты Эльмира Галимҗанова 2018 елда кайтартылган материаллар арасында иң кыйммәтлесе һәм хәзерге көн өчен иң әһәмиятлесе аның шәхси көндәлекләре булуын ачыклап үтте. «Гаяз Исхакый үзе дә васыятьнамәсендә иң зур байлыгы буларак шушы көндәлекләрне күрсәтә һәм аларны, үз дәүләтебез булса, гыйльми академиягә тапшыруларын, киләчәктә көндәлекләрнең өйрәнелеп, матбугатта басылып чыгуларын васыять итә. Хатирә дәфтәрләре зур вакыт аралыгын колачлый. Алар – 1919 елның гыйнварыннан алып 1953 елның 10 ноябренә кадәр алып барылган көндәлек язмалар. Көндәлекләр ике өлештән тора. Беренче өлеше – Төркиягә кадәр чор (1934 елга кадәр). Икенче өлеше – Төркия чоры. Язучы аларын 1944 елдан алып бара һәм «Истанбулдагы хатирә дәфтәрләре» дип яңабаштан исемли. Әдип көндәлекләрендә һәр көн вакыйгаларга җентекле анализ бирә. Көндәлекләрнең беренче өлеше – 23, икенчесе 19 дәфтәрдән тора. Көндәлекләрнең 1934 елдан 1944 елга кадәрге аралыкта язылганнары, кызганыч, югала. «Бу көндәлекләренең Икенче бөтендөнья сугышы вакытында югалуы хакында ул үзенең васыятьнамәсендә дә әйтеп уза. «Әдипнең 42 көндәлегеннән 41 е Гаяз Исхакыйның туган ягы Казанга кайтып ирешә. Беренче дәфтәре югалган, икенче һәм өченчесе – Татарстан Милли музеенда, калганы Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана», – диде Э.Галимҗанова.

Хәзер институтның текстология бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан көндәлекләрне өйрәнү һәм басмага әзерләү эше актив дәвам итә. Текстолог галимнәребез Әнисә Алиева, Фәния Фәйзуллина һәм Гөлчирә Ханнанова бу эшне җаваплылык белән башкара. Язмалар, текстологик яктан эшкәртелеп, андагы вакыйгаларга, шәхесләргә, географик атамаларга тәфсилле искәрмәләр, аңлатмалар бирелеп, фәнни басма рәвешенә китерелә һәм ул берничә китаптан торган җыентык булыр, дип уйланыла. Әлеге басманың беренче китабы тулысынча әзерләнгән инде. Ул 24-25 апрель көннәрендә Гаяз Исхакыйның 145 еллык юбилее уңаеннан үткәреләчәк III Халыкара семинарда укучы кулына барып ирешер, дип планлаштырыла. «Бу басма 1919 елның беренче апреленнән, ягъни язучының Япониянең Токио шәһәрендә яшәү вакытынан алып, аның Парижга барып җитү вакыйгаларын үз эченә ала. 300 битлек китап фондта сакланган фотосурәтләр, язмалар белән баетылып тәкъдим ителәчәк»– дип сөйләде Э.Галимҗанова.

Көндәлекләрне өйрәнү процессында галимнәр Г.Исхакыйга бәйле шактый фактларның да тәгаенләнүен белдерде, алга таба да алар ярдәмендә әдипнең мөһаҗирлектәге эшчәнлеге һәм тормышы хакында томанлы калган кайбер вакыйгаларны ачыкларга мөмкин булырын искәртәләр. Әйтик, аның туган көне турында тәгаен билгеле булмаган. Язучы хатирәләрендә 23 февральдә туганмын, дип билгеләп үткән. «Матбугатта Гаяз Исхакый мөһаҗирлеккә 1918 елда чыгып китә дигән фикер күренә. Көндәлекләр исә бу мәсьәләгә дә ачыклык кертте. Язучы үзе конференциягә чыкканнан алып көндәлекләр алып баруын әйтә, сәфәргә 24 гыйнварда кузгалуын тәгаенләп үтә, Харбинга 1919 елның март урталарында барып җитә», –диде галимә.

● Г.Исхакый иптәшләре белән. 1919 ел.

Илһам Гомәров Г.Исхакыйның шәхси фондында тагын бер кызык материал булуы турында сөйләде. Алар язучының кызы – Сәгадәт Чагатай көндәлекләре. Ул 32 калын дәфтәрдән гыйбарәт. Аның бер өлеше алман телендә, беркадәре гарәп графикасы белән төрек телендә язылган. Сәгадәт Чагатайның көндәлекләре 1988 елга кадәр алып барылган. Ул аларда шәхси тормышыннан тыш, әтисе белән мөнәсәбәтләре, аралашулары турында язган, һәм көндәлекләрдә шулай ук Гаяз Исхакыйның вафаты алдыннан соңгы көннәре тасвирланган өлешләр бар. «Аларны өйрәнеп фәнни әйләнешкә һәм, гомумән, әдәби әйләнешкә кертү – алда торган бурычларның берсе», – диде И.Гомәров. Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина язучының миллият, милли үзаң, аны ничек тәрбияләү, милләт мәсьәләренә багышланган язмаларыннан, шушы мәсьәләләргә кагылган публицистик материалларыннан тупланган басма да, рус һәм татар телендәге басма да тиздән укучы кулына барып ирешәчәген әйтте.

Бүгенге көндә Гаяз Исхакыйның әдәби иҗатына багышланган дүрт кандидатлык диссертациясе язылган. Язучының әдәби иҗаты шушы диссертацияләр аша фәнни әйләнешкә керә. «Без бүген мәктәпләрдә, югары уку йортларында әдипнең иҗатына этрафлы, тирән бәяләрне күрә алабыз. Гаяз Исхакый шәхес буларак гаять кызыклы. Һәр буын татар кешесе аның көндәлекләре белән танышып, аны яңача ачачак әле», – диде Д.Заһидуллина. Галимә искәртеп үткәнчә, кызганыч ки, язучының сәяси, тарихи, публицистик эшчәнлеге фән тарафыннан тиешенчә өйрәнелгән, дип булмый. Г. Исхакый кебек, татар кешесе буларак, дөнья күләмендә милләтебезне яклап, шулкадәр күп йөргән, илләр гизгән башка кешене табуы читен. Аның биографиясе генә дә, кинофильмнар, ниндидер рок-опералар, балетлар өчен нигез була ала. Галимә шулай ук Г.Исхакыйга Кабан күле ярында Ш.Мәрҗани белән рәттән ак мәрмәр һәйкәл куелсын иде, дигән теләген дә җиткерде.

Сөембикә КАШАПОВА.

ЯЗДАН ТАКЫЯЛАР ҮРӘ ОКСАНА

Бу көннәрдә, Чиләбе шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрә Оксана Ильюп шигырьләре белән әсирләнеп, «төшләремнән энҗе бизәнчекләр үреп», «гөлчәчәктәй кызыл күлмәк киеп», «очкан саен очасылар килеп» йөрим.

Укыган әсәреңнең лирик героена әверелеп, ул булып яшисең икән, димәк, бу иҗат сине сулышы белән әфсенләгән... Бу мизгелдә «дөньялар күчәреннән күчсә» дә, тылсымлы каләм кодрәте, вакыт төшенчәсен оныттырып, тар калыплардан, кырыс кануннардан каерып, «уйлар уены», «хисләр галәмәте» белән сихерләп, сине шагыйрьгә ияртә... Бераздан син лирик герой белән, «кайда телисең, шунда очып, Җир шарын иңләп» йөри башлыйсың.

Күпләрнең иҗаты, мөгаен, «бу, һичшиксез, мәңгелек» дип ихлас инанган тәүге сөю тәэсиреннән чаткы алып, «кубәләкләр булып яфрак коелганда», «алтын агач тәүге бәскә сыенганда», «күлдәвекләр ясап, яңгыр явып торганда» тамыр җибәргәндер. Шуңа күрә тәүге шигырьләребез дә «күңел төймәләрен ычкындырып», «җиденче күкләргә җитәр халәттә» язылады...

Оксананың «Оча алам» (Чиләбе, «Титул» нәшрият үзәге, 2019) дигән китабына танылган шагыйрь, публицист, Татарстанның Биектау районында туып-үсеп, тормыш биографиясен Чиләбе өлкәсендә дәвам иткән, үзе гомер кичергән Яман Елганың шәрәфле гражданы булу дәрәҗәсенә ирешкән милләтпәрвәр шәхес – Ирек Сабиров язган. Якташының тәүге шигъри җыентыгын ул «Мәхәббәт китабы» дип бәяләгән.

Авторның әлеге китабындагы шигырьләр, нигездә, аның 2014–2019 елларга караган иҗатын колачлый. Җыентык ел фасылларына ишарә иткән «Яз», «Җәй», «Көз», «Кыш» дигән бүлекләргә бүлеп бирелсә дә, болар – мәхәббәт фасыллары, сөенеч һәр фасылда лирик герой үзе теләгән төсмерләрдә чагылышы.

Әйе, мәхәббәтнең дә фасыллары төрле-төрле була. Лирик герой бер – «җилнең язгы канатында очар идем» дип хыялланса, икенче юлы үзен «мин бит синең язгы җилен» дип игълан итә, «яздан такыялар үрә»...

«Саф зөбәрҗәт күзле җәе» аннан кача да, ул, «җанын ачып, хыял алдында яланаяк басып кала»...

Гашыйк җан «ноябрьнең матур сагышлары» тоткынлыгында... «Агачларның алтын яфракларын // Йөрәгеңә синең тиңләдем» дип, хисләрен көйгә салып җырлый. Сөйгәненең кара күзләренең чоңгыллары аның өчен – көзге төн...

Мәхәббәт әсирлегендә калган гүзәлкәйнең «язланган» кышы да кызларча елый», «Зиһенемне урап алып, чуалтасы килә. // Бураннарыма өереп, югалтасы килә» дип хисләнә ул, «күкне сыгып, мамык-мамык карлар яуганда»...

Шагыйрәнең тәүге шигъри такыяларында сөю энҗе-мәрҗәннәре арасында, «монда без дә бар әле» дигәндәй кинәт жемелдәп, асылташтай балкып алган башка кимәлдәге сирәк җәүһәрләр дә күренгәләп ала. «Казан», «Татар кызы», «Укытучыма», «Тукта, кеше», «Казан юлы» кебек шигырьләрне укыганда, авторның шигъри кыйблдасын барлап, тормыш фәлсәфәсенә йөз боруын күреп сөенәсең. Бу каләм әле эзләнүдә... Ул, мәхәббәткә әсир төшеп, «Бөтен дөнья, барлык галәм миңа гашыйк» дип хис итеп, «җиденче күкләргә җитәрлек халәттә, йә атлый, йә оча»...

«Оча алам» китабын укыганда, акылда төрле уйлар бөреләнде. «Чиләбе шәһәрендә яшәп, шагыйрә кызыбыз ничек татар теленә бу кадәр мөкиббән була ала? Каян килеп, иҗатында «тел сандыгы»бызның түрендәрәк сакланган бүгенге әдәби һәм хәтта борынгы татар сүзләренә дә мөрәҗәгать итә, үзе яңа сүзләр «тудырып» тәҗрибәләр ясый?» – дип сокландым. «Саглам» (нык, көчле), «асман» (күк йөзе), «тирби» (тибрәлә, тибри), «җиләгән» (арыган, йончыган) кебек китап сүзләре хәзерге сөйләм телендә киң кулланылганнары янына килешле генә кереп утырган, аңлатма бирмәгән очракта да, эчтәлектән җиңел аңлашыла. Арада автор яратып кулланган диалекталь сүзләр дә шактый: «сүзләр ялкынлыгы» (ялкынлануы күз алдында тотыла), «хисләрең ташкыныр» (ташкынланыр), «тышалган атлар» (тышауланган), «чынбарда» (чынбарлыкта), «ничәләмә» (ничәмә-ничә), «ныгышып» (ныгып, чыныгып) һ.б. сүзләр шундыйлардан. Чамасын белеп һәм урынлы кулланганда, алар да шигырьнең тукымасына ятышып, матур бизәк булып тора. Әмма кайберләре (әйтик, җәһил, җайдак) сүзнең әдәби телдәге асыл мәгънәсен бирмичә, автор теләгәнчәрәк төсмер ала... Рифмалашасы юллар да, каләм иясенең үзенә охшамыйча, ара-тирә ирекка омтыла. Монысы башка мәсьәлә. Без бүген Оксананың, әдәби сүз остасы – татар халык язучысы Марсель Галиевкә ияреп, «каләм очында – галәм» дип исбатларга омтылуы хакында сүз алып барабыз. Автор үзе, миңа калса, шигъри сәфәрен төгәл тасвирлый:

Сүзләр эзләп, ташлы биек
кыяларга менәм.
Сикәлтәле юллар үтеп,
дәрьяларга керәм.
Аннан тынлык. Такыр сукмак.
Күктә – ялгыз чиләп.
Кайда китеп баруымны
үзем генә беләм, –

ди шагыйрә, иҗат дигән әтрафлы вә четерекле хезмәт турында.

Телгә мәхәббәтенең серен ачсак, Оксанабыз Башкортстанның Лаклы авылында туып-үскән икән, әби-бабай (үзе атап йөрткәнчә әйтсәк – әткәй-әнкәй) тәрбиясе алган. Әнисе Илгизә Камил кызы һәм әнкәе (әнисенең әнисе) Клара Сәлим кызы адәм балаларына Күкләр әманәт иткән изге туган телебезне канга сеңдерү бурычын, шөкер, җиренә җиткереп үтәгән. Кызчыкның балалык чорында ук һәр язганын сокланып тыңлаганнар. «Бу кадәр уйлар, сүзләр каян килә сиңа?!» – дип үсендергәннәр.

Оксана Гыйләҗева (шагыйрәнең кыз фамилиясе. «Ильюп» – кияүгә чыккач, иреннән алганы) татар мәктәбендә укыган. Ул үзе, бик хаклы рәвештә, иҗат чишмәсенең башында шулай ук беренче укытучысы Альбина Даниял кызы белән аңа татар теле һәм әдәбиятыннан белем биргән Зәлия Фәйзрахман кызы тора дип исәпли. Без алдарак искә алган Ирек абыйсы Сабировны да ул остазы, тәнкыйтьчесе дип атый. Иҗатының камилләшүендә, өскә күтәрелүендә аның зирәк киңәшләренең зур әһәмияткә ия булуын әйтә.

Кызыбыз кечкенәдән иҗатка тартылган. 10-11 яшендә язган шигырьләренең берсендә ул «Яңгыр ява башласа да, мин кояшны табармын!» дип, «үҗәт холкын» күрсәтеп ала. Инде балалык чоры күптән еракта калса да, холкы гел шул: болытлы көнгә үч итеп, үзе кояш булып балкый:

Ул җилләр аяктан егарлык.
Кемнәрдер сүгенә, сүгенә...
Бары мин кояш күк елкылдыйм,
Тормышның язланган күгендә.

Ул шигырендә (ышанам, тормышта да!) «язын, урман ырымыннан чыгып, вәхши аланнарда чәчкә атарга» сәләтле.

Холык-фигыле калебенең төш-үзәгендә элеккечә калса да, кызыбыз шагыйрь буларак гел үсеш-үзгәрештә. Икенче китабын үзе дә ул «Үзгәрдең» (Чиләбе, «Титул» нәшрият үзәге, 2022) дип исемләгән. Китапта урын алган, соңгы берничә елда язылган әсәрләре дөнья гаме, тормыш фәлсәфәсе белән сугарылган, каләменең буыны тагын да ныгып, үткерләшкән, зирәкләнгән, чаяланган. Бер шигырендә язганча, ул үзен инде «галәмнең бер өлеше» итеп таный. Алай гына да түгел, үзен «мин – галәм аһәңе» дип белдерә.

Шигырьләрдә яшәешнең, кешенең галәмдә тоткан урынын, асылын ачыкларга омтылу, фәлсәфи уйланулар, нәтиҗәләр ясап кую арта бара. «Иртәге көн барыбыр яктырак», «Мөһим микән вакыт төшенчәсе?», «Мин үземнең чынлыгымны аңлыйм», «Сөймәгәнгә мизгелебез әрәм, сөйгәннәргә гасырыбыз әзер», «Без икәү ят галәм кунагы», «Без бит атлап йөри белмәгәннәр, безне коча төнге тәрәзәләр»... «Чынлап та шулай бит! Шагыйрә минем халәтне әйтеп биргән түгелме?!» – дия-дия сихерләнәсең. Димәк, бу шигырьләр уйдырма түгел. Димәк, Шагыйрь бар, шигърият бар!

Оксанабыз «Үзгәрдең» китабына керештә, үз укучысына мөрәҗәгать итеп, нәкъ шундый уйларны җиткергән дә: «Китап битләрен син дә рәхәтләнеп ачарсың һәм анда чумарсың, дип өметләнәм. Һәр шигырь – ул аерым бер дөнья! Һәрберсенең үз тарихы, үз холкы, үз төсе бар. Кайберләрен язган вакытта, йөрәк аша үткән хисләрне сүзләр белән ачыклый алмыйча, күп көннәр эзләнеп йөргәнем хәтердә. Ә кайсын миңа гүя Күкләр ирештерә, әйтерсең кемдер сүзләрне әйтеп тора, ә мин кәгазьгә төшерәм кебек тоела...»

Шагыйрь син тойган хисләрне кичергән... Шигырьләрен укыганнан соң, аның сүзләрен үзеңнеке итеп, шигырьләренең эчтәлеген күңелең аша кичерәсең. Шагыйрь күңеле тынлыкны бушлык дип кабул итә. Илһамсызлык – күңелнең явыз чире. Йөрәгеңнең күкрәк ертып типкән шашынуын сизмәсәң, күңелең күктә очкан халәтен сагына, эзли башлый. «Шыпырт кына илһамияң булып калам», дию дә үз-үзеңне тынычландыру өчен генә. Шагыйрьгә тынычлык кирәкми! Ул дәрьяларның саташуын тели! Ул, сөю яңгырында коенып, сөйгәненең учларында чәчәк ата, иреннәренең әмеренә чума. Шул мизгелдә аның күңел чагылышы – гөлчәчәкләр! «Гөлчәчәктәй кызыл күлмәк кисәм, ныграк сөярсеңме?» диме шагыйрь?!» Синең дә, уйларыңда булса да яшьлеккә кайтып, иң матур күлмәгеңне киеп карыйсың килә башлый. Син дә очмакчы буласың. Менә шул инде ул чын шигъриятнең тылсым көче!

Үзем дә иҗат биографиямне җыр сүзләре язудан башлагангадыр, Оксананың бу осталыгын аеруча игътибарга алдым. Ул җырларына көйдән «күлмәк» тә кидерә, гитарада уйнап, үзе башкара да.

«Бармакларым гитараны сөеп назлый», «Гитараның кылларына гашыйк җаным», «Гитарамның билен кочам, син – минекен. Һәм дөньялар күчмәгә күчәреннән...» Оксананың күңел кыллары тибрәнешен тою өчен, аның җырлавын тыңларга, тыңлау гына аз – ишетергә кирәк.

Шагыйрә кызыбызның милли сәнгатебез, туган телебез һәм әдәбиятыбыз өчен бүген аеруча мөһим тагын бер җитди шөгыле белән таныштырмый булмас. Безнең Оксанабыз да – Чиләбе татар халык театры артисты. Әлеге яраткан шөгыле, иҗаты белән ул Чиләбе өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез арасында туган телебезне, мәдәниятебезне тагын да киңрәк танытуга, туган телебезне яшәтүгә үзеннән өлеш кертә.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА.

Күңел яктылыгын саклый белү Биреләдер меңнән берләргә...

Оксана ИЛЬЮП

* * *

Чиксез рәхәтлеккә чумган чагым!
Рәхәтлекнең була төрлесе.
Җиһан белән бер көй-аһәңендә
Сеңә җанга сихри Таң төсе.

Һәр күзәнәк тирә-юньгә тузгып,
Бар-бөтеннең таный шивәсен.
Көзгедә күк Галәм сафлыгында
Зиһенемнең чагыла шәүләсе.

Мин таркалам һәрбер Терәклеккә,
Һәр Аланга, Күлгә, Башакка,
Һәр Орлыкка, һәрбер Кыя Ташка.
Барлык Җиһан минем кочакта!

Һәрбер уем уяу. Бер уянгач,
Кабат йоклап китү икеле.
Сулышымда – Галәм сулышыдыр!
Галәм төсле чиксез киңлегем!

Калебемнең нуры сарып ала
Туып килгән кояш урнына
Бар Җиһанны! Һәм Асылым шулчак
Әверелә илһам җырына.

Зиһенемне ача Мәңгелек һәм
Мизгел кушылган мәл офыкта.
Һәм мин түгел читтән күзәтүче,
Мин шәфәкънең үзе, чынлыкта.

* * *

Ничә яшь? Кем белгән. Кем биргән
Егерме. Утыз... биш. Шул чама.
Әмма бу бары тик шартлылык.
Саннарга син, зинһар, ышанма!

Һәр санның ул гына таныган
Бар сәер вә тирән бурычы:
Вакытның чикләнгән булуын
Ул безгә искәртеп торучы.

Шартлылык – чәчләргә чал куну.
Чынлыка бер генә хакыйкать:
Дөньяга, тормышка ни караш?
Күңелдә, йөрәктә ни халәт?
Мөһиме шул фәкать.
Шул. Фәкать.

* * *

Мин чәчкә күк – үтә нечкә –
Җил-давыл кагылмасын.
Ачык йөрәк ачы сүздән
Янмасын, ябылмасын.

Бәллүр күңелне дорфалык
Чакмасын, чатнатмасын.
Наданлык анык зиһенне
Ярмасын, тарайтмасын.

Кеше фикере җаныма
Тимәсен, тилмертмәсен.
Тормышымда яктылыкны
Ходаем киметмәсен.

Гаделсезлек ышанычны
Алмасын, алдамасын.
Гарь, шөбһәле ялган сүзләр
Йокмасын, ягылмасын.

Ач мине – килсә ачасың.
Бел – теләсәң белергә;
Әмма сак бул – күңелемә
Омтылганда керергә.

* * *

Төн тансык моң көйли. Мин, ярсып,
Нотадан нотага омтылам.
Аһәңнәр тоташкан мизгелдә
Бер таныш аккордта онытылам.

Күкрәктә ирекле сулышның
Бу аккорд иң мөһим нигезе.
Күңелем кыллары тибрәлә –
Ул аккорд бит синең исемле.

Төн илһам өләшә. Эндәшә.
Сөйләшә. Үзләшә җырымда.
Керфегем очында уйнаклый.
Мин уяу. Син йокла янымда.

Төн моңы сыгыла аккордтан,
Һәм кыллар канатка әверелә.
Асманнан таҗлары сүрелеп,
Чәчемә кушылып үрелә.

Ничаклы моңлы көй бу дөнья!
Ничаклы мин аны яратам!
Мин гашыйк бу төнгә. Һәм сиңа!
Бу әсәр дә төнлә яралган.

Халәтем – ярымтөш. Алда таң.
Йолдызлар тузаны – төн артта.
Мин язам, онытылып калганчы
Җанга хас бер таныш аккордта.

Үзәккә үтәрлек аһәңле
Күренеш. Наз алам аңардан.
Мин төннең куенына сыенам
Җыр булып. Мин тулы. Яңадан.

* * *

Кайчандыр бер туган кыю уйдан
Нибары тик гадәт кенә калган.
Төрле яклап тузан – җил тузгыткан.
Төрле яклап ялган.
Һәр кешенең үз туксаны туксан.

Кайчандыр бер ярсып, дөрләп торган,
Һәм аннары озак пыскып яткан
Күмер уты сүнгән. Һәм көл булган.
Тәкъдир шулай язган.
Дөнья – тоташ куе көлгә тулган.

Дөнья – тоташ күз ачмаслык томан.
Өзгәләндек, бәргәләндек яман.
Тик... туйдырган инде. Бәгырь каткан.
Кайсы якка баксаң,
Ни уйласаң, янда атлар – яран.

Көчле булдык шуның белән алдан.
Ә бүгенгә... кыю хыял-уйдан
Нибары тик хәрабәләр калган.
Без үзебез тузан...
Һәр кешенең үз туксаны туксан...

* * *

Елмаеп уяндым. Төн назлый.
Урамда яңадан кар яуган.
Чакырдымдыр кебек мин сине,
Син мине ишеттең дип торам.

Апрель себерә уйнаклап,
Күбәләк көтүедәй буран!
Мин синең исемне пышылдыйм,
Син мине ишеттең дип торам.

Бу – кышның хушлашу карыдыр.
Тылсымлы да, серле дә урам.
Уянып, мин дәштем күк сиңа,
Син мине ишеттең дип торам.

* * *

Беркайчан да минем тойгыларны
Син белмичә яшәп интекмәдең.
Төшенәм дип, хәтта күзләргә дә
Озак итеп багу кирәкмәде.

Барлык булган күңел халәтемне
Шигырьләрдә һәрчак сөйли бардым.
Хисләремә моң тасмасы үреп,
Шашып, ярсып җырларымны яздым.

Һәм ничаклы ерак булсаң да син,
Бу әсәрләр безне якын итте.
Хәлләремне белер өчен бары
Шигырьләрем укуың да җитте.

Алар аша таный белдең мине.
Серләремне ачтың аңлап бар(ы)сын.
Күрешмәүләр берни түгел. Җырлар
Арабызда күпер булып калсын.

* * *

Тормыш дигән ямьле яланнарда
Күкне ярып, шәфәкъ калыкканда,
Дөнья әйләнешен уздырып,
Яшьлек чаба, тузан туздырып.

Иреклекне сөйгән шаян юрга
Иксез-чиксез офыкларга табан
Юыртадыр. Кала эзләре,
Кала артта язлар, көзләре.

Әй юырта, ак-караны күрми,
«Гомер үтәр, кире кайтмас» дими.
Яшьлек бара җилләр кудырып,
Яшьлек чаба тузан туздырып.

* * *

Яктылыкка тартылучы җан мин.
Гел яхшылык килә күрәсем.
Тик шул омтылышның үзем генә
Белеп яшим хакын, бәясен.

Күңел канатларым каерылганда,
Бар дөньяга ачу туганда,
Башка бер дә елмаймастай булам,
Югалырдай, карлы буранда.

Күзләремдә кайчак чагыладыр
Яктылыкның төксе маягы.
Төшенәсе иде: айның да бар
Кояш төшми торган аръягы.

Төшенкелек җанга ургылганда,
Дөм караңгы, шыксыз көннәрдә
Күңел яктылыгын саклый белү
Биреләдер меңнән берләргә.

* * *

Күптән таныш. Хәтер җуеп онытылган
Хисләр кинәт әйләнде дә кире кайтты.
Бер җыр булып чыңлыйсың син күңелемдә,
Һәм ул җырда чит нота юк, һәм юк яты.

Гитарамның таныш аккорд тавышлары.
Хатирәләр юлларыннан барышларым...

Һәр аһәңе хәтерләтә төсмереңне:
Синең кебек үтә ерак, үтә якын.
Кем икәнең әле дә сер. Минем өчен
Син мәңге боз. Һәм мәңге ут.
Афәт. Янгын.

Гитарамның таныш аккорд тавышлары.
Хатирәләр юлларыннан барышларым...

Мең ел инде үз кешеләр. Юк, ят икән.
Бер-берене капма-каршы күпме хисләр!
Отып йөрәк тибешемнән моң ярала –
Нәфрәт белән мәхәббәткә уртак әсәр.

Гитарамның таныш аккорд тавышлары.
Хатирәләр юлларыннан барышларым.

* * *

Дистә еллар алмашынды. Ә син һаман
Элеккечә, гүя чумып күзләремә
Карыйсың да, «яратам» дип пышылдыйсың.
Һәм бар нәрсә үз урынында шул мизгелдә.

Бар нәрсә дә шундый дөрес: сүзләреңнән
Наз чәчелә. Карашларың, өтеп канны,
Күңелемнең иң төбенә кадәр төшә.
Без бербөтен. Без бер йотым. Без бер җаны.

Вакытыбыз – мизгел? Гасыр? Тулы дәвер?
Җуелгандыр күренешләр дә күбесе.
Начар булган нәрсә, хәер, истә калмый –
Хәтер саклар иң татлысын, кадерлесен.

Һәм тагын бер алсу шәфәкъ калыкканда,
Сергә төреп ничә таңнар язылганын,
Күчә дәфтәр битләренә безнең тарих –
Мәхәббәтнең мәңге тынмас авазлары.

* * *

Алган гыйлем тәҗрибәләп тупланмаган –
Китап, димәк, укылмаган, ятланмаган.
Күп дәресләр ваз кичерелеп, исраф калган.

Мин һәрвакыт гади генә бер кыз булдым.
Артык биек кыяларга ургылмадым.
Раббыбыздан хаклык сорап, дога кылдым.

Зирәклек бир, дидем, кабул итәр өчен
Кешеләрнең һәм үземнең кимчелеген.
Бир ярлыкау асылына төшенү көчен.

Дөнья ямен данлап яздым шигырь, җырлар.
Кем дә булса мине ишетер әле, тыңлар.
Мин күргәнчә күрер, бәлки, белер, аңлар.

Кешеләргә гаҗәпләнеп, яшьләр түктем.
Кабат карап кыйблага тезем чүктем.
Ничек таныйм бу тормышны, шулай үттем.

Язмыш мине сындырмады. Сөйде назлап.
Сынаулары – сабак иде, түгел газап.
Үз юлыма бастырды ул азлап-азлап.

Алган тормыш тәҗрибәсен туплап торам.
Һәм самими елмаям да, алга барам.
Рәхмәтләнеп, тәкъдиремә тугры калам.
Рәхмәт, Аллам!

Халыкны милләт буларак яшәтүче төп алшарт – аның теле. Тел бетә икән, милләт тә яшәүдән туктый. Күпләребез әлеге хакыйкатьне аңлаудан шактый ерак. Бүген республиканың 21 район үзәгендә татар мәктәпләре юк. 1382 белем бирү оешмасының 679 ында гына белем һәм тәрбия чаралары татар телендә алып барыла. Татарстанда яшәүче 2 млн 76 мең татарның яртысы татарча белми. Катнаш никахлар чәчәк ата (31,6%). Инде сан ягыннан да кимеп барабыз. Ничек бу хәлгә төштек, дисезме? Сәбәпләрен, әлеге халәттән чыгу юлларын язучы, шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим белән ачыкларбыз.

Айдар ХӘЛИМ: «Соңга калмыйк, татарым!»

– Айдар абый! Гомерегез буе татар халкына фидакярләрчә хезмәт иткән, туган тел әләмен 60 нчы елларда ук күтәреп чыккан шәхес буларак, милләтне уятуны, туган телебезне асылына кайтаруны нәрсәдән башларга киңәш итәсез? Шәхсән, үзегез милли көрәш юлына кайчан һәм нинди шартларда аяк бастыгыз?

– Иң беренче эш, милләтебезне, телебезне бүгенге халәтенә төшергән сәбәпләрне ачыклаудан башланырга тиеш. Үткәнне аңламыйча бүгенгене хәл итеп, киләчәккә юл ачып булмый. Милләтнең киләчәге үз язмышы турында борчылудан, уйланудан, халкыңның, туган телеңнең тарихын сагынудан башланырга тиеш.

Ә тел язмышы бүген генә килеп туган проблема түгел. Шәхсән, мине әлеге тема Казан дәүләт университетында укыганда ук борчый иде. Татарстан Язучылар берлеге каршында оешкан яшьләр түгәрәгендә Тәуфыйк Әйди, Рабит Батулла кебек кыю фикерле егетләр белән пышан-пышан булса да бу хакта сөйләшә идек. Ә инде Әмирхан ага Еники, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан янына барып йөрүләр милләт турында уйлануларымны нығытты гына. Туган халкымның кызганыч хәлгә төшүе, аны бу хәлдән чыгару юлларын эзләү тора-бара минем яшәү рәвешемә әйләнде.

1966 елда язучыларның бер җыелышында Рабит Батулла белән бик кыю гына чыгыш ясадык. «Ни өчен 100 млн тонна нефть чыгарган Татарстанда, татар илендә татар мәктәбен тоту өчен акча юк? Тиз арада татар яшьләре өчен журнал, аерым газета чыга башларга тиеш. Ә татар мәктәбен фәнни рәвештә тулы хокуклы мәгариф органы итеп праслау өчен, Мәскәүгә махсус петиция юлларга кирәк!». Президиумда утырган обком секретаре Вәлиев каралай янып чыкты. Үз заманы өчен шактый кыю гамәл иде бу.

Бүген татар милләтен уятыр өчен ай-һай күп көч түгәргә туры киләчәк. Чөнки ул – үз-үзе өчен көрәштән баш тартып, гамәлсез калган милләт. Гамәлне кайтарганнан соң гына, татар аякка басачак. Тик ул шулкадәр түнгән, турыдан-туры көрәшү түгел, хәтта көрәш турында уйлау мөмкинлегеннән дә ваз кичкән. Чөнки гасырлар дәвамында куркытылган. Иң беренче эш итеп, татар әнә шул куркудан арынырга тиеш.

Мин татар милләте өчен өч тапкыр ачлык тоткан кеше. 3-4 көн Казанда, 10 ар көн Уфада һәм Чаллыда. Уфада 1991 елның октябрендә татар милләтен башкортлаштыруга каршы салкын яңгыр астында асфальтта яттым. Чаллыда солдатларыбызны Чечнядан чыгару өчен ачлык тоттым. Болар протест гамәле иде, тик аны үстереп алучылар булмады. Әгәр дә татар милләтенең һәр тыкрыгында бер генә татар күтәрелеп чыкса да, татар мондый хәлгә төшмәгән булыр иде.

Аны уятып, яңа көрәш юлына чыгару өчен, милләт айнырга тиеш. Вакыйга булырга тиеш. Ни кызганыч, татар милләте вакыйгага бармый. Башка өчен үлсә дә, үзе өчен утка керми. Ул бөтен сугышларда да беренче, иң алдан йөгерә. Ләкин үзенә дигәндә, ул алда да түгел, артта да түгел, күренми. Шул ук вакытта ул үзеннән ваз да кичмәгән. Тик аңа үрнәк кирәк. Лидер кирәк. Әмма, ни хикмәт, шул лидерларны ул үзе харап итә. Шәхсән, мине шундый хәлгә төшерде. Фәүзия Бәйрәмованы нинди газапларга дучар итте. Ул бөек шәхесне без якларга, сакларга тиеш идек. Ләкин без аны якламыйбыз да, сакламыйбыз да. Әмма ул һаман газиз халкым, милләтем дип тыпырчына, рәхмәт аңа. Үз лидерларыбызны яклый белмәгәнгә күрә, без милләт буларак та, сан ягыннан да үсмибез. Узган 20 ел дәвамында 5 млн га да тулмавыбыз, 10 ел эчендә 600 меңгә кимүебез моңа дәлил түгелме?!

Ә бит татарны төрле чорларда газиз халкы өчен гомерен дә аямаган каһарманнар яшәтә. Туган милләтен моңарчы дөнья йөзендә булмаган биеклеккә күтәргән Җәлил, Алиш, Кормашлар батырлыгы – кешелек тарихында булмаган каһарманлык. Фашистлар империясенең башкаласы Берлин төрмәсендә 11 татар шагыйренең, татар язучысының 20 минут эчендә башлары киселсен әле! Алар туып-үскән илләре, газиз Ватаннары өчен һәлак булды бит. Аларны бит татар гаиләсе, татар мәктәбе, татар рухы тәрбияләде! Ник соң шул каһарманнарыбыз белән тиешенчә горурлана һәм туган телебез өчен көрәштә файдалана белмибез?! Яһүдләрнең шундый батырлары булсамы, җәй туры килгән саен халыкара мәйданга әләм итеп күтәреп чыгарлар иде!

Милләтне корбаннар айныта. Ә милләт корбансыз гына бәхетле булырга хыялллана. Аның бәхетле буласы бик килә, ләкин корбаннар бирмичә генә. Менә шунда безнең төп чиребез. Кашык күтәреп кенә корбан биреп булмый бит. Әле аның күбесе кашык күтәргәндә дә, билем сынмасмы, дип курка. Ә җиңү корбансыз булмый. Бу – буш хыял.

– Туган телгә мәхәббәт тәрбияләүне гаиләдән башларга кирәк, дибез. Тик «Татар теле миңа һәм киләчәктә балама нәрсә бирә?» дигән фикер аңына кереп урнашкан ата-аналар да шактый бит. Үгетләү яки аңлату юлы белән генә хәл итеп тә булмый. Бу очракта нинди чара үтемлерәк булыр?

– Ә татарның гаиләсе бармы соң? Татар милләте, ни кызганыч, гаиләсен югалткан милләт. Шуңа күрә аның исеме татар булса, фамилиясе рус, фамилиясе татар булса, исеме рус. Дәүләте белән бергә гаиләсен, үзен югалткан, үз-үзенә хыянәт иткән милләт. Ләкин без моны әйтмичә, милләтнең йөзенә кызартып чәпәмичә, йокысыннан уята алмаячакбыз. Татар милләтен саклап кала алмаячакбыз. Ата-аналар белән сөйләшкәндә дә күңеленә үтәрлек итеп, туган телебез белән горурланырлык, кайчагында хәтта оялтырлык мисаллар китереп сөйләшергә кирәк.

– Ә бит туган телебез, чыннан да, горурланырлык. Татар теле – дөньядагы иң бай тарихлы телләрнең берсе. Татарның беренче дәүләте безнең эрага кадәр 209 елда, ягъни моннан 2225 ел элек төзелгән дип фаразлана. ЮНЕСКО тарафыннан Бөтендөнья халыкара аралашу теле буларак, иң камил, иң бай, иң уңай лексикалы дип саналган 14 телнең берсе – татар теле. Ничек итеп шул, акка кара белән язылган хакыйкатьне милләт аңына индерергә?!

– Гомумән, татар теле кебек камил тел җир йөзендә юк. Ул бөтен сыйфатларны бирә ала. Татар милләте әнә шул хакыйкатькә инанган, үзенең бөек телле икәнен аңлаган хәлдә генә көрәшкә керә ала. Әлбәттә, татар баласының рус телен белүе дә хупларга кирәк. Ике халык арасына чөй кагу дөрес сәясәт түгел. Гомумән, безнең Татарстан – халыклар дуслыгының иң лаеклы үрнәге. Рус теле белән татар теле бер-берсенә каршы куелган көчләр дә, оешмалар да түгел. Ярдәмләшеп, аңлашып яшәгәндә, бер-берсен үстерәләр генә. Ике телне дә камил белү начармыни? Ә рус телен татар теленә каршы куеп, рус теленең ролен чиксез рәвештә көчәйтү сәясәте турыдан-туры татар милләтен, татар телен бетерүгә юнәлтелгән. Ничек тә шуңа юл куймаска, ахыргача көрәшергә кирәк. Чөнки хакыбыз, хокукыбыз бар. Без – Россия Федерациясендәге 89 субъектның берсе генә түгел, сан ягыннан икенче урында торган тигез хокуклы халык.

– Татар баласының туган теленнән бизүенә китергән тагын бер сәбәп – балалар бакчасы. Чөнки бала бакчага татарча белеп барса да, катнаш төркемдә руслаша башлый. Ә тәрбияче барлык балалар да бердәй аңласын өчен, русчага күчәргә мәҗбүр була. Дөрес, татар җанлы әти-әниләрнең тәкъдиме белән кайбер бакчаларда саф татар төркемнәре эшли. Тик ул диңгездәге тамчыга тиң.

– Ә нишләп әле без үзебезне кимсетәбез? Нишләп татар баласы үз илендә төркемгә генә йөрергә тиеш? Без бит төркем түгел, милләт, халык! Шәһәрләрдәге һәр комплекста, һәр район үзәгендә татар балалар бакчалары булырга тиеш. Татар милләтеннән булган бала нинди генә шартларда да туган телен бөтен камиллеге, тирәнлеге белән өйрәтә торган татар балалар бакчасына йөрергә, татар мәктәбендә, татар югары уку йортында белем алырга тиеш. Әгәр дә без милләт буларак бетәргә теләмибез икән, шушы өч буынны берләштергән чылбырны яшәтү өчен көрәшергә тиеш. Шулай итеп бер өзелмичә, ялганып булмый. Өзелгән җирдә генә ялганып була. Кагыйдә буларак, татар үзенең өзелгән җирен бәлә, әмма ул анда ялганмый, тагын өзек ясый, чөнки курка. Әгәр без гаиләбездә татарча сөйләшмибез, татар канунннары буенча яшәмибез, балабызны катнаш бакчага йөртүне, рус мәктәбендә укытуны дәвам итәбез икән, телебезне дә, милләтебезне дә, дәүләтебезне дә югалтачакбыз.

– Татар теле укытучыларының Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгына карата дәгъвасын ничек урынлы дисезң! Хәтта саф татар авылы мәктәбендә бүген ана телен укытуга атнага 2 сәгать кенә бирелә. Шәһәрләрдәге татар мәктәпләре, татар гимназияләре рус телендә белем бирүгә күчеп бара. Инде туган телебезне өйрәнүне ата-аналар сайлап алуына гына калдырган федераль закон белән дә килештек. Дәреслекләребезнең Мәскәүдә төзеләчәгенә дә баш селкеп, риза булдык. Нишләп шулай «телсез» соң без?!

– Без татар милләтен мәктәпсез калдырып, зур зыян китердек. Саф татар авылларында берән-сәрән калган мәктәпләрдән тыш, татар мәктәпләре юк бүген. Рус теле һәм әдәбиятыннан тыш барлык фәннәр дә, шулай ук тәрбия чаралары саф татар телендә алып барылган белем бирү оешмасы гына татар мәктәбе дип аталырга хаклы. Безгә һәр район үзәгендә, шәһәрләрдә һәр комплекста шундый саф татар мәктәпләре кирәк. Шулай булмаганда, татар рус армиясенә хезмәткә бармаска, торак-коммуналь хезмәтенә акча түләмәскә, Мәскәүгә салым түләмәскә тиеш.

Ә татар мәктәпләре язмышын мин тагын бер тапкыр 1969 елда Казандагы «Прометей» клублары

● Фәүзия Бәйрәмова белән. 2015 ел.

җитәкчеләренең семинарында күтәреп чыктым. Әлеге җыелышка делегат итеп Түбән Кама ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Леонид Лужицкий җибәрде. Ә Түбән Камага мин үз теләгем белән 1968 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлаган яшь белгеч буларак кайттым. Хыялым шушы шәһәрдә Татарстан Язучылар берлегенең филиалын һәм алга таба әлеге оешма нигезендә татар иҗтимагый үзәген оештыру иде. Озак та үтми, Рахмай Хисмәтуллин җитәкләгән түгәрәк нигезендә «Кама таңнары» дип аталган яшь язучылар берләшмәсен оештырдык. ВЛКСМ өлкә комитеты каршында оешуыбызның сәбәбе үзенә күрә көтелмәгән хәлләрдән яклану чарасы иде.

Казанга килгәч, КПСС өлкә комитетының пропагандистлар йортын эзләп таптым. Карыйм, зал шыгрым тулы. Президиумда – ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Рәис Беляев. Ә трибунадан кемдер чыгыш ясый. Сүзләренә колак сала башладым. «Татар яшьләре арасында тәртипсезлек артты, милләтчелек күренешләре очрый», – ди. «Коткы таратучылар» исемлегендә Нәкый ага Исәнбәтне, тагын берничә язучыны атый. Минем күңелгә бик каты тәэсир итте бу. Янәшәмдә утырган Бөгелмә егетенә: «Бәреп егыйммы моны?» – дим. Ул терсәгемә төртә: «Әйдә, Айдар!» ди.

Өр яңа яшел келәм буйлап трибунага таба киттем. Барып җитүгә, артым белән бастым да чыгыш ясаучыга борылып сүз башладым: «Татар халкының көче белән эшләнгән революция менә нәрсәгә китерде! Без, татарлар, бүген бер балалар бакчасыз, бер мәктәпсез калдык. Без татар милләтен бүген үтерүгә алып барабыз. Сез шушы шартларда да ниндидер миллләтчелек эзләп, үзегезне кыен хәлгә куясыз түгелме? Шушы Совет власте өчен көрәшкән татар халкын мәктәпсез калдыруга сез ничек карыйсыз?!»

Зал тып-тын. Урыныма барып утырдым. Бераз кулын терсәгенә куеп утырганнан соң, бу русча җавап бирә: «Махсус әзерлексез көе бу сорауга җавап бирә алмыйм». Тавышы үзгәргән, бөтенләй икенче тон. Ә мин яңадан торып басам да: «Әгәр әзер түгел икәнсез, ни өчен үзегез аңламаган проблеманы күтәрәсез?» – дим. Рәис Беляев тиз генә тәнәфес игълан итә һәм мине президиум янына чакыра. Ул арада халык (үзебезнең татарлар!) чыгыш ясаучыны уратып алып, рәхмәтләр укый, минем якка караганда, күбесенең күзеннән дошманлык чәчелә. Рәис Кыям улы әйтә: «Ә син беләсеңме, кемгә каршы чыгыш ясадың? Ул – Татарстан Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының сәяси бүлек башлыгы полковник Виктор Морозов».

Тәнәфескә чыгам, бөтен кеше чиратка баскан. Командировка акчасын бирәләр икән. Мин дә басам. Шунда ук янәшәмдә бушлык хасил була. Минем белән рәттән басмас өчен бөтенесе читкә тайпыла. Иң аянычы: күбесе татарлар бит. Шул чакта үзебезнең татарның ни дәрәҗәдә юкка чыкканлыгын, аумакайлыгын, сатлык җан булуын аңлап тетрәндем. Залда утырган 400 кешенең ник берсе килеп, хуплау сүзе әйтсен. Ә бит халкымны, милләтемне яклап чыгыш ясадым! Янәшәмдә утырган Бөгелмә егете генә менә сиңа минем адрес, теләсә кайчан минем фатир синең карамакта, диде. Шулай да бер тапкыр Бөгелмәгә баргач, мин әлеге фатирны эзләп таптым. Хуҗасын Мисырда командировкада, диделәр. Кем белә, бәлки ул да мине саткандыр…

Ә Түбән Камага кайткач, бер яхшы танышым: «Синең арттан шымчы җибәргәннәр, сак бул, алдыңны-артыңны карап йөр!» – дип искәртте. Менә шуннан китте минем «милләтче» дигән исемем. Ә милләтемне яклаудан туктаганым һәм туры юлыма хыянәт иткәнем юк. Шул заманнардан бирле 50 елдан артык вакыт үтте, ник бер кеше шалтыратып: «Айдар, син чыгыш ясаган вакытта мин шул залда утырган идем», – дип әйтсен.

Әнә шундый сугышта батыр, тынычта куркак-өркәк безнең халык. Ул тырыш, эшчән, әмма сәяси фикерләүче милләт түгел. Безнең бөтен нәрсә шуңа килеп терәлә. Анда күбрәк вак җанлылык, изелгәнлек өстенлек ала. Ул бары тик йомышчы малай. Ул – сөт, катык һәм бәрәңге милләте. Әмма ул бәрәңгене, файдалы матдәсе күбрәк булганча, тәгәрәтеп, кабыклы килеш ашамый. Ул тышын, витаминын арчып ыргыта, кырып ташлый. Тәгәрәтеп ашаса, бераз витамины калган булыр иде. Болар барысы да – татарның азатлык хакына корбан бирү зарурияттыннан тайчынуы. Шуңа күрә ул дөньяга да күп очракта аптыраган, таң калган хәлдә түгел, ә акчадан акайган күзләре белән карый…

– Айдар абый, исегездә булса, 2020 елның 1 сентябрендә бөтен мәгълүмат чаралары Казанда һәм Алабугада полилингваль мәктәпләр ачылуын шау-гөр килеп яктыртты. Шул ук вакытта татар теле елында бер татар мәктәбе дә ачылмавын искә алучы булмады. Шулай да җавапны көтеп алдык. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов 8 март көнне хатын-кыз журналистлар белән очрашуда Татарстанга саф татар мәктәпләре кирәклеген, ә полилингваль мәктәпләрнең татар телен без теләгәнчә өйрәтү мөмкинлеген бирмәвен ассызыклап әйтте. Бүген әлеге мәсьәлә белән Марат Әхмәтов җитәкчелегендәге тел комисссиясе шөгыльләнә, дип искәртте.

– Сүз дә юк, күп телле мәктәпләр дә кирәк; телләр белгән, илләр белгән, дип юкка әйтмиләр. Балаларга сәләтләрен үстерүдә бик зур мөмкинлекләр вәгъдә итә яңа мәктәп. Ләкин татар теле елында республикада бер генә татар мәктәбенең дә ачылмавы җитәкчелеккә дә, Дәүләт Советы депутатларына да абруй өстәми. Татар телен саклау һәм үстерүгә дәүләт дәрәҗәсендә алынганбыз икән, нигә әле полилингваль мәктәпләр ачуга бирелгән финансларның күпмедер өлешен саф татар мәктәпләре ачуга тотмаска! Әйтик, Чаллыда 2021 елда ачылган полилингваль уку комплексы белән бер үк вакытта ике-өч саф татар мәктәбе ачсак, күпме татар җанлы әти-әниләрне, әби-бабайларны, татар теле укытучыларын сөендерер идек.

Гомумән, туган телебезнең абруен күтәрүдә мөмкин булган бөтен чараларны да кулланырга кирәк. Әйтик, саф татар мәктәпләрен тәмамлаучы чыгарылыш сыйныф укучылары өчен БДИ балларына өстәмә бонуслар булдырсак, нинди мөһим кызыксындыру чарасы булыр иде. Кадет мәктәпләрендә укучыларга өстәмә баллар бирелә бит. Телебезне саклауга дәүләт дәрәҗәсендә җитди алынганбыз икән, нигә әле милли мәктәпләр өчен әлеге мөмкинлекне кулланмаска! Балада милли горурлык тәрбияләү өчен менә дигән стимул.

– Татар югары мәктәбенең дә хәлөте мактанырлык түгел. Федераль (Идел буе) университететын оештырган көннәрдә татар зыялыларының горурлыгы булган татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ябылды. Университетның яңа системасында 70 еллык тарихы булган татар филологиясенә урын табылмады. Ә бүген татар сөйләм һәм әдәби телен югары һөнәри дәрәҗәдә укытырга сәләтле тел белгечләребез җитми, дип чаң кагабыз. Айдар абый, нишләп соң һәрвакыт шулай килеп чыга?! Башта җимерәбез, аннан соң уфылдап кабаттан торгызу юлын эзлибез…

– Татарстан башкаласында данлыклы татар теле кафедрасын ябу татар телен, татар милләтен юкка чыгаруга җитди сигнал булды. Исемнәре бөтен татар дөньясына билгеле тел, әдәбият галимнәре Диләрә Тумашева, Гомәр Саттаров, Флера Сафиуллина, Ибраһим Нуруллин, Мөхәммәт Мәһдиевләрнең якты истәлеге кимсетелде. Бу бит тарихта булмаган хәл. Бөек Ватан сугышы барган көннәрдә, 1944 елда оешкан әлеге кафедра күпме татар җанлы яшьләрне милләт өчен хезмәткә әзерләү йорты иде. Әнә шулай итеп, федераль мәгариф системасы татар телле мәктәпләрне кадрларсыз калдыруга юнәлтелгән иң үтемле чараларның берсен тормышка ашырды.

Моны ничек тә булдырмаска кирәк, дигән таләпне беренчеләрдән булып, татар теле укытучылары күтәреп чыкты. Төрле дәрәҗәдәге җыелышларда яңгыраган кискен фикерләр, моң-зар, ниһаять, Рөстәм Нургали улына барып җитте. Югары дәрәҗәдәге җыелышларның берсендә ТР Рәисе Федераль университет ректоры Илшат Гафуровка катгый шелтә белдерде, татар теле кафедрасы ябылу турында ни өчен хәбәр итмәвенә анык җавап таләп итте. Нинди генә сәбәпләр, нинди генә акланулар эшкә җигелмәде! Дөрес, данлыклы кафедра урынына Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе дип аталган бүлек ачылды. Тик бүгенге көнгә кадәр элеккеге татар теле бүлеге абруен кайтара алганы юк. Ә инде башта җимереп, аннан соң төзүгә килгәндә, ул безгә өлкән туганнан күчкән мирасларның берсе.

– Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеген билгеләп үткән елны РФ Конституциясенә рус телен, дәүләт тоткан тел итеп, дәүләт теле дип танырга дигән төзәтмә кертелде. Димәк, 1991 елда татар теленә икенче дәүләт теле буларак бирелгән дәүләт статусын да, 68 маддәдә язылган дәүләт телләрен билгеләүдәге хокукларыбызны да югалттык булып чыга? Ә төп законга кертелгән төзәтмә халыклар дуслыгын какшатуга беренче адым түгелме?

– Рус телен дәүләт тоткан тел дип игълан итү, әлбәттә, бернинди кысаларга да сыймый торган чын законсызлык. Ничек итеп федерация халыкларның уртак дөньясы булган илдә бер телне генә дәүләт тоткан тел итеп калдырырга була? Моның өчен тулысы белән оятсыз булырга кирәк. Моны тыңлаган татар – икеләтә ахмак. Ялган өстенә ялганга башны иеп, ишәк хәленә калдык бит инде! Җитештерү буенча бөтен Россия күләмендә 4 нче урында булып та, хезмәт хакы алу буенча 21 нче урында булуыбыз шуны исбатлый түгелме?

Миңа калса, 89 субъектны эченә алган федерациядә 89 вәкил утырырга тиеш. Рус булмаган халыкларны дәүләт тоткан телләр исемлегенә кертмәү – бу бит бөек җиңүләр, Бөек Ватан сугышында кылынган батырлыклар өстеннән көлү, аларның мәгънәсен юкка чыгару. Минем әтием 4 ел буе сугышып, сугыш азагында Чехословакиядә нәрсә өчен һәлак булган соң? Мине, балаларымны, оныкларымны татарча укудан тыяр өченме? Бу бит газиз халкының якты киләчәге өчен үзен корбан иткән Җәлилләрнең батырлыгын юкка чыгаруга тиң. Милли җанлы татарлар бүген туган телебезнең федерациякүләм тигез хокукын кайтарырга, барлык халыкларның ассамблеясын булдырып, тиз арада имзалар җыю эшенә керешергә чакыра икән, бәлки колак салыргадыр. Уян, татар халкы! Мондый йокы сине һәм барыбызны да юкка чыгарачак. Без Советтан – федерацияне, федерациядән Советны таләп итәргә тиеш. Рус халкын дәүләт тоткан халык дип тану бу бит федерациянең үзен таркату, җимерүгә тиң. Россия шартларында федерациянең бөтенлеген, куәтен тәэмин итүче халыклар дуслыгына алмаш юк.

Бәлки кемдер мине кискенлектә гаепләргә омтылыр. Мин әйткәннәр кискен түгел, дөрес фикер. Төп максатым – үзебез яшәгән Росия Федерациясе дигән илне саклау, аның халыкара абруен күтәрү. Тик бер генә милләтне дә рәнҗеттермичә! Үзеннән кечерәк милләтне рәнҗетү, санга сукмау исәбенә бәхетле була алмаячагын өлкән туганыма ничек аңлатырга соң дигән борчылулардан туган фикерләр бу. Бүген Россияне халыклар бердәмлеген саклаучы бөек ил буларак беләләр, таныйлар, хөрмәт итәләр. Шул ышаныч югалмасын иде.

(Ахыры киләсе санда).

Әңгәмәдәш –
Рәзинә НАСЫЙБУЛЛИНА.

Яңгырлы кичтә

Афзал ШАМОВ

(Дәвамы. Башы 11 нче санда).

Ул арада аның кайчандыр ире булган кеше – Дәүләтхан, кыскартып әйткәндә, Дәүләт, чакыруны көтмичә, бу йортта, бу фатирда хакы булган кеше сыман күн итекләре белән бусаганы атлап кереп китте. Камиләгә хәзер йә тыныч кына ишекне ябарга, йә, көчен җыеп, аның кире чыгуын үтенергә, таләп итәргә, әгәр чыкмаса, бераз сәерсенеп һәм кызыксынып карап торган Шәйхулла карт алдында, яңгырлы караңгы кичтә, тирә-күршеләрне уятырлык һәм борчырлык итеп тавыш чыгарырга гына калган иде. Икенең берсе, башка юл юк. Әллә ул күршеләрне борчырга, кеше көлкесенә калырга теләмәде, әллә бу кеше белән тагын бер сөйләшергә, сынап карарга, аны яхшырак танырга, төшенергә исәп итте, – нәрсәгәдер, үзе дә сизмичә, ниндидер бер эчке көчкә буйсынып, ишекне әкрен генә япты, калтыраган куллары белән бикләде. Әле аның һаман нинди дә булса бер сүз әйтерлек көче юк иде. Аннары бу хәл аңа өн булып түгел, ә ниндидер саташулы төш шикелле булып тоела иде. Тик аның уянырга, көтелмәгән бу куркынычлы саташуны куарга көче генә җитми. Шулай да ул моның өн булуына, саташу түгел, ә чын тормыш булуына шикләнми.

Дәүләт кулындагы чемоданын коридорга куйды, Камиләгә таба борылды һәм аңа таныш булган бераз төчерәк тавыш белән сорады:

– Үзең генәме?

Хатынның борынына тыштан кергән көзге салкын яңгыр исе белән бергә тәмәке исе һәм сизелер-сизелмәс аңкып торган аракы исе килеп бәрелде. «Эчә икән», – дип уйлады ул һәм, өйдә үзе генә икәнен аңлатырга теләп, башын селкеде. Гаҗәп, менә шушы яңгыр исе, тәмәке исе, барыннан да бигрәк аракы исе аны кинәт дөньяга, өнгә кайтарды.

– Йә, күрешик, булмаса, – диде Дәүләт һәм Камиләгә кулын сузды. Хатынның кулын учлап тоткач, ул аны, үзенә таба тартып, кочагына алырга, алдан уйлап куйган сүзләрен кабатларга теләде булса кирәк, татлы телләнеп, нәрсәдер мыгырданып алды, ләкин Камилә аның кулыннан тиз ычкынды.

– Тукта, башта өстегезне салыгыз, хәл-әхвәлне сорашыгыз, – диде.

Моны ул шундый тыныч әйтте, хәтта үзенең беренче сүзне шулай тыныч әйтә алуына гаҗәпләнде дә. Инде ул аңына килә башлаган, аның үз-үзен тота алуы, горурлыгы яңадан кайта иде. Шулай да әле үзенең калтырануын, рухи калтырануын түгел, ә эчке физик калтырануын тыеп бетерә алмый иде. Моның өчен аңа минутлар, дөресе, Дәүләтне, аның төсен-битен, күз карашын, аңа таныш хәрәкәтләрен, гадәтләрен яңадан күрергә кирәк булды.

Бу минутта ярым караңгы коридорда ике көч очрашты. Берсе алдан әзерләнгән, әйтеләчәк сүзләренә, аерым хәрәкәтләренә кадәр уйланган, ләкин мәхәббәт белән дә, нәфрәт белән дә сугарылмаган, бары хайвани хистән генә торган көч булса, икенчесе күп еллар буе ачы күз яшьләре белән сугарылган, әрнүдән, онытылмас үпкәдән, хәтта нәфрәткә якын хисләрдән гыйбарәт иде. Соңгы көч Дәүләтнең беренче орынуын кире кайтарды, тукталып калды. Ләкин шуның белән бергә бу соңгы көчтә, әрнү, үпкә һәм нәфрәткә якын хисләр артында, шәфкатьле күңелләргә генә хас икенче хис тә яшеренеп ята иде. Сүнеп барган мәхәббәт хисеме ул, әллә кызгану хисеме, Камилә моны үзе дә төшенеп бетерә алмый иде.

Дәүләт Камиләнең нечкә күңелле, ягымлы, гафу итүчән табигатьле җан икәнен белә иде. Шуңа күрә ул, аның кире кагуын, салкынлыгын вакытлы чәбәләнү, назлану дип санап, күңеленнән моңа бераз көлемсерәп, плащын салды, аны коридордагы киемнәр янына элеп куйды. Шәһәр чите пычрагын алып кергән итегенә карап алгач, аны да салырга кирәк тапты. Чишенгәннән соң, ул Камиләгә таба борылды, кесәсеннән тарагын чыгарды, бераз көлемсерәгән күзләре белән караштыргалап, сирәк чал бөртекләре белән чуарлана башлаган кара чәчен артка тарады. Камилә исә, бер сүз дә әйтмичә, аның хәрәкәтләрен күзәтеп, ишек төбендә басып тора иде.

Алар берничә секунд шулай, бер-беренә карашып, сүзсез басып тордылар. Бер-берен сынау идеме бу, әллә, күп еллардан соң очрашкач, ничек сүз башларга белмичә аптырап калган секундлар идеме, – ничек кенә булмасын, бу секундларда алар икесе дә нишләргә белми иде. Шулай да Дәүләт, Камиләгә таба омтылырга теләгәндәй, тагын бер талпынып алды. Ләкин, хатынның якын китермәс салкынлыгын күреп булса кирәк, үзен тыеп өлгерде һәм шуның белән бергә көлемсерәве дә бетте.

– Әйдә, түрдән узыгыз, – диде хатын һәм үзе аңа юл күрсәткән сыман, челтәрле ак пәрдә белән өретелгән пыяла ишекне ачып, эчкә узды, бүлмә уртасындагы өстәл янына барып басты һәм яңадан «ире»нең хәрәкәтләрен күзәтә башлады.

Дәүләт оекбаштан гына бүлмәгә керде, кулларын артка куйган хәлдә аның бер башыннан икенче башына хәтле сөзеп карап чыкты: баш-башлары никельле тимер карават, аның янында шундый ук бала караваты, шифоньер, кечерәк диван, китап шүрлеге, түгәрәк өстәл, гади агач урындыклар, тәрәзә пәрдәләре артыннан күләгәләре генә күренеп торган ниндидер гөлләр. Бүлмәдәге җиһазлар кыйбатлылардан булмаса да, җыйнак, матур: зәвык белән урнаштырылганнар һәм шуның белән бергә хатынның өйне матур итеп җыя белүен дә күрсәтеп торалар.

Дәүләт каршында Камилә ничектер кинәт үсеп киткән сыман булды. Шул Камиләме бу? Элекке нечкә күңелле, ягымлы, тотып алу белән үк коелып төшә торган Камиләме?

Дәүләтнең күз карашы бала караваты өстендә бераз озаграк тукталды, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, кашларын җыерды һәм шунда ук ул күз кырые белән генә Камиләгә карап алды. Хатын, аның бу карашын күрмәмешкә салынып, бер кулын өстәлгә куйган, икенче кулы белән халатының күкрәк турысын йомарлап тоткан хәлдә басып тора иде. Ул әле һаман үзенең калтырануын, туңуын җиңә алмый иде.

«Бала янына барырмы икән?.. Барырмы икән? – дип уйлады ул. – Бармады. Кашларын гына җыерды».

Дәүләтнең күз карашы шулай ук китап шүрлегенә дә төште, анда да бераз тукталып торды. Камиләнең бүлмәсендә китап шүрлеген күрү, китапларның күп булуы сәер тоелды булса кирәк. Бу юлы да Камиләгә карап алды.

Күпме вакыт узгандыр, Камилә моны белмәде; Әммә минутлар түгел, сәгатьләр, авыр сәгатьләр узды кебек. Шулай тоелды.

– Нишләп басып торасыз, утырыгыз, – диде хатын һәм шунда ук, тавышын мөмкин кадәр әкренәйтеп, өстәде: – Хәер, монда бала уяныр, кухняга керик.

Кухня да хатынның җыйнак һәм төпле яшәгәнлеген раслап тора иде.

Алар аш урыны булып хезмәт итә торган кечкенә өстәлнең ике башына утырдылар. Тагын тынып калдылар.

«Бала турында сорашырмы икән?.. Нәрсә дияр икән?..» Дәүләт бернәрсә дә сорашмый, кулларын бер кая куярга белмичә, йә өстәл өстенә, йә үзенең тезенә куйгалап, йөгерек соргылт күзләре белән кухнядагы әйберләргә һәм Камиләгә караштыргалап алып, ничек сүз башларга белми утыра.

Бер караганда чибәр, икенче караганда ничектер бераз тискәре, үзсүзле кеше тәэсирен калдыра торган бу кара чәчле, куе кашлы, җәенкерәк борынлы кеше моннан тугыз-ун еллар элек Камиләнең башын тәмам әйләндергән иде. Камилә эшли торган төзелеш трестында шофер иде ул. Машинасы белән таш, кирпеч, ком, цемент ташый һәм шуның белән бергә төзелеш кызларын шыркылдашып көләргә мәҗбүр итә торган шаян сүзләр дә тәяп килә иде. Яшь иде, таза иде. Барыннан да бигрәк, шаян телле, җиңел, хәрәкәтчән егет иде. Гармунны оста уйный, шундый ук оста бии дә иде. Эш вакытында булсын, аннан соң булсын, төзелеш кызлары аның тирәсендә, чыпчыклардай чыркылдашып, пырылдап әйләнгәлиләр иде. Әле бу вакытта авылдан яңа гына килгән Камилә башта, аны ошатканлыктан түгел, болай гына, иптәшләре белән аның янында булгалый, аның шайтан төкергән теленнән чыккан сүзләрен ишетеп, чын күңеленнән шыркылдап көлә иде.

Нәрсәдер булды, анысына тукталып тормыйк, көннәрнең берендә Камилә аның җанкисәге булып әверелде. Язылыштылар. Бергә тора башладылар, һәр көнне иртә белән Дәүләт инде аны, үзе белән бергә машинасына утыртып, эшкә алып бара һәм, шаян сүзләр әйтеп, хәзер инде аның тирәсендә ул кадәр пырылдашмый торган кызлар янында калдыра иде.

Алар ике ел чамасы бергә тордылар. Дәүләт әллә ни каты холыклы, усал кеше булып чыкмады. Какмады, сукмады, бер тапкыр да кул күтәреп карамады. Эчә дип тә әйтеп булмый иде үзен. Тик әллә нигә бер, иптәшләре белән очрашкан чакларда гына эчкәләп кайта иде. Анда да үз аягы белән кайта һәм иртә белән, кичә эчмәгән, исермәгән кеше кебек, эшенә чыгып китә иде. Җаен-уңаен белеп торганда, аның белән яшәргә, тормыш корырга мөмкин иде. Камилә барысын да эшләде, аны бәхетле итәргә тырышты. Кирәк икән, аның өчен утка керергә әзер иде. Чөнки ул, тормыш иптәше булгач, хатын булгач, бөтен җаны-тәне белән аныкы, бары аныкы гына булырга, аның өчен генә яшәргә тиеш дигән караштa иде.

Дәүләт Камиләнең яхшы гадәтләрен күрә, белә иде. Шулай да ул дөнья ике килми, аның барлык җимешләрен татып калырга, алардан теләгәнчә файдаланырга дигән фикер белән тәрбияләнгән һәм бу фикерне иң дөрес фикер дип саный иде. Тора-бара, моннан тыш, аның ике тискәре гадәте ачылды. Берсе – кимчелекләрен күрсәткәнне яратмау булса, икенчесе – бала булдырырга теләмәү иде. Бу гадәтләре аның әлеге фәлсәфи карашыннан, дөнья ике килми дигән карашыннан килеп чыккан инде. Шуның белән бергә ул үзен өйләнгән итеп түгел, ә, электәгечә, гаилә тормышының барлык кануннарыннан азат, бәйсез итеп тоя иде. Юлында очраган хатын-кызларга, хәтта таныш булмаганнарына да шаян сүзләр сибүне, каш сикертүне, күз кысуны, урыны туры килгәндә кулына теләгәнчә ирек бирүне бернәрсәгә дә санамый иде.

Камилә аның бу гадәтләре белән, гаиләгә, тормышка шулай җиңел, төкереп каравы белән килешә алмады: әрнеде, елады, ялынды, әмма, аның күз яшьләренә карап, Дәүләт үзгәрмәде. Вәгъдәне, антны кызганмады, тик берсен дә үтәмәде. Аның өчен вәгъдә бирү, ант итү бернәрсә түгел иде, – бары «ике килми торган дөньяның» вакытлы хәйләсе генә булды.

Яши торгач, тагын бер нәрсә ачылды. Дәүләт моңа кадәр өйләнгән булган икән. Хатынын ул кайдадыр Донбасс ягында ташлап калдырган. Хәер, берике ай торгач, Дәүләт моны үзе әйтте, яшереп тормады. Мондый эшне ул яшерергә кирәк тапмый, хәтта аны гаеп итеп тә санамый иде.

Камилә белән дә ул ансат аерылды. Кычкырышмады, талашмады, ул бала табу йортына киткәч, үзенең әйберләрен җыйды да Кабан күле буендагы кечкенә бүлмәсен ташлап чыгып китте. Аның белән бергә төзелештәге шыркылдык кызларның да берсе югалды.

(Дәвамы киләсе санда).

«Идегәй» – дастан үрнәге

(Дәвамы.
Башы 11 нче санда.)

Икенче бер урында Туктамыш, «Идегәйнең башын алам дип, үз башыма яу алдым» дип, үз гаебен хәтта үзе дә таный.

Идегәй качып киткән ханны тота алмый. Шуннан соң ул, әлеге эшне улы Норадынга тапшырып, Сарайга әйләнеп кайта. Монда, башкаланы Аксак Тимернең көлгә әйләндереп китүен күреп, өлешчә үзе дә сәбәпче булган баскынчылык сәясәтенең аянычлы бер нәтиҗәсенә тап була. Җитмәсә, Аксак Тимер элекке хан урынына Алтын Урдага «курчак хан» итеп Кыйгырчык исемле үз кешесен дә куеп киткән булып чыга... Аны һәм янындагы яраннарын юк итеп, вакытлыча булса да, дошман як белән килешүгә, кан коюга китергән хыянәткә бару исәбенә әлеге үтә хәйләкәр, әмма һәрьяклап сәләт һәм акыл иясе булган Идегәй Алтын Урда дәүләтенең идарә башына менеп утыруга ирешә.

Дастанның татар версиясендә Идегәй хан итеп куйган Тимер Котлык образы бөтенләй тасвирланмый, ә аннан соң тәхеткә утырган һәм гаскәре Туктамышны әзәрлекләүдә катнашкан Шадыбәк (1400–1408) исеме генә телгә алына. Аның каравы Идегәйнең әлеге ханнар заманында Алтын Урданың икътисади куәтен, сәяси абруен күтәрергә юнәлдерелгән эшчәнлеге бер-бер артлы тезеп күрсәтелә.

Тарихи чыганаклардан аермалы буларак, әсәрдә Туктамыш Идегәйнең улы Норадын кулыннан үлгән итеп тасвирлана. Әтисеннән аерылып калгач, ул ханны куып тота һәм аларның икесе арасында эпос геройларына хас сүз бәйгесе булып ала. Туктамыш, «мин Чыңгызмын, беләмсең, хан улымын, ханыңмын» дип, үзенең кем булуына басым ясый, «халыгыма, илемә өлге булган морзамын» ди, Норадын исә аның Сарайдан мәсхәрәләп куып җибәрелүен исенә төшерә. Һәм иң ахырда «казак булып җиреннән, куылып йөрсен иленнән» дигән каргышыннан соң Туктамышның башын чабып өзә дә этисенең каршына кайтарып сала.

Моннан арысы хан һәм Кара-Тиен Алып каргаганча булып чыга. Үзенә дип ниятләгән Туктамыш кызы Ханәкәнең, мәкерле Җанбай котыртуына бирелеп, әченә киез бәйләп каршылавын күргәч, моңа этиең гаепле дигән сүзләрен ишеткәч, Норадын түземе, кулындагы думбрасын атып, Идегәйнең уң күзен чыгара. Шул рәвешле, ул, этисен рәнҗетеп һәм башка бер җиргә барып урнашырга өмет итеп, казак булып («каз» борынгы төрки телдә күчеп йөрү мәгънәсендә) ил гизәргә чыгып китә. Ләкин, төпләнеп калырга урын тапмыйча, бераздан кире

әйләнеп кайта һәм, атасының чакыруы буенча, болар янә Сарайда очраша. Бу юлы Норадын, үзе юк чакта, тәхеткә этисе ярдәмендә Шадыбәк утырганын белеп, эчендәге рәнҗүен тышка чыгарып сала. «Йә син үзең хан булгыл, йә син мине хан кылгыл!» – дип, атасына хәл итмәслек сәяси дәгъва белдерә. Чыңгыз нәселеннән чыкмаганлыгын аңлап һәм «падишаһлык сөрә алмам – Алла үземә бирмәсә» дип аек акыл белән яшәгән Идегәй, әлбәттә, моңа риза булмый. Нәтиҗәдә, ике арадагы конфликт тагын да кискенләшеп, ата кеше казак булып читкә (тарихи чыганакта Харәземгә) чыгып китәргә мәҗбүр була.

Соңрак чорга караучы Кырымга бәйләнешле төрек чыганакларында Норадынның тәхеткә дәгъва белдерүе Шадыбәк үлгәч, ягъни Булат-Солтан хан булыр алдыннан булган хәл итеп күрсәтелә. Дастан ата белән ул арасындагы низагны үзенчә файдалана, аларның иҗтимагый-сәяси карашларын ачу белән бергә, вакыйгаларның драматик киеренкелеген, тәэсирлелеген дә арттыруга ирешә. Вакыйгалар үсеше күрсәткәнчә, Норадынның идарәче булырга омтылу теләге барып чыкмый. Икейөзле Җанбай корган хәйләле тозакка эләгеп, ул Туктамышның улы Кадыйрбирде кулына әсир төшә. Үтерелгән этисе өчен үч алып, ул Норадынны ерткычларча җәзалый, һәм газаплауларны батырларча кичергән герой соңыннан үзенең атасы Идегәй алдында җан бирә. Үлгәндә, ул бозылышканнары өчен этисеннән, кулын үбеп, гафу үтенергә өлгерә.

Ә хәзер моннан алда булган хәлләргә – Туктамыш ханның ничек үтерелгәнлегенә кабат әйләнеп кайтыйк. Әлеге хәлгә бәйле рәвештә әсәрдә гадәттән тыш күренеш тасвирлана: Норадын үзенең кылычы белән Туктамыш ханның башын чабып өзгәч, аннан кан урынына сөт ага. Бу гаҗәп хәлнең мәгънәсе Идегәйнең үлеме белән чагыштыргач һәм ике үлемне боларның кылган эшләре белән тәңгәл куеп карагач кына ачыла.

Тарихтан билгеле булуынча, Туктамышның уллары, Алтын Урда тәхетен үз кулларына төшерергә тырышып, шактый озак көрәш алып бара. Шулардан бердәнбер исән калган Кадыйрбирде исемлесе – Норадынны үтергәне – үзенең һөҗүмнәре белән Идегәйне кат-кат борчып тора. Әмма 1419 елда ике арада булган соңгы сугышта ул Идегәй кулыннан һәлак була. 67 яшьлек каһарман моны «арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар» дип, «алты батман чукмар»ы белән сугып үтерә. Туктамыш буыны тәмам кисела.

Ләкин бу канлы сугыш, яраланып, берүзе калган Идегәй өчен дә һәлакәт белән тәмамлана. Ахырда ул, Кадыйрбирденең үзен чолгап алган «унике түрә, алты би»ен кырып бетерсә дә, хәлсезләнеп калгач, Барын морза аның башын чабып өзә. Тәгәрәгәндә, баш мондый сүзләр әйтә:

Сөт урынына кан койдың,
Канымны түгеп ни кылдың?
Казан, Кырым, Аҗдаркан,
Куымны сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең.

Менә монда инде киселгән баштан кан агуы белән очрашабыз. Беренче очракта сөт ага, икенче очракта – кан, моның сере нәрсәдә соң? Дөрес җавапны табарга төбәкләр «куымны сорап купканда» дигән юл ярдәм итә. Борынгы төрки телдә «кын» җәза, үч дигән мәгънәне белдерә. Татар сүзлекләрендә «кун» (дастанның Нигъмәт Хәким язып алган вариантында «кон») «йолым», «үч» дигән төшенчәләргә туры килә дип күрсәтелә. Кыргыз телендә әлеге сүзнең мәгънәсе – «үтергән һәм гарипләгән өчен түләнә торган хак». Туктамышның, Алтын Урда тәхетен яулаганда, Идегәйнең этисен үтерүен, ягъни кан коюын исәпкә алганда, аннары Идегәй улы Норадынның, Туктамышны үтереп, кан үчен кайтаруын истә тотканда, элекке ыру-ара йола-гадәт буенча «үтерү хакы» түләнгән булып чыга. Сөт образы исә шушы буруч яки йолымның кайтарылганын белдерә дә инде, һәм бу Норадынның корбанына «үз кылганың үзеңә кайта» дип әйткән сүзләре белән дә раслана. Шул ук вакытта ак сөт символы (монысы аеруча мөһим) канкоеш тукталырга, иминлек белән алышынырга тиеш дигән мәгънәне дә аңлата. Кызганыч ки, каршы як, кабат кан коеп, «кан канны тарта торган» юлга баса. Моннан тыш, әсәрнең беренчә урынында канлы кылычны сөт белән юу мотивы яки шуның киресе кабатлана, шулай ук саурык бия (кырыкмыш тай) сөтенең тыныч йортка кот булуы турында әйтелә. Монда да сөтнең канкоешка чик куярга яки тынычлык-иминлек урнаштыруга чакыру мәгънәсендә килгәнлеген сиземләү кыен түгел.

Гомумән, «Идегәй» дастанының бөтен композициясе «кан – кан булып, явызлык – явызлык булып, яхшылык – яхшылык булып кайта» дигән фәлсәфи принципка корылган. Идегәй авызыннан шушы принципны раслый торган сүзләр төрле вариантларда, әйтик, контраст парлар рәвешендә дә әйттерелә:

Мин яхшыга яхшымын,
Мин яманга яманмын.
Дустымы утын сүндермәм,
Дошман утын яндырмам.

Ошбу фәлсәфи канун күпчелек геройларның төрле вариантларда пар-пар итеп яки капма-каршы куеп сурәтләүләрендә дә, аларның үзара мөнәсәбәтләрендә, эшләрендә дә чагылыш таба. Әйтик, Котлыкыя Туктамышның атаклы ау бөркете балаларын Аксак Тимергә сата, бу хәл исә үзенең һәм гаиләсенең юк ителүенә китерә; әлеге гаилә Дөрмән би кулы белән һәлак ителә, әмма тиздән аның үз улына әҗәл килә. Идегәй туганнан туганы легендар Кара-Тиен Алыпның йөрәгенә ук белән ата, шуның каргышы төшеп, үз улы моны ахырда яртылаш сукыр итеп калдыра; Шаһ Тимер Алтын Урдага басып керә, җавабы – аның гаскәрен, эпик уйланмага корылган бәрелештә булса да, Туктамыш ханның пәһлеваны Кыпчак би кыйратып сала; әлеге баскак әмирне Идел-йорт өстенә алып килүче Идегәй була, нәтиҗәдә ул ил агасының (халыкның) бәддогасын ала, сарайсыз, улсыз кала; Кадыйрбирде Норадынны җәзалап үтерә, әмма Идегәй соңыннан улын үтерүченең үзен һәлак итә һ. б. Кайбер антипод буыннарны башкачарак та төркемләргә мөмкин. Мәсәлән, Идегәйнең этисе Туктамыш тарафыннан үтерелә, тик ахырда үзе дә Идегәйнең улы кулыннан үтә. Кыскасы, башкаларга карата эшләнгән һәр ярамаган эш яки фаҗига тудыра торган гамәл дастанда шуңа ук бәрабәр җавапка дучар була, начарлык тиешле җәзасын ала.

Әсәрнең «умыртка баганасын» яки эпик чылбыр тәшкил итүче мондый парлы контраст буыннарның бер өлеше, һичшиксез, героик эпос традицияләре яки каһарманлык мотивлары белән дә үрелеп килә. Мәсәлән, үзара сугыш һәм хәтта баш киселер алдыннан да ике якның бер-берсе белән батырларча сүз көрәштерүе, дошманын үткер тел белән өркетергә тырышуы; аерым каһарманнарның каршы як батырлары яки гаскәре белән орышканда, экияти пәһлеванга әверелүе; үлемсез батырның – Кара-Тиен Алыпның һөҗүмгә борешә торган култык астына ук белән атып һәлак ителүе.

Каһарманлык мотивларының күпчелеге, әлбәттә, Идегәй һәм Норадын образлары белән бәйле. Туктамыш ягына килгәндә, мондый мотивлар теге яки бу дәрәҗәдә Кыпчак би һәм хан улы Кадыйрбирде өлешенә туры килә. Туктамыш хан исә, ягъни дәһшәтле Аксак Тимергә каршы кат-кат яу белән барган кодрәт иясе, әсәргә бөтенләй ябышмый торган Болгарны җимерү эпизодын исәпкә алмаганда, бик еш кына «азамат ир», «олуг хан» дигән хөрмәтләү эпитетлары белән аталса да һәм хан үзе бабасы Чыңгызның абруена кат-кат таянса да, әсәрдә шактый пассив, кыюсыз, хәтта куркаграк та итеп тасвирлана.

Моның, безнеңчә, ике сәбәбе бар. Беренчедән, Туктамыш, башта Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга ирешсә дә, Җучи олысының куәтен кайтаруга алыну акрынлап илнең зәгыйфьләнүенә, ә үзенең тәхеттән качып китүенә китерә. Икенчедән, үзен акламаган ошбу сәясәттән файдаланып, хәтта дошман көченә таянып, хакимият башына сыгылмалырак, остарак сәясәт алып бара торган яңа идарәче килә. Бу хәл исә үз чиратында тарихи аңның һәм халык рухының үзгәрешенә китерә.

(Дәвамы киләсе санда.)

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы.

Талантлы каллиграф, мөгаллим Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ инициативасы белән Россия ислам институты карамагында «Ән-Намир әл-Мөхаттат» дип аталган гарәп классик каллиграфиясе һәм көнчыгыш сәнгатьләре үзәген төзү карары 2010 елда кабул ителгән. Үзәк бүген дә уңышлы эшли! Бу әңгәмәдә – шушы үзәкнең алыштыргысыз директоры, хөрмәтле Рамил хәзрәт Насыйбулловның иҗаты, эш нәтиҗәләре, каллиграфиягә кагылышлы фикерләре...

Шәрык сәнгате

– Рамил хәзрәт, сезнең әти-әниегез нинди һөнәр ияләре һәм алар сезнең иҗатка нинди карашта?

– Әти-әнием, әлхәмдулилләһ, исән-саулар! Алар инде күптән лаеклы ялда. Әнием – архитектор, ә этием эше бина-комплекслар төзү белән бәйле булган инженер хезмәтендә булды. Әнием – сәнгать кешесе дә, татарча җырлый, рәсем сәнгате, тегүчелек – аңа барысы да хас. Төрле кул эшләренә бик һәвәс! Әтинең дә куллары алтын. Балта тота белә. Аның бабасы да, бабасының атасы да агач эше осталары булган. Мин шул дәү әтиләремнән мирас булып калган эш коралларын, экспонатлар буларак, кадерләп саклыйм. Бәлки, киләчәктә шуларны да кертеп, бер матур музей ясарга мөмкинчелек туар. Чөнки ул кораллар бик күп, арада хәтта XIX гасырныкылар да бар.

Әнием сәнгать белән шөгыльләнүемне ярата. 1980 нче елларда, мәктәптә укыган чакта ук мин ушу, каратэ белән мавыктым һәм кытай телен дә өйрәнә башладым. Мәдәният арасындагы охшашлыкларны барладым. Кытай, Япония илләре мәдәнияте хакындагы мәгълүматларны күпләп укып, аларны татар мәдәнияте белән чагыштыра идем. Шушы кызыксынуларым мине ислам динен өйрәнүгә китерде. Инде мәктәптә укыганда, 1989-1990 елларда, гарәп каллиграфиясе белән чынлап торып кызыксына башладым. Ә бу – ислам каллиграфиясенә өйрәтә торган китапларны беркайдан да табып булмый торган вакытлар иде әле... 1993 елны мин Бөгелмәдәге төрек лицеена укырга кердем. Гарәп теле укытучыбыз Хәсән Сәвил каллиграфия сәнгате белән кызыксынуымны күреп алды һәм миңа шушы юнәлештә белем бирә башлады. Классик гарәп каллиграфиясенең бөтен ысулына иҗазәтне (дипломны) (гарәп каллиграфиясендә барлыгы – 12-13 төр) 1997 елда Истанбулда алдым, доктор Мәхмәт Рәфигый Киләҗидән. Хәзер бу шәхес Нидерландның Роттердам каласында урнашкан Җ.Руми Сәнгать институтында белем бирә. Шулай ук: Каман-кари – Азия җәясе ясау сәнгате, эбру һәм кануни орнаментация – тәзһиб (яки захрафа) буенча иҗазәтләрем да бар. Дөрес, мин һәр күргән белемне җыймыйм. Эш өчен, уку, аралашу, анализ ясау өчен күпме кирәк, шулкадәр өйрәнәм. Каллиграфиядән, сугышчан көрәш төрләреннән кала, металл һәм агач эшкәртү ысулларын да өйрәндем. Шәрык милли киемнәрен ничек тегәргә кирәклеген дә төшендем. Кайвакыт зәркәнчелек белән дә шөгыльләнәм. Китап ясау сәнгате – җилдчелек дип атала. Моның белән дә мавыккач, сәхифәләрне тегү, тышлык ясау һ.б. технологияләрен дә теләп өйрәндем. Берничә ел элек үзәктә, тәҗрибә буларак, укучыларымны Пенчак силат Харимау – индонезия көрәш алымнарына да укыттым. Аларга моның белән шөгыльләнү өчен киемнәр дә тектем.

– Хәзрәт, Гыйльм-уль-хатт турында искә алган идегез... Ул нинди фән?

– Хәреф формаларының сыйфатларын өйрәнеп, аларны камил ясый белү гыйлеме. Аңа төшенү – әле гарәп графикасын тулысы белән белү дигән сүз түгел. Гарәп теле 12 фәнне үз эченә ала, ә каллиграфия исә – шул гарәп теле фәне эченә кергән бер фәнне тәшкил итә. Бу сәнгатьне бар кеше дә үзләштерә алмый. Мәсәлән, «Ән-Намир әл-Мөхаттат» үзәгенә уку елы башында утызлап кеше килергә мөмкин, ләкин ахырга таба инде бер-ике кеше генә дә кала. Гомумән, үзәгебез ишекләре һәркемгә ачык. Укыту бушлай. Моннан кала тәзһиб, китап төпләү һәм башка Шәрык сәнгатьләрен өйрәнү дә каралган.

– Каллиграфик әсәрләр ясау – дөрес һәм матур язу өчен күпме вакыт таләп ителә дип саныйсыз?

– Бу укучының тырышлыгыннан, кызыксынучанлык дәрәҗәсеннән дә тора. Яхшы укытучы булуы да бик мөһим. Гарәп каллиграфиясе сәнгате гомер буе камилләштерелә... Аннары кайбер язу ысуллары гадирәк, ә кайберләре бик катлаулы бит. Мәсәлән, сөлс язу ысулына берничә ел эчендә өйрәнергә мөмкин. Ләкин бу әле сөлс ысулын кулланып, бик камил яза башлау дигән сүз түгел. Һәр ысулның үз кагыйдәләре булса да, укучының язмасы барыбер аның холкы аша да үтә. Һәм аның үзенә хас үзенчәлек килеп чыга. Каллиграфия сәнгатендә һәр хәреф элементларында яшерелгән үзенә хас канун, мәгънә бар. Гомумән, каллиграфиягә иҗазәт алганчы, 20-30 ел да үтә ала.

– Рамил хәзрәт, каллиграфик әсәрләрегез Татарстан, Россия, Төркия, Малайзия, Индонезия, Германия, АКШ, Таиланд, Канада һ.б. дәүләтләрдәге тупланмаларда саклана. Халыкара күргәзмәләрдә, бәйгеләрдә еш катнашасызмы?

– Юк. Зур күргәзмәләрдә катнашканым юк, бәйгеләр белән бик кызыксынмыйм. Каллиграфия – башка төр сәнгатьләрем белән бергә бара торган бер юнәлеш, ягъни минем яшәешемнең бер өлеше генә. Минем шәхси күргәзмәм бер тапкыр гына булды, 2014 елда Кол Шәриф мәчетендәге Татар шәмаиле галереясында «Камиллек сәнгате» дип аталган күргәзмәмне сәнгать белеме кандидаты, күргәзмә кураторы Рөстәм Шәмсутов ачкан иде. Берникадәр әсәрләрем, даими күргәзмә буларак, Казан ислам университетында эленеп тора.

Бәйгеләргә килгәндә, минемчә, алар аерым кешеләр өчен мөһим. Конкурслар, бәлки, сәләтләрен үз-үзенә раслау өчен яисә шушы сәнгатькә бәйле булу өчен кирәктер... Шәхсән үзем өчен сәнгать – ул яшәешнең максаты түгел. Бәйгеләр, минемчә, күп очракта объектив була алмый. Нәтиҗә теге яки бу карарны чыгарган кешеләрнең шәхсиятенә дә бәйле. Ә бу – субъектив әйбер. Мәсәлән, бер сүзне дүрт кешегә язарга кушсалар, дүртесе дә дүрт төрле эшли бит. Әмма берсе генә җиңә. Ләкин ул нинди кретерийга

остасы

карап җиңә соң?! Бу язу канун дөреслегенә бәйлеме? Яисә композиция төзелешенәме? Яки үз холкын күрсәткәнме? Яки тиз яисә акрын язугамы... Берсенең хәрефе шома чыкса да, формасында җитешсезлек бар, ә икенчесенең формасы камил, ләкин каләм йөртеше шома түгел, өченчесенең исә композиция төзелеше дөрес, тик хәрефләрендә җитешсезлек сиземләнә, дүртенчесенең, киресенчә, һ.б. Бәйгенең, гадел булмыйча, кешенең күңелен төшерү мәсьәләсе дә бар.

– Хәзрәт, археология белән җитди кызыксынуыгыз, татар җәяләрен ясау белән мавыгып китү нәтиҗәле булдымы?

– Мәктәптә укыган чакта ук тарих белән мавыктым. Үзем өчен татар тарихы белән бәйле төрле макетлар һәм реконструкцияләр ясый идем. Алардан тулы бер музей ачарлык кебек иде!

1990 еллар башында минем татар тарихы белән бәйле экспонатларым шактый иде... Шуларны вакытлыча гына Бөгелмәнең татар гимназиясенә биреп тордым. Андагы стендка җәя, төрле кылычлар, ук очлыклары, Алтын Урда дирһәмнәре күчермәләре һ.б. әйберләрем урнаштырылды. Гимназия республика күләмендәге конкурста да җиңде... Аларны мактап язма да чыкты. Имеш, укучылар тарих белән шөгыльләнә, тарихчылар белән киңәшләшә... Нәтиҗәдә, ни кызганыч, экспонатларымны кире бирмәделәр, җимерелеп-таралып, алардан бер ни калмады диярлек...

– Сезнең өчен борынгы татар кураен яки ситар ясау да авыр түгел икән...

– Мин бит дүртенче буын агач үю остасы... Бервакыт татар курае тарихы белән кызыксынып киттем һәм 1991 елда курайлар ясый башладым. Туганнан туган абыем да бу эш белән шөгыльләнә иде. Гомумән, безнең нәселдә курай ясауга һәвәслек бар, мәсәлән, бабамның әнисе урманнан курай үсемлеген кисеп алып кайтып, борынгы типтагы курай ясаган һәм күңелләргә үтеп керерлек итеп уйнаган.

Андый төр курайда тавыш чыгару үзенчәлекле, чөнки сызгы өлеше юк. Тавыш, курайны өске тешкә терәтеп, билгеле бер юнәлештә һава өрелүдән чыга. Ни кызганыч, хәзер бездә бу төр курайга әллә ни әһәмият бирелми, ул инде 40-50 ел кулланылмый. Шуңа да халык аны безнең курай дип тә белми. Бу төр татар кураеның озынлыгы 80-90 см га җиткән. Гадәттә, алар курай үсемлегеннән ясалган, 2-5 тишемле булганнар. Мондый курай казах, кыргыз, башкорт, монгол, алтай халыкларында да бар. Хәтта шуңа охшаш озын, сыбызгысыз инструмент күп кенә Көнчыгыш халыкларында да очрый. Ләкин аларны ясау өчен камыш, бамбук һ.б. материалларны кулланалар.

Мин Көнчыгыш музыка коралларыннан ситарны һәм элек татарларда ятаган дип йөртелгән (үзем аны җидегән дип атыйм) борынгы уен коралын да ясыйм. Татар музыка сәнгатендә әһәмиятле уен коралы ул! Аңа охшаш инструментлар Кытай, Япония, Вьетнам, Монголия, Корея, Алтай һ.б. Көнчыгыш халыкларында бар.



– Рамил хәзрәт, каллиграфия сәнгате күргәзмәләре белән танышканда нинди уй-хисләр кичерәсез?

– Илебездә мондый сәнгать төрендә иҗат итү күп еллар юкка чыгарылып торды бит, шул сәбәпле бу юнәлеш бик алда дип әйтә алмыйм. Башка дәүләтләрдә иҗат ителгән каллиграфия әсәрләрен күп күргәнгә һәм биредәге каллиграфия яки шәмаил сәнгате (ә шәмаил белән хатт сәнгате (каллиграфия) – икесе ике төрле нәрсә) бәйгеләрендә жюри эшендә катнашканга күрә, бу нисбәттән анык фикерем тупланды. Кызганыч, кайбер күргәзмәләребездә өйрәнчеклек дәрәҗәсенә якын эшләр дә куела, ә бу үз чиратында халыкта «каллиграфия сәнгатенә бик тиз, җиңел төшенеп-өйрәнеп була икән» дигән фикер тудыра. Өстәвенә, шундый эшләр аркасында халык зәвыгы да аксый башлый.

Безнең илдә гарәп каллиграфиясе мәчетләр бизәүдә, китап тышлыкларын язуда, логотиплар, тугралар ясауда гына кулланышта. Иран, Төркия кебек мөселман илләрендә исә мондый традицияләр гасырлар буе бер дә өзелмичә дәвам иткәнгә күрә, каллиграфия сәнгате бик алга киткән. Бездәге шәмаил язучылар бу сәнгатькә гадиләштереп карый кебек... Чит илләрдә каллиграфия ул тулы бер фән һәм ул мөселман сәнгатьләре арасында иң катлаулысы санала.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ӘСӘЙ АВЫЛЫ

Азнакай районының бай тарихлы авыллары арасында Әсәй үзенең гадәти булмаган исеме белән аерылып тора. Авыл картларының хәтерендә сакланган риваятьләрнең берсе бу урынга беренчеләрдән булып Әсәй картның килеп утыруы турында сөйли. Димәк, шундый исемле кешенең булуы шик уятмый. Әсәй – Исәкәй (Әсәкәй) исеменең диалекталь варианты. XVII-XVIII гасыр чыганакларында татарлар арасында мондый исемле кешеләр күп очрый. Авылга нигез салучының исеме дә – Әсәй.

● Әсәй авылы.

Ул кайдан һәм кайчан әлеге төбәккә килеп утырган? Риваятьләрнең берсендә Әсәйнең якындагы Имән авылыннан килүе турында әйтелә. Мондый атамалы авыл (ул Иске Имән дип йөртелә) Сарман районында. Авылга нигез салучының шуннан булуы ихтимал. Болай фикер йөрткәндә, без аз билгеле бер документка таянабыз. «Татарстан» журналында (1994 ел, № 7-8) басылып чыккан ул язма белән күпләр таныш булмаска да мөмкин. Шунлыктан документның Әсәйгә кагылышлы урынына тукталыйк.

Башкортстан Милли архивында саклана торган бу документның тулы исеме – «Дело об установлении родопроисхождения и исключения из подушного оклада Юсупова Тимиркея». Анда Оренбург губернасы Минзәлә өязе Катысаз (Имән) авылы (Иске Имән элек шулай аталган) кешесе Тимеркәй Йосыповның 1798 елның 13 июлендә губерна хакимиятенә язган гаризасы теркәлгән. Ул анда түбәндәгеләрне яза (текст оригиналдагыча бирелә): «[...] я происхождения рода башкирского по которому и оказалась, что я справедливо башкирскому роду ибо прапращер мой Байрамгузя пращур Аккузя, прадед Исяк и Кушай есть настоящия башкирцы. Но дед мой Уразман и отец Юсуп как я остался малолетним какими путями попались в ясашной оклад я уже неизвестен. Отца ж моего Есупа брата родной Абиш Уразманов состоит и поныне 3детьми своими как и в родословной значится в башкирцах, а я в подушном окладе [...], доказательством служит, что я имею во владении своем землю по грамоте во 104 года (1596/97 гг. –Т.К.) прапращеру моему Байрамгузе жалованную...» (БР МА, И-2 фонд, 1 тасв., 13 сакл. бер.).

Әлеге гаризадан аңлашылганча, Тимеркәй Йосыпов үзен привилегияле башкорт сословиесенә кайтаруларын сорый. Документта безнең өчен әһәмиятлесе шул, анда Т. Йосыповның ерак бабаларыннан берсе булган Исәк телгә алына. Исәк (Исәкәй яисә Әсәкәй) – 1596-97 елларда грамота нигезендә җир алган Бәйрәмхуҗаның оныгы. Ул чама белән XVII гасыр урталарында туган булырга тиеш. Шул гасырның икенче яртысында Исәкнең кайдадыр җир алуы мөмкин. Әгәр дә аның зур биләмәсе хәзерге Әсәй авылы урынында булса, яңа барлыкка килгән авылның аның исеме белән Әсәкәй яисә Әсәй дип атала башлавы гаҗәп түгел. Шундый фараз кылсак, Әсәйгә XVII гасырның икенче яртысында нигез салынган булып чыга.

Авылның башлангыч чорына ачыклык кертүче икенче документ 1840 елның 19 мартында төзелгән. Анда Әсәй авылы «типтәр»ләре (ир-атлар – 218 кеше) турында «жительствуют по припуску башкир без всякого документа более 150 лет» (Малоизученные источники по истории Башкирии. – Уфа, 1986. С. 89) дип әйтелә. Димәк, бу документ та авылның XVII гасырның икенче яртысында нигезләнүенә ишарәли.

Өченче документ авылның беренче мәчете турында. Ул 1704 елда ук төзелә, хәтта XX гасыр башында да исән була (БР МА, И-295фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.).

Югарыда телгә алынган документлар түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Беренчедән, Әсәй авылы XVII гасырның икенче яртысында нигезләнгән. Ике документ белән дәлилләнгән бу факт шик уятмый. Икенчедән, Әсәй карт бу урында беренчеләрдән булып яши башлый һәм авыл шуңа күрә аның исеме белән йөртелә. Әлеге кешенең нәкъ Бәйрәмхуҗа карт оныгы булуы мөмкин. Чөнки Әсәй яшәгән чор белән авылга нигез салынган чор үзара тәңгәл килә. Бу фикергә өстәмә дәлил итеп Әсәйнең башкорт сословиесендә булуын да өстәргә кирәк. Ә бу сословие кешеләре авылда беренчеләрдән булып яши башлый.

XVII гасырның икенче яртысында нигезләнсә дә, Әсәй авылы телгә алынган иң борынгы чыганак 1729 елга карый. Патша хакимияте вәкиле сорау алганда Дусай-Кичү (хәзерге Минзәлә районында) авылы татары Чирү Теләшев җан башыннан түли торган салым («подушный оклад»), ә Әсәйдә «типтәр ясагы» түләве турында әйтә (чыганакта болай язылган: «допросом показал, что он Чирю во оной деревне Досай Кичю в подушной оклад також и в Уфимском уезде в деревне Асаевой написан в одну куницу в тептярский ясак»). Шул ук сүзләрне аның авылдашы Мөслим Ишбулатов та кабатлый. Алар Әсәйгә 1728 елда килеп утырган (РБАДА, 248фонд, 13 тасв., 712 сакл. бер.). Гасыр ахырында Әсәй авылы биләмәчеләре (вотчинниклары) арасында Мөслимов фамилияле кеше булуын искә алсак, соңгысы сословиесе буенча



● Әсәй авылы ясаклы татарлары теркәлгән 1762 елгы документ фрагменты.

«башкорт» булып киткән дип фараз кыла алабыз.

XVIII гасыр уртасында Әсәй авылы ясаклы татарлары Уфа өязе Казан юлы Юрмый волостенда күрсәтелә. Россия борынгы актлар дәүләт архивында сакланучы 1762 елның 2 июнендә төзелгән документта 47 ир-ат теркәлгән. Алар старшина Хасбулат Мөтеков командасында исәпләнә, яртысыннан күбрәген Мостафа (9 ир-ат), Нараты (7) һәм Сабай (8) авылларыннан күчеп килүчеләр тәшкил итә (Шунда ук, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл.бер.).

Ыкның уң ягыннан күчеп килүчеләр турында истәлек картлар хәтерендә бүгенгәчә саклана. Аерым алганда, бу хакта Гариф Харис улы Әхмәдиев (1904 елгы) күп мәгълүматлы булып чыкты. Аның истәлекләренә караганда, монда яшәгән авыл кешеләре арасында хәтта марилар да булган. Алар җирле халык белән яши-яши татарлашкан, үзенең дә ерак бабасы мари булган, имеш. Әмма бу риваять архив документлары белән расланмады.

Башкортстанның Бакалы ягыннан татарларның күпләп бу тирәләргә күчүенең җитди сәбәбе була. 1736 елда Нугайбәк крепосте төзелгәч, урыс миссионерлары тирә-як халыкны көчләп христиан диненә күчерү буенча актив эш алып бара. Ә инде крепостька әледән-әле җибәрелеп торган чукындырылган кавемнәр өчен урындагы халыкның уңдырышлы җирләрен тартып алып бирә башлыйлар. Дини кысу-мәсхәрәләүгә түзә алмаган татарларның бер өлеше хәзерге Азнакай районына күчеп утырган.

Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773-1775 еллар) башлану төбәктәге авылларга да кагылып үтә. Баш күтәрүчеләрнең отрядларына Юрмый волосте старшинасы Биккенә Яушев командасында торучы Әсәй ясаклы татарлары да кушыла (Крестьянская война на территории Башкирии. – Уфа, 1975. – С. 282.). Старшина үзе дә, улы Исмәгыйль Биккенин дә 1773 елның декабреннән алып 1774 елның апрелена кадәр яуда актив катнаша. Нугайбәк крепостендагы В. Торновка буйсыналар (Вахит Имамов. Татарлар Пугачев явында. – Яр-Чаллы, 1994. – Б. 466.).

1794 елның 1 октябренә караган документта Бүләк Таһиров, Алканай Айдашев, Баязит Мостаев, Габдул Карагулов, Габделшәфи Бакиров, Госман Карагулов, Имангол Карагулов, Габдерәхим Гобәев, Шәрип Карагулов, Мәхмүт Аккулов, Базан Мөслимов, Атлис Исәнбаев, Күгәш Исәнбаев, Тимерша Базанов, Бикташ Исәнбаевлар күрсәтелә. Болар Әсәйдә яшәүче биләмәчеләр (вотчинниклар) буларак телгә алына (БР МА, И-2фонд, 1 тасв., 7031 сакл. бер.). Биләмәчеләр булганлыктан, башка документларда сословиеләре «башкорт» дип язылa.

1795 елда авыл 35 хуҗалыктан тора. Халыкның төп өлешен «типтәр»ләр (моңарчы алар ясаклы татар сословиесендә иде; 94 ир-ат һәм 84 хатын-кыз), калганын «башкорт»лар (башкорт сословиесендәге татарлар; 43 ир-ат һәм 29 хатын-кыз) тәшкил итә (РБАДА, 1355 фонд, 1 тасв., 1874 сакл. бер., 287 б. а.-294 б. «ТЭ» Әсәйдә 1795 елда 250 ир-ат яши дип яза. Әсәй авылы буенча дөрес булмаган бу һәм кайбер башка мәгълүмат авторларның архив чыганакларын бөтенләй яисә тирән өйрәнмәве хакында сөйли). 1798 елда кантоннар оештырылгач, Әсәй«башкорт»лары 12 нче башкорт кантонында күрсәтелә. «Типтәр»ләр 5 нче типтәр командасына карый.

Авылның үсүе җир бүлүдә кыенлыклар китереп чыгара. Якын-тирәдә кулланылмый яткан җирләр калмый, ә волостьның башка буш җирләре авылдан ерактарак урнашкан була. «Типтәр»ләр күпчелекне

тәшкил иткәнлектән һәм, өстәвенә, җан башына аларга җир азрак та таләп ителгәнлектән, аларны авылдан кузгатмыйлар, ә буш җирләргә азсанлы «башкорт»ларны күчерергә карар кылалар. Менә шулай XIX гасыр башында моннан күченүчеләр исәбенә икенче авыл – Карамалы барлыкка килә.

Башкорт сословиесендәге татарлар яңа урынга күченү белән, монда рәсми рәвештә «типтәр»ләр генә кала. Шулай да бер чыганакта 1816 елда Әсәйдә 2 хуҗалыкта 4 ир-ат «башкорт» яшәве хакында әйтелә, әмма шунда ук аларның ревизия исемлеге буенча Карамалыга караганы искәртелә (БР МА, И-1 фонд, 1 тасв., 450 сакл. бер., 124-126 б. Ә.Әсфәндияров 1816 елда 22 йортта 98 «башкорт» яши дип яза (Аулы мензелинских башкир. Уфа, 2009. С. 561). Әмма иң ышанычлы һәм бернинди бәхәссез чыганак – 7 нче ревизия документы (1816 ел) – Әсәйдә бары тик «типтәр»ләрнең генә теркәлүен күрсәтә). Димәк, болар күченгән саналса да, Әсәй авылыннан китмәгән.

1816 елгы ревизия мәгълүматлары аерым игътибарга лаек. Әсәй халкын типтәр сословиесендәге татарлар тәшкил итә. Алар 131 ир-ат һәм 141 хатын-кыз (48 хуҗалык) исәпләнә. Ревизия исемлеген хакимияткә үзенең имзасын куеп йөзбашы («сотник») Араптан Габдрахманов (63 яшь; өч хатынлы) тапшыра. 1814 елгы манифест нигезендә типтәр сословиесенә язылган, Оренбург казна палатасының 1818 елның 17 август карары белән читтән килеп утырган 2 ир-ат һәм 3 хатын-кыз (2 гаилә) аерым ревизия документында теркәлгән. Алар Ибәтулла Динмөхәммәтов белән Камалетдин Габбәсовның хатыннары һәм балалары дип күрсәтелә. Соңгыларын да кушсак, Әсәйдә типтәр сословиесендә барысы 133 ир-ат һәм 134 хатын-кыз (50 хуҗалык) була.

Бер чыганакта ир-атлар – 138, хуҗалыклар 50 дип күрсәтелә. Әмма югарыда күрсәтелгән ревизия документы төгәллеге белән аерылып тора, шуңа күрә аңа төп чыганак итеп карарга кирәк.

1859 елгы ревизия исемлеге буенча Әсәйдә типтәр сословиесендә 366 ир-ат һәм 381 хатын-кыз (50 хуҗалык) татар исәпләнә. Габделкадыйр Габделвәһапов – Кәтемгә, Мөхәммәтшәрип Габдулгалләмов – Сөендеккә (4 нче юрта), Габдерәхим Хәмитов – Туйкәгә күчеп утырган. Минһаҗетдин Гибәтуллин ясаклы татар сословиесенә язылып, 1855 елда Вятка губерниясенә күченә («по указу Самарской казенной палаты от 16 июля 1855 года № 3753 перечислен в Вятскую губернию в число государственных крестьян», дип әйтелә чыганакта). Соңгы булып Кәкре Елгадан указлы мулла булып килгән Шәрәфетдин Габделвахитов (42 яшь) теркәлгән. Бер гаилә 1863 елда Себергә сөрелә. Ревизия документының титул битендә барлык халык «башкорт» дип язылган. Чөнки «типтәр»ләрне 1855 елда «Башкорт» гаскәренә кушкач, алар «башкорт» («яңа башкорт») булып китә.

Типтәр сословиесендәге татарларны «башкорт» дип яза башлау Самара губернасы буенча белешмә китапларда да чагыла. Шуларның иң беренчесендә (1859 ел) Әсәйдә 381 ир-ат һәм 413 хатын-кыз (115 хуҗалык) «башкорт» күрсәтелә (Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. – С-П., 1864. С. 35.). Күргәнебезчә, 1859 елгы ревизия исемлеге белән чагыштырганда халык саны күбрәк язылган. Димәк, шул ел ахырында тагын бер тапкыр халык санын, яңа гына зур хуҗалыклардан аерылып чыгучыларны исәпкә алганнар.

Имана җире ревизия исемлегендәге ир-ат санына карап һәм сословиене күз алдында тотып бүленә, ул җан башына 6,9 дисәтинә туры килә. Бу чорда авылда имам һәм мөгаллим булып (1853 елдан) Әхмәтҗан Шаммасов тора.

1885 ел ахырында –1886 ел башында Әсәй Азнакай волостенда зур авыллардан санала. Анда 238 хуҗалыкта 629 ир-ат һәм 629 хатын-кыз яши. Бу күрсәткечләр буенча ул волостьта бары Азнакайдан һәм Сәпәйдән генә калыша.

Авылның иманасы 2942,5 дисәтинә тәшкил итә. Шуның 716 дисәтинәсен –

● Әсәй авылы мәчете.

сөрүлекләр, 489,8 дисәтинәсен – йорт яны җирләре һәм көтүлекләр, 382,3 дисәтинәсен – урман һәм 66 дисәтинәсен печәнлекләр алып торган. Моннан тыш, 3 хуҗалыкның сатып алган җире (300 дисәтинә) була.

Авылда 233 хуҗалыкның имана җире була. Әмма аның күләме, хуҗалыкларга карап, нык аерыла. Күпчелек хуҗалыкларның (136) имана җире – 6,9 дан 12,8 гә, ә 16 хуҗалыкның исә 12,9 дисәтинәдән 20,7 дисәтинәгә кадәр булган. 20,8 дисәтинә һәм аннан күбрәк җирле хуҗалыклар аз (6). Хуҗалыклар арасында сөрүлек җирне һәм печәнлекләрне арендага алу киң кулланыла. Барлыгы 208 хуҗалыкның 150 дисәтинә сөрүлекне арендага алуы мәгълүм. Җир хуҗалары яисә казна (әгәр дә җир аныкы булса) белән исәп-хисап, гадәттә, акчалата башкарылган. Мәсәлән, печәнлекләрне арендага алган өчен генә дә Әсәй кешеләре 1390 сум акча түли.

Авылда 182 хуҗалык эш кораллары белән тулысынча тәэмин ителгән. Ә менә 28 хуҗалыкта исә алар өлешчә генә була. Мондый һәм бөтенләй эш кораллары булмаган (19 хуҗалык) хуҗалыклар аларны башкалардан нинди дә булса шартларга үзара килешеп алып торган.

Әсәйдә 37 хуҗалыкның эш атлары бөтенләй булмый. Күп кенә хуҗалыкларда (79) алар бердән артмый. Шул ук вакытта башкалары ике-өч (78 хуҗалык), дүрт (16) һәм дүрттән күбрәк эш атлары тоткан.

Эш атларын гына түгел, башка мал-туарны да авыл халкы күп асраган. Хуҗалыкларда мөгезле эре терлек 487, сарыклар 1181 һәм кәҗәләр 420 баш исәпләнә. Әмма 36 хуҗалыкның эш аты да, сыеры да булмый. Андыйларга авылда көн итү шактый авырга төшкән.

Кайберәүләргә гаиләләрен туйдыру һәм салым түләү өчен үз хуҗалыкларының гына кереме җитми. Шунлыктан алар кыр эшләре вакытында төрле эшләргә ялланган (59 кеше) яисә һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. 16 хуҗалык 102 баш умарта тоткан.

Авылда бернинчә хуҗалык сәүдә иткән. Азнакай волостенда (ул Азнакай, Балтач, Сәпәй, Туйкә, Уразай, Әгерҗе һәм Әсәй авылларыннан торган) тугыз лавка булса, шуның өчесе Әсәйнеке. Кибет хуҗалары күпчелек товарларны Сәпәй базарыннан һәм Бөгелмәдән алып кайткан.

1889 елда Әсәйдә 241 хуҗалыкта 1225 кеше яши. Авылда 2 мәчет була. Аларның берсе 1858 елдан соңгы чорда төзелгән. Уңайлы җирләр – 2794, эшкәртергә яраксызлары (чокырчакыр, ташлы урыннар һ. б.) 150 дисәтинә тәшкил итә.

Гасыр ахырына (1897 ел) Әсәйдә хуҗалыклар саны шактый арта. Анда 279 хуҗалык, 719 ир-ат һәм 731 хатын-кыз исәпләнә. Бу күрсәткечләр буенча ул волость үзәге Азнакайдан гына калыша.

Авылда 2 мәчет һәм мәктәп эшли. Мул сулы Стәрле елгасында авыл кешеләре 3 тегермән тоткан. Тегермән хуҗалары – Әхмәтҗанов, Зәбиров һәм Габделкәримов (Список населенных мест Самарской губернии. – Самара, 1900. С.111-112.).

Югарыда телгә алынган кешеләрнең икесе – Әхмәтҗанов һәм Габделкәримов турында Татарстан дәүләт архивында сакланган 1900 елгы документлар өстәмә мәгълүмат бирә. Шуларның Әхмәтшакир Әхмәтҗановка караганына тукталыйк. 1900 елда аңа 29 яшь була. Хатыны (28 яшь), балалары (4 улы һәм 1 кызы), анасыннан (55 яшь) башка, хуҗалыгында энесе (25 яшь) һәм аның хатыны (19 яшь) да яши. Анасыннан кала, өлкәннәрнең барысы да укый-яза белгән. Стәрле елгасындагы тегермән авылдашы Якуп Җәләлетдинов белән икесенеке, ягъни уртак була. Ул сәүдә белән дә шөгыльләнә, лавка тота.

Әйтергә кирәк, Әхмәтшакир Әхмәтҗановның хуҗалыгы зурлыгы ягыннан башкалардан аерылып торган. Имана җире аз булу сәбәпле, ул шактый җирне сатып яисә арендага ала. Имана җирендә чәчүлеге – 5 дисәтинә 1500 кв. сажин, арендага алган басуда 49 дисәтинә 1500 кв. сажин тәшкил итә. Сатып алган җире 100 дисәтинәдән торган утар була. Бу утарның 52 дисәтинәсен – басу, 10 дисәтинәсен – мал йөртү урыны, 24 дисәтинәсен – печәнлек, 22 дисәтинәсен урман алып торган. Шакир бай күп санлы мал-туарын (19 эш аты, 33 мөгезле эре терлек, 80 сарык һәм 6 кәҗә) яз, җәй һәм көз айларында шунда асраган. Мондый зур хуҗалыкны алып бару күп хезмәт куюны сорый, шунлыктан ул 4 хезмәтче тота һәм һәр җәйне көтүче яллый. Болардан тыш, кыр эшләре вакытында дистәдән артык ир-ат һәм хатын-кыз Шакир байга ялланып эшләгән. Кайбер ярлы хуҗалыклар аның сыерларын (7 баш) сөте бәрабәренә ашатырга-карарга алып торган. Сыерларның бозаулары булса, алар хуҗаныкы исәпләнгән һәм аңа тапшырылган.

1900 елгы документларда тегермән тотучылар арасында 1897 елда телгә алынган Зәбиров фамилияле кеше күрсәтелми. Аның тегермәне улларына мирас булып күчкән, ахры. Исәп буенча өченче тегермәнне Латыйф Исмәгыйлов (43 яшь) үзенең 3 авылдашы (берсе Мотыйгулла Исмәгыйлов) белән тоткан. Тегермәндә һәм зур булмаган хуҗалыгында берәр хезмәтчесе була.

1900 елда авыл элеккечә ике мәхәлләдән тора. Муллалар Шәрәфетдин Вахитов, Әхмәтша Әхмәтҗанов һәм Мөхәммәтгәрәй Садыйков, мәәзиннәр Гәрәйша Шәрәфетдинов һәм Латыйфулла Әхмәтҗанов була.

Шәрәфетдин Вахитов муллалар арасында иң өлкәне – аңа 90 яшь, хатынына – 75 яшь. Алар улының (43 яшь) гаиләсе белән бер хуҗалык булып яши. Хуҗалыгы, башка муллаларныкы белән чагыштырганда, зурлыгы белән аерылып тора. Имана җирендә 9 дисәтинә, үз авылдашларыннан арендага алган басуда – 4 дисәтинәгә якын, башка урында 8 дисәтинә чәчүлекләре була. Алар 8 эш аты, 6 сыер, 30 сарык һәм 5 кәҗә асрый. Шундый зур хуҗалыкны алып бару өчен хезмәтче тоталар, ә кыр эшләре вакытында алтмышлап көнлекче ялларлар.

58 яшьлек Мөхәммәтгәрәй мулла документта сукыр дип күрсәтелә. Мәәзиннәрдән Гәрәйшага – 48, Латыйфуллага 41 яшь була. Алар мал-мөлкәте ягыннан урта хәлле авылдашларыннан әллә ни аерылмый.

Гарифулла Хәйруллин ул чорда авылның старостасы булып тора. Аның үзенә – 30, хатынына 25 яшь; аларның ике уллары була. Яңа гына өйләнгән энесе (26 яшь) хатыны белән аларның йортында яши. Ә бер энесе (21 яшь) солдатка алынган була. 60 яшьлек Сәрвәли (?) Җиһаншина документта укытучы дип күрсәтелә. Ул ялгызы яши, мал-туар тотмый. Укытучылык аның төп яшәү чыганагы булып тора.

Төрле һөнәрләр белән шөгыльләнүчеләрнең күпсанлылыгы күзгә ташлана. Алар арасында таш чыгаручылар һәм эшкәртүчеләр дә була. Мондый төр һөнәрчеләр булу аркасында башка төзелеш материаллары (агач, кирпеч һ. б.) белән беррәттән, таш та еш кулланыла башлый. Таштан амбарлар һәм башка каралтылар салу гадәти күренешкә әйләнә. Башка төр һөнәрчеләр арасында балта осталарын, пыялачыларны, киез итек басучыларны, тегүчеләрне, чабатачыларны, тимерчеләрне әйтеп үтәргә кирәк.

Шунысына игътибар итик, югарыда күрсәтелгән кешеләрнең күпчелеге өчен һөнәрчелек төп яшәү чыганагына әйләнгән, шуңа күрә алар моның белән ел буе диярлек шөгыльләнә. Гадәттә аларның җирләре аз яисә бөтенләй юк, мал-туарлары да шундый дәрәҗәдә. Мәсәлән, киез итек басучы Әхмәтгәрәй Ситдыйковның алыйк. Аның мал-туары юк, ә чәчүлек җире ташка үлчим, бер дисәтинәдән аз гына арта.

Кайбер һөнәрчеләр иманаларының зур өлешен арендага бирүне кулай күргән. Моның өчен алар, әлбәттә, хак алган, ә үзләре исә күп вакытларын һөнәрләренә багышлаган.

Авылда аз җирле хуҗалыклар күп була. Андыйларның бер өлеше 8 нче санлы Чалтаймас казна участогыннан 9 елга һәм алпавытлардан (Пискунов, Докшин) бер елга арендага җир алган. Пискунов арендачыларга үстергән уңышның яртысын («исполу») аңа бирү шартын куйган. Азнакайдан, Урманай, Митрәй, Карамалыдан һәм кайбер башка авыллардан да арендага җир алучылар була.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Мәдәни җомга
31 март
№12, 2023

Казандагы М.Җәлилнең музей-фатирында Шаһинур Мостафинның тууына 75 ел тулуга багышланган искә алу кичәсен уздырдылар. Ни кызганыч, Шаһинурга карата да «искә алу» сүзе әйләнешкә кергән. Ул һәрвакыт янәшәбездә булды, үзе турында түгел, күбрәк башкалар хакында кайгыртып, гамьләнеп йөрде. Бөтен гомерен сугыш каһарманнарын, затлы кешеләр язмышын кайгыртып, батырлыклары һәм кылган гамәлләренә бәрабәр итеп бәяләүгә нигез булырлык мәгълүматлар эзләп уздыры һәм бу өлкәдә зур табышларга юлыкты. Тырышлыгының нәтиҗәләрен күреп, үзе дә сөенде, замандашларын да куандырды.

Һәрвакыт янәшәдә кебек

(Шаһинур Мостафинның тууына 75 ел тулу уңаеннан)

● Мамадыш шәһәрендә Шаһинур Мостафинга 70 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсеннән.

Мин аны Кукмарада эшләгән вакытыннан беләм. Ул аңа кадәр, Казан университетында югары белем алып, башта Мамадыш район газетасында хезмәт иткән. Тормыш юллары Кукмарага китереп чыгарган. Монда аны оста һәм үткен каләмле журналист дип таныдылар. Аның каләменнән төшкән мәкаләләр, әсәрләр укучыларны «Хезмәт даны» газетасына җәлеп итте. Алай гына да түгел, бирердә ул үзенә кадәр күп еллардан бирле Гали Галиев, Нур Идрисовлар җитәкчелек итеп килгән әдәби түгәрәккә шифалы сулыш өрде. Шаһинур аны «Салават күпере» дигән әдәби берләшмә итеп үстерде. Күрше Нократ Аланы районының Түбән Шөн авылында туып-үскән танылган әдибә Ләбибә Ихсанованы да берләшмә эшенең иҗади ягына җитәкчелек итүгә җәлеп итте. С.Хәким, И.Юзеев, Г.Ахунов, Ш.Рәкыйпов кебек остазларны башлап язучылар белән очрашуларга чакыруны гамәлгә кертте. Нәкъ шушы елларда бирердән Рәшит Бәшәр, Газинур Морат, Рифә Рахман, Заһид Мәхмүди кебек талантлар үсеп чыккан икән, монда аларны вакытында күрүче, иҗади мохиткә якынлаштыручы Шаһинурның да өлеше бар.

Башта без аны газетадагы шушы уңышлы башлангычлары буенча белдек, тора-бара үзе белән дә таныштык. Кап-кара бөтеркә чәчле, озын буйлы бу журналистның барып чыкмаган авылы, оешмалары калмагандыр.

Минем Татарстан радиосында диктор булып эшләгән вакытым иде. Үзем укыган Пычак мәктәбенә очрашуга чакырып кайтардылар. Район газетасы хезмәткәре Шаһинур да килгән. Мәктәп директоры Каим абый Җиһаншин безгә бер хат күрсәтте. Аны Казанның тарихчы галим Сәләм Алишев җибәргән. «Сезнең авылда Пугачев армиясендә полковник булган Мәсәгут Гомәровның нәсел тамырлары бармы икән? Ул Пычак авылыныкы бит. Аның хакында берәр мәгълүмат саклангандырмы? Хәер, үзем дә сезнең тарафка барып чыгарга җыенам. Тарих фәне өчен бик кызыклы яклар». Мин Сәләм абыйның Пугачев хәрәкәте турындагы кайбер язмалары белән таныш, әле күптән түгел ул үзенең эзләнү нәтиҗәләре турында безнең радиодан да чыгыш ясаган иде. Үз вакытында А.Пушкинның «Капитан кызы», С.Злобинның «Салават Юлаев» әсәрләре дә укылган. Шаһинур да ул чор кешеләренең көрәшеннән шактый хәбәрдар. Чөнки М.Гомәров һәм аның тарафдарлары Мамадыш төбәге тарихында да эз калдырган. Безнең, Каим абый белән фикер алышу өчен, күпмедер хәбәрдарлыгыбыз бар иде. Сөйләшүебезнең төп юнәлеше, С.Алишев, В.Имамов кебек галим һәм язучылар белән киңәшеп, М.Гомәров һәм аның замандашларының истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә гамәли адымнар ясау мәсьәләсенә кайтып калды. Шаһинур да кайнар эздән тарихи мәгълүматларга нигезләнгән язмаларын тәкъдим итте. Каим абый белән мин дә үз сүзләребезне җиткерә тордык. Район җитәкчелеге дә моның әһәмиятен аңлады. Мәктәп бакчасында М.Гомәровка багышланган обелиск пәйда булды. Бу хәл Пычак мәктәбендә укытучылар һәм укучыларны да эзләнүләргә җәлеп итүне күздә тотты.

Әлеге тантана барышында игътибар иттем: Шаһинурның канәгать булуы йөзенә чыккан иде. Димәк, нәрсәгә дә булса иң әүвәл үзең ышансаң, аннан соң башкаларны да фикердәшләрең итеп әверелдерә алсаң, әнә нинди башлангычларны чынбарлык итүгә ирешергә мөмкин икән ич. Менә шундый уңай нәтиҗәләр аны эзләнүләргә канатландырып җибәрде. Мамадыш, Кукмара кебек зур төбәкләрдә узган чорлардагы каһарманнарны барлау, аларның исемен халыкка кайтару юлында ул төп эзләнүчеләрнең берсе һәм аларның батырлыгы турында үтемле итеп язучы буларак танылды.

Шаһинур кешеләр белән аралашырга ярата, алар белән үз итеп сөйләшү аның үзенә дә канәгатьлек бирә. Мондый чакларда мин аның үзен күзәтергә яратам. Әйтик, ул яңа күргән кеше белән болай сөйләшә башлый:

– Гафу итегез, исемегезне онытып җибәргәнмен...

Сүз арты сүз китә, мәгълүматлар куен дәфтәренә күчә бара. Эре-эре хәрефләр белән кыеклатып яза. Блокнотлар – Шаһинурның мәгълүмат байлыгы. Аның андый дәфтәрләре йөзләрчә булырга тиеш. Ул алардан кирәкле фактларны табып, хикәяләренә, очеркларына, истәлекләренә кертеп җибәрә. Шулар ярдәмендә күпме кешенең сугышчан юлын, тормыш сукмакларын ачыклый. Күпләр үзенең ялын көньяктагы савыгу, дәвалану урыннарында уздыра, Шаһинур Әхмәтсафа улы исә, Подольскидагы хәрби архивка барып, еллар тузанын җыйган кәгазьләрне, документларны өйрәнә, моны авырсынып түгел, йөрәге кушканга кинәнеп эшли. Берәр табышка юлыкса, үзен чын-чынлап бәхетле хис итә. Аның йөзләгән әсәрләре һәм язмалары документ белән расланган дөреслеккә корылган. Шул рәвешле, С.Шакир, Р.Мостафин, Ш.Рәкыйповлар башлап җибәргән эзтабарлык әдәбиятыбызны аеруча уңышлы дәвам иттерүче каләм иясе Ш.Мостафин булды. Бер үк вакытта ул «Казан утлары» журналы редакциясендә дә үзенең урынын тапты. Басманың илебез киңлекләренә таралган укучылары белән элемтәсен тәэмин итүдә җиң сызганып эшләде.

Татарстан язучыларының XIII корылтаенда берлек рәисе итеп сайлангач, миндә бу эшчәнлекне кемнәргә таянып алып барырга, дигән сорау туды. Уема иң әүвәл Ш.Мостафинның килүе очраклы түгел иде. Чөнки аның бик тә кирәкле сыйфаты бар – кешеләрне ярату һәм алар турында кайгырту. Моңа кадәр дә ул Р.Сибат, Р.Җамал, М.Каюмов, Р.Шәфи, Р.Шәрипов һ.б.га әдәби мохиттә булуга юл ачучы булды. Бигрәк тә Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында яшәүче Рафаэль Сибатның кульязмаларын Казанга алып кайтып, аларны төрле газета-журналларга урнаштырып, басылып чыгуларын кайгыртып йөрүе хәтердә калган. Кемгәдер үзенең ярдәме кирәклеген тоеп та гамьсез генә читтә калу Шаһинур холкына туры килми, берлектә шундый кешенең булуы кирәк иде. Уртак эшебезне уңышлы алып баруда Шаһинурның хезмәте бәяләп бетергесез булды.

Еллар үтә-үтә, Шаһинурның өстәл тартмасында басылуны көтеп яткан кульязмалары җыелган иде. Ул бер-бер артлы «Хәтер яктысы», «Яшәү яме», «Яңа меңьеллыкка очыш», «Җиләкле гомерем мизгелләре» кебек китапларын мәйданга чыгарды. Балалар өчен «Бака кашыгы», «Болынбикә апабыз» исемле китаплары аның нәниләр күңелен нечкә тоючы шагыйрь икәнлеген дә күрсәтте.

Шулай да Ш.Мостафин дигәндә, без аның сугыш кырларында ил азатлыгы өчен гомерен биреп сугышкан элгәрләребезнең фидакарьлекләре бәян ителгән әсәрләрен күз алдына китерәбез. Күпме әби-бабайларның, ата-аналарның, туганнарының газиз кешеләре язмышларын ачыклап, үзенә карата рәхмәт сүзләре ишетте ул. Мин аның эзләнү нәтиҗәләренең аеруча Кукмара төбәге кешеләренә куаныч китерүләренә шаһит булдым. Әйтик, рәсми рәвештә Ил каһарманы дигән исем алмасалар да, шундый ук батырлыкка барган исемле геройлар рәтендә урын алырга тиешле Битләнгер авылы егете Нух Идрисов, нәсел агачы тармагы шул ук авылга барып чыгучы Әхмәтгали Мөхәммәдиев язмышларын һәм кылган гамәлләрен нәкъ менә ул таныттты. Тумышы белән Югары Арбаштан булган Сәмигулла Кәримуллинны XXI гасыр буыннарына ачып бирүче шулай ук Ш.Мостафин иде. Утыз алты яшендә Смоленск өлкәсендә, матросовчылар батырлыгын кабатлап, һәлак булган бу якташыбыз бүгенге укучыларга Ш.Мостафин әсәрләре ярдәмендә мәгълүм булды. Татар егете Гази Заһитовның Рейхстаг өстенә беренчеләрдән булып Җиңү байрагын кадауда катнашкан каһарман булуын раслау да зур тырышлык, үҗәтлек таләп итте. Шаһитләр һәм документлар ярдәмендә шушы дөреслекне раслаучыларның да берсе Шаһинур иде. Аның эшчәнлегеннән һәм иҗатыннан мондый сәхифәләрне күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Шаһинур Әхмәтсафа улының алга таба планнары зур иде. Батырлыклары, ныклыклары белән күңелен илһамландырган затлар турында уйланып та язылмаган бик күп сәхифәләре калды. Бу изге юлда ул ялкынланып, янып яшәде. Быел 6 июньдә аның бакыйлыкка күчүенә ике ел тула. Әмма бүген дә аны арабызда кебек хис итәбез. Кылган хезмәтләре, язган китаплары һәрдаим үзен дә искә төшереп тора. Шулай, изге күңелле заттан игелекле эшләр кала. Бу аның халык хәтерендә яшәвен дәвамлы итә.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

«Мирас» – татар иле

Ниһаять, берничә ай буе планлаштырган очрашуга, шәһәр яны бистәсенә баруым. Капкадагы кыңгырауга басуга, ул ачылып китте һәм мин ишегалды аша дүрт катлы зур йортның эченә үттем. Бусагадан аягымны атлауга, шау-шулы балалар дөньясына эләктем. «Сөембикә, аягыңа ки. Башта Аяз чыксын, ашыкма. Рамазан, бир кулыңны!..» Тәрбияче апалары шау килеп бер төркем бәләкәчне урамга алып чыгарга әзерли. Рәхәтләнеп татарча сөйләшкән сабыйларга, апаларына карап сокланып торган арада «Мирас» татар эко-бакчасының хуҗабикәсе Айсылу ханым үзе дә өске каттан төшеп җитте, без аның эш бүлмәсенә уздык. Бу бакчада бернәрсә дә гадәти түгел: балалар да гүя дәү әниләренә кайткан оныклары... Аш бүлмәсендә яулыгын чөеп бәйләгән апалары тәмле исләр таратып нидер пешерә. Ишегалдына чыгып өлгергән балаларның куанныр оясы янында шат тавышлары ишетелә.

Хыялдагы кебек бу милли бакчаны башта күңелендә, аннары чынлыкта бар иткән чибәр ханым – Айсылу Илнур кызы Гарипова. Аңа нибары 30 яшь, иң зур байлыгы – өч баласы бар. Биектау районының Бөреле авылында туып үсә, рус мәктәбен тәмамлый. Әти-әнисе гаиләдә татарча сөйләшсә дә, бөтен күршеләре – руслар, Айсылу күңеленә ят мохиттә, Май чабуларны бәйрәм итеп үсә. Өлкән сыйныфларда укыганда, күңеленә нидер җитмәгәнен сизә үз кешеләрен, йөрәгенә якын дуслар эзли башлый. Тугызынчыны бетергән кызның «Сәләт» лагерена барып эләгүе дә очраклылык кына түгелдер. Нәкъ менә шунда ул үзенә татар рухы җитмәгәнен аңлый. Монда исә бөтен кеше татарча сөйләшергә тырыша... Айсылу үзенең дөрес җиргә килеп эләккәнен аңлый һәм гомерлек дусларын да таба. Ул арада ике ел мәктәп президенты булып торган Айсылуның югары уку йортына керер вакыты да килеп җитә. Кызның хыялы канатлы – президент булырга тели ул! Барлык президентлар шуннан чыкканга, башта аграр университетка бармакчы була, тик уйлый торгач, КИТТУ/КХТИның дәүләт муниципаль хезмәте белгечлеген сайлый. Уку еллары татарча Шаяннар-тапкырлар клубы тарихы белән үрелеп бара, 200-300 баланы бу уеннарга тарту, әзерләнүләр, чыгышлар... Аннары – Биектау районының Коркачык бистәсендә «Сәләт» аланын оештыру. Университетта укыганда, Айсылу намазга баса, яулык бөркәнә. Аннары – кияүгә чыгу, бер-бер артлы Зәйнәб, Йосыф, Маратның дөньяга килүе. Әлбәттә, аның сабыйларын кайчандыр үзе сусап яшәгән милли мохиттә, үз гореф-гадәтләребез, динебез буенча тәрбиялп үстерәсе килә. Ләкин җаны теләгән балалар бакчасын таба алмый, чөнки алар юк дәрәҗәсендә.

Айсылу башта үз өендә, аннары Биектауда бакча ачып җибәрә, тик анда мөселманча тәрбия булса да, татарлык читтәрәк кала. Нәтиҗәдә, бакча озак эшләмәсә дә, бу файдалы тәҗрибә була. Аннары хәләл ризык сату белән бәйле гаилә бизнесы башлап җибәрәләр, ләкин күп көч, финанс сарыф ителгән эш пандемия аркасында җимерелеп төшә, бизнесны ябарга туры килә. Кәефләре төшә, куллар салына... Гаилә дуслары белән киңәшләр дә, яшәү урыннарын үзгәртеп торырга – бераз Төркиядә яшәп кайтырга булалар. Анталиядә фатир яллап яшәгән ике ай вакыт бик файдалы була: карашлар киңәя, фикер сөрешләре үзгәрә. Анда Россиядән күп эшмәкәрләр белән танышалар. Айсылу гаҗәпкә кала: күпчелек читтән торып эшли, кышны җылыда үткәрәләр, бизнеслары да бара. Без бит исә барысын да кул белән тотып үзебез эшләргә өйрәнгән халык... Казанга күтәренке кәеф, саф баш, яңа фикерләр белән кайтып төшәләр. Яңа сулыш ачылып киткәндәй була. Айсылу ел буе хиҗама белән шөгыльләнә. Тик тыныч кына яшәсә, җиңел сөякле Айсылу буламыни ул? Үзе дә милли бакча ачу идеясе белән янган дус кызының «коткы»сы уңдырышлы туфракка төшә – күңелдә йоклап яткан очкыннар яңадан кабынып китә. Әлбәттә, уң кулы – ире. Үзенең төзелеш өлкәсендә эше булса да, Айсылуның йөрәк җимеше булган «Мирас»ка аякка басыр өчен булышырга вакыт таба. Ул янәшәдә булмаса, 600 кв метрлы бинаны, 15 сутый җирне карап тәртиптә тотуы кыенга туры килер иде. Айсылу әзер бизнес сатып ала, ул чакта хосусый бакчага нибары 9 бала йөри, күбесе – рус балалары. Монда алга таба татар бакчасы булачагын, дини юнәлештә дә тәрбия биреләчәген белгәч, яртысы китә. Акрынлап балаларына татар мохитендә, гореф-гадәтләребез, динебез кушканча тәрбия бирүне мөһим дип санаган әти-әниләр сабыйларын китерә башлый. Хәзер монда шәһәрнең төрле почмакларыннан бер яшьтән алты яшькәчә 47 бала йөри, Биектаудан, Лаештан китерүчеләр дә бар. «Мирас» – эко-бакча, монда сабыйларга экологик тәрбия дә бирелә. Шәһәр читендә булгач, һава да саф, җиргә басып, йөгереп рәхәтләнәләр. Ике парниклары бар. Февральдә балалар борыч, помидор, кыяр, кәбестә чәчәләр, тишелеп чыкканнарын күзәтәләр. Апрель-майларда парникка күчерәләр. Җәй буе су сибәләр, чүп утыйлар. Август-сентябрьләрдә эшләрләренең нәтиҗәсен күрәләр: эре-эре помидорларны үз куллары белән өзеп, аш пешерүче апаларына кертеп бирәләр. Җәй буе ишегалдында батут тора, рәхәтләнеп сикерәләр. Һәр көнне иртән бассейнга җылы су тутыралар. Балалар җәй буе кәҗә, йорт куяннары карыйлар, тавык йомыркаларын үзләре җыеп алып керәләр. Бакчадагы слива, алманы җыеп, ел буена җитәрлек итеп компотлар, джемнар әзерләп куйганнар, аш-су остасы апалары хәтта кыяр да тозлаган. Көз көне әти-әниләрне чакырып, бергәләп өмә ясап, уңыш җыйганнар. Кар яугач исә, әти-әниләр килеп, чана шуарга таулар ясап биргән. «Бездә балалар үзләрен әбиләрендә кунакта кебек хис итәләр: Айсылу апага, йә Люция апага кунакка барам, дип сөйләшәләр. Монда чабыр, йөгерер өчен урын иркен булгач, балалар бакчадан арып-талып кайтып китәләр», – ди Айсылу елмаеп.

Барлык таләпләргә җавап биргән тәрбиячеләрне табу да җиңел эш түгел.

Шөкер, бүген эшлибез дип торган, татарлыкны саклаучы, динебезне хөрмәтләүче коллектив җыелган. Төп максатлары – яшь буынга халкыбызның рухи байлыгын, мирасын тапшыру. Ашчы апалары да ризыкны «бисмилләһ» әйтеп кенә пешерә, сабыйлар ашаганчы да, ашагач та дога кылалар. Кичә исә балаларга пәрәмәч пешерергә өйрәткәннәр, нәниләргә бик ошаган. Ахырдан тәмле пәрәмәчләр белән бергәләп утырып чәй эчкәннәр. Барлык дәресләр, уеннар да татарча алып барыла.

Без сөйләшеп утырганда, янибызга нәни Йосыф кереп «ашыйсы килә!» дип игълан итте. Әле өйлә вакыты җитмәсә дә, Айсылу аны аш бүлмәсенә, Люция апасы янына кертеп җибәрде. Сабый аннан кулына кишер таякчыклары тотып килеп чыкты.

«Мирас»ка быел февральдә бер яшь тулган. Ул – татарлыкның нинди заманча, янача, сыйфатлы, затлы була алуына шәп бер мисал. Һәм аны киң карашлы, фикерле, иманлы, булдыклы ханым барлыкка китергән. Бүген баланы татар итеп үстерү җиңел эш түгел. Ә Айсылу менә шушы җиңел булмаган юлны сайлаган. «Эшлисе эшләрем шундый күп, кайвакыт әле мин берни дә эшләмәгәнмендер кебек тоела», – ди ул. Иң зур хыял – «Мирас» татар мәктәбен ачудыр, мөгаен. План буенча, «Мирас»ка бала бер яшеннән килә һәм университетка кадәр белем алырга тиеш. Тормышта үз юнәлешеңне табарга ярдәм итә торган, телефоннарсыз, барлык фәннәр татар телендә укытыла торган мәктәп... Иң зур проблема – укытучылар табу. Тик бу хыялның да чынга ашасына ышанасы килә. Дәүләт тарафыннан балаларны үз телебездә укытырга мөмкинлек тудырылмаган бу заманда авыр йөкне үз җилкәсенә салырга курыкмаган Айсылулар безгә һава кебек кирәк. Ә президент булу турындагы хыялга килгәндә, ул инде чынга ашкан: Айсылу үзе төзегән кечкенә генә «ил»нең президенты һәм анда татарны татар итеп саклар, үстерер өчен барлык шартлар тудырылган.

Эльмира СИРАҖИ.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

1 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 13.05 сәгатьтә калка, 13.03 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.03 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Суганлы алма суы

Ютәлдән мондый чара булыша: 1 алманы һәм кабыгы белән 1 баш суганны яхшылап юып, 4-8 кисәккә бүләләр, 1литр суга салып, суган йомшарганчы пешерәләр, берничә катлы марля аша сөзеп, сыгалар, көн буена эчеп бетерәләр (эчкән саен гел җылытып алырга кирәк).

2 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 11нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 14.23 сәгатьтә калка, 5.38 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.08 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Кабак сихәте

Кабакның өске өлешен кисеп, эчендәге орлыкларын алалар һәм шикәр салалар. Кире шул "капкачы" белән томалап, тирән савытка куялар һәм кабыгы йомшарганчы тоталар. Аннан соң кабак эчендәге бар нәрсәне банкага агызып, суыткычка куялар. Балга охшаган эчемлекне кайчан телисең, күпме телисең – шулкадәр эчәргә ярый, ул бавырны бик шәп дәвалый.

3 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 15.41 сәгатьтә калка, 5.45 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.13 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Озын гомер сере

Озын гомерле һәм сәламәт буласың килсә, менә бу 5 киңәшне хәтереңнән чыгарма: 1) үпкәләмә; 2) көнләшмә; 3) кичерә бел; 4) йөрәгеңне авыр уйлардан арындыр; 5) һәр көнгә сөенеп яшә.

4 апрель (сишәмбе). ***Рамазан аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 16.58 сәгатьтә калка, 5.52 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.17 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Гаймориттан дәва

2 бүлем сарымсак һәм ярты баш суганны вак кына турап, өстенә әз генә үсемлек мае салалар, 2 атна төнәтәләр. Аннары 2 атна дәвамында көненә 5 тапкыр һәр борын тишегенә 2 шәр тамчы тамызалар. Яисә 1 чәй кашыгы яхшы сыйфатлы яшел чәйне1 стакан кайнар суда пешерәләр, сөзәләр, шул җылымса чәй белән көненә 7 тапкыр борынны юдыралар (кечкенә спринцовка яки шприц ярдәмендә), ә төнгелеккә пипетка белән һәр борын тишегенә 3-4 әр тамчы тамызалар. Яисә алоэ һәм канлы үлән яфрагы сокларын, балны тигез микъдарда кушып, хроник гайморит интектергәндә көненә 4 тапкыр һәр борын тишегенә 5-10 ар тамчы тамызалар.

5 апрель (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 18.17 сәгатьтә калка, 5.57 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.22 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

6 апрель (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 19.38 сәгатьтә калка, 6.03 сәгатьтә бата. 7 сәгать 34 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 13.26 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Имән кайрысы, ромашка...

3 өлеш имән кайрысы, 2 өлеш ромашка, ярты өлеш канлы үләнне кушып, шуның 1 аш кашыгын 200 мл кайнар суга салалар, капкач ябып, 1 минут кайнатып алалар, 7 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, 4 тигез өлешкә бүлеп, көн дәвамында эчеп бетерәләр. Геморрой интектергәндә хәлне җиңеләйтү өчен, 1 атна буе шулай дәваланалар.

7 апрель (җомга). ***Рамазан аеның 16нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 21.03 сәгатьтә калка, 6.10 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.31 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Баллы прәннек

2 йомырка, дүрттән өч стакан шикәр, 160 г бал, чирек стакан үсемлек мае, дүрттән өч стакан каһвә (2 чәй кашыгы эри торган каһвә+кайнар су), ярты чәй кашыгы дарчин, 1 чәй кашыгы сода, ванилин, 2,5 стакан он кирәк. Каһвәне пешереп, суыталар. Йомырканы шикәр һәм ванилин белән күпертәләр, үсемлек мае, каһвә, бал, дарчин (төелгән имбир белән мөшкәт чикләвеге булса, аларны да), сода, он өстәп, туглыйлар. Формага агызып, 175 градуслы газ мичендә 30 минут чамасы пешерәләр. Пешеп чыккач, өстенә шикәр оны сибәләр.

Мусага ураза әмере

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам Исраил угыллары белән бергә Мисырдан китеп, дошманнан котылгач, өммәтенә Аллаһ катыннан бер китап иңдереләчәген хәбәр итә. Муса галәйһис-сәлам Һарун галәйһис-сәламне үз урынына вәкил итеп калдыра: «Син боларның ялгыш гамәлләрен төзәт! Мин Аллаһның әмере белән Сина тавына китәм. Анда утыз көн ураза тотачакмын. Аллаһтан иңәчәк яңа Китап белән кайтачакмын!» – ди. Ләкин рәхмәтсез кавеме: «Яныңда безнең арадан шаһитләр булуын телибез, и Муса!» – аны ялгыз гына китүенә каршы чыга. Шулай итеп, җитмеш кешене сайлап алып, барысы бергә Сина тавына юл тота.

Муса галәйһис-сәлам вәгъдә ителгән Китап турында Җәнабел-Хакка ялвара. Хак Тәгалә Аңа утыз көн ураза тотарга куша. Бу зөлкагдә аеның утыз көне була. Соңыннан зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне белән бергә бу ураза кырык көнгә җыела. Хәзрәти Мусага Китап бирелеп, аңа кавемен туры юлга ирештерү вазыйфасы йөкләнә.

Аллаһ Тәгалә: «Без Муса белән (Миңа гыйбадәт кылу өчен) утыз төн турында килештек һәм аларны (тагын) ун белән җиткердек, шулай итеп Раббың билгеләгән вакыт кырык төн булды...» – дип хәбәр итә («Әл-Әгъраф», 142).

Хәзрәти Муса бу вазыйфа таләп иткән камиллеккә ирештерәчәк ураза тоту, тыелып тору, гыйбадәт, дога, игътибар туплау, күңелне пакьләү һәм фикерләү өчен кырык көнгә Сина тавына чакырыла. Муса галәйһис-сәлам шушы кырык төн эчендә Раббы белән күрешүгә әзерләнергә тиеш була. Күкләрнең тынлыгына чуму, җирләрнең мәшәкатьләреннән ерагаю, ахырда исә чиксез киңлекләрдә бөек Яралтучыга барып җитеп, күңел диңгезенә чуму өчен, Муса галәйһис-сәлам Сина тавында башка кешеләрдән аерым яши, чөнки рухын пакьләп яктыртыр һәм аңа йомшаклык, нәфислек бирер өчен, әнә шундый ихтыяҗы була.

Моннан аңлашылганча, тәүге утыз көн ураза башка гыйбадәтләр белән бергә рухи төзәтү, пакьләнү, аз белән канәгатьләнү булып тора; ахыргы ун көндә Тәүрат иңдерелә һәм Аллаһ белән сөйләшү чынга аша, ягъни Муса галәйһис-сәлам шушы кырык көнлек вакыт эчендә Аллаһ Тәгалә белән аралаша алырлык югары рухи дәрәҗәгә күтәрелә.

Аяти-кәримәдә без күнеккәнчә кырык көн урынына кырык төн дип әйтелүе, айлар төн белән башланганга күрә, көн белән түгел, төннәр белән саналуы аркасында. Димәк ки, бу хисапка көннәр дә керә. Шулай ук, көндезге як белән чагыштырганда, төннең үз үзенчәлекләре дә бар. Бик күп илаһи күренешләр төннәрен чынга аша. Коръәни-Кәримнең ләүхел-мәхфуздән төнлә иңдерелүе, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мигъраҗ сәфәренә төнлә чыгуы кебекләр…

Муса галәйһис-сәлам бу сынавында кырык көннең, әйтерсең, тәүге утыз көне бер тулы төнне, аннан соңгы ун көн исә шул төннең сәхәрен тәшкил итә. Бу сәхәрнең таң сызыгы беленү сәгатьләрен хәтерләткән соңгы вакытларында Хәзрәти Муса галәйһис-сәлам Аллаһ Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешеп, бик күп илаһи күренешләрнең шаһитенә әйләнә.

Муса галәйһис-сәлам Сина тавында бертуктаусыз утыз көн ураза тота һәм бу вакытта ачыкмый да, кибекми дә!.. Ләкин Хозыр белән очрашыр өчен, сәфәргә чыгарга кушылгач кына, ярты көн дә узмый, сабырлыгы төкәнә һәм бик ачыга. Муса галәйһис-сәлам дустына: «Ризыкларыбызны чыгар, ашап алыйк!» – ди. Чөнки аның Хозыр янына баруы бер сынау белән бәйле була. Бу сынауга исә артык баглылык хисе өстәлә. Аллаһ яралткан бер мәхлук белән очрашу юлында Муса галәйһис-сәлам ярты көндә ачыга. Ләкин Сина тавында торган вакыты һәм Аллаһ янына сәфәр кылуы исә Хак Тәгалә белән кавышу сәфәрен һәм Аның белән әңгәмәне күздә тота, шуңа күрә Синада чакта ул ашау-эчүне онытa, Аллаһтан башка һичнәрсәгә игътибар бирми.

Аллаһ Җәллә Җәлалүһү белән сөйләшү бәхетенә ирешкәнлектән, Муса галәйһис-сәламне «Кәлимуллаһ» дип атыйлар. Хәзрәти Муса галәйһис-сәлам Җәнабел-Хак белән без күзаллаган тел кебек әгъза, корал ярдәмендә түгел, вакытка һәм тарафка бәйсез рәвештә, Аның мәңгелек «Кәлам» сыйфаты аша сөйләшә. Аллаһның сыйфатларыннан һичкайсы мәхлукларга хас сыйфатларга охшамый.

Тәүге мөселманнар

Иман китергән беренче кеше – Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез. Бу үзенчәлек аяти кәримәләрдә түбәндәгечә белдерелә: «Пәйгамбәр Раббы тарафыннан үзенә иңдерелгәнгә иман китерде…» («Әл-Бәкара», 285) «Әйт: Миңа динне Аллаһка ихлас булып тоту, Аңа коллык итү кушылды. Һәм миңа мөселманнарның беренчесе булырга боерылды» («Әз-Зүмәр», 11-12).

Беренче мөселман – Аның хатыны хәзрәти Хәдичә радыйаллаһу ганһә була. Пәйгамбәребез кавеменең мыскыллау, шаярту һәм җәфалау кебек начар мөнәсәбәтенә дучар булып, кайгы-борчулы хәлдә өенә кайткач, Аллаһ Тәгалә Аның газапларын хәзрәти Хәдичә анабызның юатучы һәм өмет бирүче сүзләре белән җиңеләйтә, илаһи ярдәме белән Аның вазыйфасын җайлаштыра.

Хәзрәти Хәдичә иман китергәч, Әфәндебезнең кызлары хәзрәти Рокыя, Өмме Гөлсем һәм Фатыйма да мөселман була.

Хәзрәти Гали кәррәмаллаһү вәҗһәһ Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән хәзрәти Хәдичәнең намаз укыганнарын күрә дә: «Нәрсә бу?» – дип сорый.

Аллаһ Рәсүле: «Бу – Аллаһның үзе өчен сайлаган дине. Мин сине бердәнбер Аллаһка иман китерергә һәм гыйбадәт кылырга, һичбер файдасы һәм зарары булмаган Ләт һәм Узаны кире кагарга чакырам!» – дип белдерә.

Хәзрәти Гали ул төнне көтеп карый. Аллаһ Тәгалә аның күңелендә исламга мәхәббәт уята. Иртән Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып. Хәзрәти Гали ислам турында сораулар бирә. Җаваплар алгач, Аллаһ Рәсүле кушканны шундук үтәп, мөселманлык кабул итә. Әтисеннән тартынып, күпмедер вакыт мөселманлыгын яшереп йөри. Хәзрәти Галигә ул чакларда ун яшьләр була (Ибне Исхак, 118 б.; Ибне Сәгъд, III, 21).

Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, намаз укырга теләгәндә, хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе белән бергә Мәккә үзәнлекләренә таба чыгып китә һәм шунда кешеләрдән качып намаз кылалар, кич өйгә кайталар. Аллаһ теләгән вакытка кадәр бу әнә шулай дәвам итә.

Әбү Талиб улының һәм сөекле туганының яшерен-яшерен намаз укуларын белеп алгач, Пәйгамбәр Әфәндебез яраткан агасын да исламга дәшә. Әбү Талиб бу чакыруга болай дип җавап бирә: «Әй туганымның улы! Аталарымның диненнән аерылырга минем көчем җитмәячәк! Ләкин Син Үзең җибәрелгән белән гамәл кылуны дәвам ит! Валлаһи, мин исән чакта, Сиңа берәү дә зыян сала алмаячак!»

Хәзрәти Галигә исә: «Балам! Ул сине бары хәерле нәрсәгә һәм яхшылыкка гына чакырыр! Син Аның юлын нык тот, Аңардан һич аерылма!» – ди (Ибне Һишам, I, 265).

Пәйгамбәр Әфәндебезнең иреклe колы Зәйд бинте Харисә радыйаллаһу ганһе хәзрәти Галидән соң мөселманлык ала, намаз укый башлый, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән аерылмый, аңа гел хезмәттә була. Таифле явыз башлыкларның Пәйгамбәр Әфәндебезгә аткан ташларын үз гәүдәсе белән каплап, кан эчендә калырлык фидакяр сөю белән үзен Аллаһ Рәсүленә багышлый, моңа каршы Галәмнәрнең Әфәндесенең шәхси мәхәббәте һәм хөрмәте белән бүләкләнә.

Хәзрәти Әбү Бәкер радыйаллаһу ганһе нәбилеккә кадәр дә Пәйгамбәр Әфәндебезнең дусты була. Балачагыннан ук Аның күркәм әхлагына, тугрылыгына һәм ышанычлылыгына шаһит зат. Күркәм әхлаклы буларак, һич ялган сөйләмәүче бер кешенең Җәнабел-Хакка карата ялган нәрсә сөйләвенең мөмкин түгеллегенә инана. Шуңа күрә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны исламга өндәгәндә, һич икеләнеп тормыйча, чакыруны кабул итә.

Билали Хабәши һәм аның анасы да Аллаһ Рәсүле кешеләрне исламга яшерен өнди башлаган тәүге көннәрдә мөселман була. Хәзрәти Билал радыйаллаһу ганһе – мөселманлыгын халыкка ачкан тәүге җиде кешенең берсе. Диненнән йөз чөергән өчен, кавеме тарафыннан иң авыр газапларга дучар ителә. Җәзалап, көчләп, исламнан баш тартырга мәҗбүриләнгән чагында: «Әхәд! Әхәд! Аллаһ бер! Аллаһ бер!» – ди.

Бала күңеле – китап

Яңа уку елы башында Ижауда җәмигъ мәчет каршында Удмуртия мөфтияте ярдәмендә «Мирас» репетиторлык үзәге ачылды. Җитәкчесе – Әлфия Газизуллина. Алар былтыр тормыш иптәше Габдерәшит хәзрәт белән Можга шәһәреннән күченеп килде. Анда яшәгәндә дә дин кардәшләребез, балалар, яшьләр белән тырышып эшлиләр иде. Әлеге хезмәтләрен хәзер Ижауда дәвам итәләр. Әлфия ханым Можгада балаларга (церебраль паралич авырулы) Монтессори методикасы буенча дәресләр оештырган иде. Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендә белем алып, һәрвакыт тәҗрибәсен арттыра бара.

– Әлфия ханым, «Мирас» үзәге кем тарафыннан һәм нинди максат белән ачылды?

– Без Можгада яшәгәндә, чыннан да, ата-аналар, балалар белән тыгыз эшли идек. Монтессори методикасы буенча дәресләр генә түгел, нәниләр өчен кечкенә балалар бакчасы да булдырган идем. Анда без татар, гарәп, инглиз телләрен өйрәттек, дин сабакларын укыттык. Минем педагогика буенча 20 еллык тәҗрибәм бар. Шуңа күрә, мөфтият тарафыннан Ижауда да шундый үзәк ачарга кирәк дигән тәкъдим яңгырагач, бик теләп риза булдым. Алар безгә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Ижауда мөмкинлекләрнең, мөселман гаиләләренең дә күбрәк булуы сөендерә, әлбәттә.

– Укыту ничек алып барыла?

– Көн саен иртәнге 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр 4-7 яшьлек балалар өчен «Ислам мәктәбе» оештырыла. Хәзер әлеге дәресләргә 10 бала йөри. Балалар төрле проектлар, биремнәр аша динне генә түгел, ә җир шарының, галәмнең төзелешен, әйләнә-тирә табигатьне, төрле һөнәр ияләре, галимнәр, шагыйрьләр, язучылар һәм башка нәрсәләр турында өйрәнәләр. Мәсәлән, Нух Пәйгамбәр турында өйрәнгәндә, кәгазьдән кораб, җәнлекләр ясадык. Бала үзе ясап, үзе сүзләр төзеп, үзе тотып карап өйрәнсен, дип тырышам. Шулай хәтерләрендә дә ныграк кала. Кайсы намазда ничә рәкәгать фарыз, ничәсе сөннәт икәнен дә уен аша, магнит белән беркетелә торган саннар ярдәмендә өйрәнәбез. Балаларны ниндидер кысалар эченә алмыйм. Мәктәпләрдә укытучылар укучыларның хаталарын кызыл төс белән сызып төзәтәләр икән, бала үзенең мөмкинлекләрендә шикләнә башлый. «Мин булдыра алмыйм», – дип уйлый. Ә уртанчы кызым Казан мәдрәсәләренең берсендә укыганда, укытучы дәфтәр читенә яшел төс белән тамга куя иде. Димәк, бу юлда хата бар, игътибар белән кара дигән сүзне аңлата. Баланы начарлык түгел, ә яхшылыкны күрергә өйрәтергә кирәк. Начарлык күреп, урынсыз тәнкыйть сүзләре ишетеп үскән кеше аны башкаларда да эзли башлый: монысының күлмәге кыска, моның сакалы озын, тегесенең киеме килешсез һәм башкалар. Бала күңеленә кечкенәдән изгелек, игелек орлыкларын чәчеп үстергәндә, ул башкаларда да матурлык күрергә өйрәнәчәк.

– Ата-аналар белән дә эш алып барасызмы?

– Кайбер балалар үзләренең хисләрен аңлата, таләпләрен әйтә белми. Шуңа күрә, төп максатым – ата-аналарга баланы, иң беренче чиратта, психологик яктан тәрбияләргә кирәклеген аңлату. Шул вакытта ул һәрьяклап та үсеш алачак. Дөрес, һәркайсына гомуми белемне алырга кирәк. Ә менә югары «планка» төрле була. Чөнки Аллаһ Тәгалә һәр балага сәләтләрне дә төрле итеп салган, холыклары да аерыла. Кемдер иҗатка тартыла, икенчеләре математиканы яхшы аңлый. Кемдер бик актив, икенчеләр оялчан. Кайчагында 6 яшьлек бала тарихны өлкәннәрдән дә яхшырак белә. Психологлар, тәҗрибәле укытучылар баланың сенситив үсеш чорларына игътибар итәргә кушалар. Ягъни, туганнан алып өч яшькә, өчтән алты яшькә, алтыдан тугыз һәм тугыздан унике яшькә кадәр чорларда балага аның психологик таләпләренә карап тәрбия бирергә кирәк. Кызганыч, бөтен ата-ана да моны белми. Ә шушы яшькә карап бүленгән чорларның берсендә тәрбия бирүдә ялгышсаң, соңыннан аны куып җитү, баланың тормышта бар яктан да камил шәхес булып үсүе икеле. Шуңа күрә мәктәптә әниләр өчен дә семинарлар үткәрәм. Психология, педагогиканы белгәндә, һәр баланы ачык китап кебек укырга була.

– Сезнең укыту программасы өчен кирәкле материалларның күплегенә таң калдым.

– Барысы да 20 ел дәвамында тупланган материалларым. Сатып та алам, үзем дә ясыйм. Мәсәлән, холык, хисләр турында өйрәнәбез икән, төсле рәсемнәр белән бизәлгән махсус китапларым бар. Мондый мәгълүмат татар телендә дә булса, тагы да яхшырак булыр иде. Агачтан киселгән хәрефләрнең татарчалары да булсын иде. Ул вакытта балалар татар телендә сүзләр төзеп уйный, өйрәнә алыр иде.

– «Мирас»та тагын нинди түгәрәкләр эшли?

– Балалар ашарга пешерү серләренә төшенәләр, инглиз, гарәп телен өйрәнәләр, робототехникага йөриләр, рәсем ясарга, төрле остаханәләрдә катнашалар. Рамазан ае алдыннан изге айның хикмәтләре турында сөйләштек. Татар теле дәресләре дә оештырыла. Кызганыч, туган телне өйрәнергә бары тик 2-3 кеше генә йөри. Шулай ук агачтан кисеп-ясау өчен кирәкле җиһазларны алдык, өйрәтергә остаз да табылды. Балалар агачтан кисеп, беренче уенчык машиналар да ясадылар инде. Гомумән, укытучылар белән авырлыклар килеп чыкмады. Алар безнең үзәккә үзләре килде. Мәсәлән, инглиз телен Мисырдан Ижауга укырга килгән егет өйрәтә. Балалар белән эшләргә теләк белдерүчеләр күп. Хәзер үземнең командамны туплыйм, 6 кешене укытам. Алар тиздән укытучылар сафына басачак. Алга таба да үзебезнең үзәкне үстерү, тәрбия-укыту эшләрен җәелдерү өстендә эшләүне дәвам итәчәкбез.

Эльвира ХУҖИНА.
«Яңарыш» газетасыннан.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

31 март – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
1 апрель – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
2 апрель – «Өтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
3 апрель – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
4 апрель – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
5 апрель – Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиевнең юбилей кичәсе.
6 апрель – «Дон Жуан» (Ж.-Б. Мольер).
7 апрель – зур залда – «Сөясеңме, сөймисеңне...» (Ф.Бүләков). Кече залда – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

4 апрель – «Баядерка» (Л.Минкус).
7 апрель – «Паяцы» (Р.Леонкавалло).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

31 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
1 апрель – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
2 апрель – «Туй алдыннан» (Х.Вахит).
4 апрель – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци).
5 апрель – «Шах...Мат!» (Л.Сәләхетдинова).
6 апрель – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
7 апрель – «Аферист» (Н.Исәнбәт).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

31 март – «Җырлап яшик!» (Р.Латыйпов).
1 апрель – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
2 апрель – «Ромео һәм Джульетта» (У.Шекспир).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

31 март – зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятенә нигезләнеп куелган). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк).
1 апрель – зур залда – «Али-баба и сорок разбойников» (В.Смехов). Кече залда – «Өрә белмәгән көчек» (Р.Мөхәммәтша).
2 апрель – Фойеда – «Бобровый пруд». Зур залда – «Теремок» (С.Маршак).
6 апрель – «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева).
7 апрель – Зур залда – «Конек-горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 апрель – 11.00 – Балалар өчен «Алло, мы ищем джазовые таланты!» дип исемләнгән музыкаль тамаша. 18.00 – «Мураками» төркеме һәм La Primavera Казан камера оркестры концерты.
4 апрель – Композитор П.И.Чайковскийның романсларына багышланган кичә.
5 апрель – Автор-башкаручылар концерты.
6 апрель – «Йөрәктән-йөрәккә» дип исемләнгән романслар кичәсе.
7 апрель – Татарстан Республикасы филармониясе джаз оркестры һәм Аркадий Шилклопер башкаруында джаз музыкасы премьералары башкарыла.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

1 апрель – La Primavera Казан камера оркестрының көлке көненә багышланган концерты.
2 апрель – 15.00 – Композитор Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган «Җырларым» концерты. Катнашалар – Илүсә Хуҗина, Марсель Вәгыйзов, Илгиз Мөхетдинов, Илгиз Шәйхразиев, Алмас Хәсәенов, Зәринә Хәсәншина һәм Татарстан Республикасы дәүләт кыллы квартеты. 18.00 – Композитор, пианист Илья Бешевли концерты.
5 апрель – «Рахлин сезоннары» XII халыкара фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт академия симфоник оркестры концерты. Дирижер – Ноам Цур. Солист – Борис Андрианов (виолончель).
7 апрель – Мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләре өчен хәйрия концерты. Катнашалар – Татарстан Республикасының Милəүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры, С.Гобәйдуллина исемендәге заманча музыка үзәгенең Анна Гулишамбарова җитәкчелегендәге оркестры. Дирижер – Ләйлә Гарифуллина.

Кешенең химик составы

Ахыр чиктә бөтен нәрсә химик элементлардан тора, хәтта безнең тәнебез дә. Организмның гомуми авырлыгының 65 процентын кислород тәшкил итә. Икенче урында – углерод. Авырлыкның 10 проценты водородтан, 3 проценты – азоттан, 1,5 проценты кальцийдан тора. Организмдагы фосфор – ДНК барлыкка килүдә алыштыргысыз элемент. Калий җитешмәсә, аяк-кулларны көзән җыера башлый. Күкерт аминокислота һәм коферментларның нигезен тәшкил итә. Хлор да бар әле безнең тәнебездә, дөресрәге, хлорид – ул кан плазмасында алыштыргысыз элемент. Натрий күзәнәкләрне саклау һәм нерв сигналларын җибәрү өчен кирәк. Магний, тәндәге күләме 0,05 процент кына булса да, мөһим: ул житешмәгәндә, баш авырта, нервландыра, арыта, мускулларны көзән җыера. Тәндәге тимер микъдары – 2-5 грамм. Кобальт В12 витамины составына керә. Бакыр микроорганизмнар өчен бик аз күләмдә дә кирәк, ә менә кешегә ул мөһим ферментлар ясалуы өчен кирәк. Бакырны без яшелчәләр, шоколад һәм чикләвек аша алабыз. Цинк – җирдәге бөтен тереклек иясе өчен кирәкле элемент, ул матдәләр алмашы өчен мөһим һәм күп ферментлар составына керә. Йод калкансыман биз житештерә торган тироксин һәм трийодтиронин гормоннары составында бар, ул җитешмәгәндә, матдәләр алмашы бозыла. Селен һәм фтор да алыштыргысыз микроэлементлар, әмма артык күп кулланганда, агуга әйләнә һәм организмга зыян китерә башлыйлар, шунлыктан аларны биологик актив өстәмә (БАД) сыйфатында куллану галимнәр арасында зур бәхәсләр куптара.

(“Abcfact.ru”).

Йөрергә кирәк!

Элек, күбрәк физик эш белән шөгыльләнгәндә, кеше көн буена аяк өсте булган. Әмма хәзерге телевидение, компьютерлар һәм офиста эш заманында без көненә уртача 9,3 сәгать утыра башлаганбыз (хәтта ятып торудан да күбрәк – йокыга уртача 7,7 сәгать вакытыбыз китә)! Кеше организмы исә моның өчен яратылмаган, шунлыктан аз хәрәкәтләнеп яшәү рәвеше көннән-көн күбрәк зыян китерә бара. Тәүлегенә 6 сәгатьтән дә артык утырып торучыларның 15 ел эчендә үлеп китү ихтималы көненә 3 сәгатьтән азрак утыручыларга караганда 40 процентка зуррак. Утырып эшләүчеләр басып эшләүчеләр белән чагыштырганда йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан ике тапкыр ешрак интегә. Утырып торганда, организм энергия сарыф итми диярлек. Бу вакытта аяк мускулларының электр активлыгы минимумга кадәр кими; 1 минутта 1 калория генә сарыф ителә; май таркатучы ферментлар саны 10 процентка кими; 2 сәгать утырганнан соң, кандагы яхшы холестерин микъдары 20 процентка; инсулинның исә нәтиҗәлелеге кими һәм шикәр чире килеп чыгу куркынычы арта. Офиста көн буена утырып эшләүчеләр, хәлне ничек тә яхшырту өчен, әледән-әле торып йөрергә, сикергәләп алырга, бер урында булса да таптанырга тиеш.

(“The Local”).

Алма төшкәнме, юкмы?

Исаак Ньютон бөтендөнья тартылу законын башына алма килеп төшкәч ачкан, дигән бик популяр хикәят чынлыкта исә уйдырма гына. Алманы физикның илһам чыганагы дип атап була-булуын. Чөнки бала чагында Ньютон: “Ни өчен алма җиргә төшә, ә Ай – төшми?” – дип бик еш уйлана торган була. Шулай да ул тарту көчен немец физигы һәм математигы Иоганн Кеплер (1571-1630) хезмәтләрен өйрәнгәннән соң ача. Бу кыш көне була, табигатьнең әлеге фасылында исә алмагачтан алма коелмый...

(“Die Presse”).

Прокрастинация

Бик дәһшәтле яңгырый торган әлеге сүз организмның билгеле бер психологик халәтен аңлата. Кеше мөһим вакыйгаларны хәл итүне һаман кичектерә бара, үзе бер дә кирәкмәгән эш белән шөгыльләнә. Мәсәлән, ашарга әзерләмәс өчен, телевизион каналларның яки социаль челтәрләрнең берсеннән икенчесенә күчә-күчә, көн буе экран каршыннан китми яки гаджетларын кулыннан төшерми. Яисә, кирәкле хисапны язмас өчен, компьютерда уйнап утыра һ.б.ш. Белгечләр исәпләп чыгаруынча, кеше прокрастинациягә эшкә караганда ике тапкыр күбрәк вакыт сарыф итә, хәл елдан-ел кискенләшә генә бара. Әгәр кирәкле эшне вакытында үтәп барса, кешенең ял итәр өчен буш вакыты күбрәк калыр иде.

(“The Local”).

● **Сан-Францискодагы Ломбард-стрит дөньяда иң матур урамнарның берсе санала.**

Иң матур авыл

Англиянең Котсуолд районында урнашкан Бибури авылын унтугызынчы гасырда яшәгән танылган инглиз рәссамы һәм шагыйре Уильям Моррис дөньяда иң матур авыл дип санаган. Бирегә вакыт шул тыныч, салмак дәвердән бирле туктап калган кебек, андагы һәр йортны раритет дип атап була. Бу авылда хәзергә кадәр төзелештә яндырылган кирпеч кулланылмый. Бибуридагы барлык биналар кабырчык токымнан салынган. Бирегә якындагы Кембле станциясеннән автомобильдә генә килеп җитеп була, берниндиі җәмәгать транспорты да йөрми. “Иң инглиз авылы”-ның тар урамнары буйлап йөрергә, Кольн аша салынган күпердән пар аккошлар белән хозурланырга, борынгы биналарда урнашкан уңайлы рестораннарда сыйланырга, антиквариат кибетләреннән матур әйберләр сатып алырга дип, бөтен дөньядан романтиклар Бибурига агыла.

(“Интересно.cc”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

3 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ». 16+
11.00 «Әдәби хәзинә». 16+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
17.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
17.30 «Татарстан без коррупции». 16+
19.30 Хоккей. Кубок Гагарина. «Ак Барс» - «Авангард».
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Ватандашлар». 16+
19.30, 0.15 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Юрий Андропов. Терра инкогнита». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Генрих Шлиман.
7.35, 18.40 «Майя. Рождение легенды».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 Спектакль «Кто есть кто?»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Поет Эдита Пьеха».
11.50 «Одинцово. Васильевский замок».
12.20 Линия жизни. Виктор Садовничий.
13.20, 22.10 «ЩИТ И МЕЧ».
14.45 «Забытое ремесло».
15.00 Новости. Подробно. АРТ.
15.15 «Агора».
16.20 Цвет времени. Валентин Серов.
17.40 Неделя хоровой музыки. Сочинения С. Танеева и С. Рахманинова. НФОР и Академический большой хор «Мастера хорового пения».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 75 лет Валентину Дикулю. Линия жизни.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
23.30 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».

«НТВ»

4.55 «ПОБЕДИТЕЛИ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Сишәмбе

4 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Татар сүзе».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40, 17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Ватандашлар». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Секретные материалы. Ключи от долголетия». 16+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 95 лет со дня рождения Элины Быстрицкой. «Театральная летопись».
7.35, 18.40 «Майя. Рождение легенды».
8.20 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.55, 16.35 Спектакль «Между небом и землей».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Земное притяжение». Научно-популярный фильм.
12.15 «Эвакуационный роман».
13.15, 22.00 «ЩИТ И МЕЧ».
15.00 Новости. Подробно. Книги.
15.15 «Передвижники. Алексей Саврасов».
15.45 «Сати. Нескучная классика...»
16.25 Цвет времени. Надя Рушева.
17.40 Неделя хоровой музыки. Духовная музыка русских композиторов. Хоровые коллективы Москвы на Великопостном фестивале.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 Искусственный отбор.
21.15 «Белая студия».

«НТВ»

4.50 «ПОБЕДИТЕЛИ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Чәршәмбе

5 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ». 16+
11.00, 0.50 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.30 Хоккей. Кубок Гагарина. «Авангард» - «Ак Барс».
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Татар сүзе».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Равил Шәрәфиев турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.30 «Ватандашлар». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Никита Хрущев: от Манежа до Карибов». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 К 95-летию со дня рождения Элины Быстрицкой. «Театральная летопись».
7.35, 18.40 «Ангкор - земля богов».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 Спектакль «Понедельник - день тяжелый».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Встреча по вашей просьбе. «Виртуозы Москвы» и Владимир Спиваков».
12.30 Искусственный отбор.
13.15, 22.00 «ЩИТ И МЕЧ».
14.30, 23.15 «Запечатленное время».
15.00 Новости. Подробно. Кино.
15.15 «Библейский сюжет».
15.45 «Белая студия».
17.40 Неделя хоровой музыки. Концерт хора Валаамского монастыря в Московском международном Доме музыки.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 Абсолютный слух.
21.15 Власть факта. «Реформы Дэн Сяопина и китайский путь».

«НТВ»

4.50 «ПОБЕДИТЕЛИ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Пәнҗешәмбе

6 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00, 23.00 «ВТОРАЯ ЖИЗНЬ». 16+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ТӨЛКЕ ЕЛМАЮЫ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Ватандашлар». 16+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 16+
18.00 «Татар сүзе».
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10, 0.15 «Соотечественники». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Ким Филби. Моя Прохоровка». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+

23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 К 95-летию со дня рождения Элины Быстрицкой. «Театральная летопись».
7.35, 18.40 «Ангкор - земля богов».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 Спектакль «Солдаты в синих шинелях».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Осень шахматиста. Михаил Ботвинник».
12.15 «Забытое ремесло».
12.30 Абсолютный слух.
13.15, 22.00 «ЩИТ И МЕЧ».
14.30, 23.15 «Запечатленное время».
15.00 Новости. Подробно. Театр.
15.15 Пряничный домик. «Загадки восточных узоров».
15.45 «2 Верник 2».
17.40 Неделя хоровой музыки. В.А. Моцарт. Большая месса до минор. Оркестр «Камерата Зальцбург» и Зальцбургский Баховский хор.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Алексей Сальников. «Оккультрегер».
20.35 «Собака Баскервилей». Овсянка, сэр!»
21.15 «Энигма. Франс Хельмерсон».

«НТВ»
4.50 «ПОБЕДИТЕЛИ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Җомга

7 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.30 Хоккей. Кубок Гагарина. «Авангард» - «Ак Барс».
19.00 «Туган җир». 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Татар сүзе».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «РОЖДЕСТВО В ШОКОЛАДЕ». 16+
23.45 «ПОХИЩЕНИЕ ЧАРОДЕЯ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
4.15 «Кәмит Җәвит». 16+
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Җыр - ул хиснең балкышы!» Наил Касыймов турында телечерк. 16+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.55 «ФЕДОСИЙСКАЯ СКАЗКА». 6+
14.35 «Человек на своем месте». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Маршал Конев. Иван в Европе». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Моя мелодия». 12+
23.35 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05 К 95-летию со дня рождения Элины Быстрицкой. «Театральная летопись».
7.35 «Да, скифы - мы!»
8.15 «Забытое ремесло».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 Спектакль «Мужчина и женщины».
10.15 Спектакль «Любовный круг».
12.40 Цвет времени. Камера-обскура.
12.50 Открытая книга. Алексей Сальников. «Оккультрегер».
13.20, 19.45 «ПЯТЬ ВЕЧЕРОВ».
15.00 Письма из провинции.
15.30 «Энигма. Франс Хельмерсон».
16.15 Цвет времени. Караваджо.
17.40 Неделя хоровой музыки. Концерт Капеллы России имени А.А. Юрлова и Хора имени А.В. Свешникова.
18.30 «Азербайджан. Баку. Дом Мухтарова».
19.00 «Смехоностальгия».
21.25 «2 Верник 2».
23.30 «КАРП ОТМОРОЖЕННЫЙ».

«НТВ»
4.50 «ПОБЕДИТЕЛИ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Шимбә

8 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казанннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
14.00 «Мәңгелек юлында». Мөхәммәт Мирзаның 70 яшьлек юбилей кичәсе. 12+
16.00 «Уроки истории». 6+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «ЧЕЛОВЕК ИЗ РИО». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 16+
17.20 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Язмышларым сиңа бәйләнгән». Рөстәм Закиров концерты. 16+
22.15 «АЛМАШ». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПУШКИН: ПОСЛЕДНЯЯ ДУЭЛЬ». 12+
14.45 «Александр Пушкин. Нет, весь я не умру». 12+
15.45 «В БЕГАХ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПРИНЦЕССА СПЕЦИЙ». 12+
22.35 «ТАНЦЫ НА ГРАНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «Видели видео?»
13.40 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 3». 12+
18.20 Концерт «Юбилейный вернисаж». 12+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.35 «СИРАНО. УСПЕТЬ ДО ПРЕМЬЕРЫ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «ЗОЛОТАЯ КЛЕТКА». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ПОСЛЕДНИЙ ШАНС». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «НОВЫЙ ГУЛЛИВЕР».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ».
11.30 «Передвижники. Алексей Саврасов».
12.00 «Люди неба».
13.00 «Даты, определившие ход истории».
13.30 «Британская Колумбия. Край, где царят гризли».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.15 «Анатолий Виноградов. Гражданин директор».
15.45 «Бельмондо Великолепный».
16.35 «ЧЕЛОВЕК ИЗ РИО».
18.30 «Возвращение в Ивановку».
19.50 К 100-летию со дня рождения Людмилы Шагаловой. Острова.
20.30 «ДАЧА».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.05 «Жди меня». 12+
5.50 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Страна талантов». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

9 апрель

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Татар сүзе» халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесенең гала-концерты. 6+
17.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
18.00 «Ком сәгате». 16+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «СКАНДАЛЬНОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ В БРИКМИЛЛЕ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30, 16.05 «Музыкаль мәйдан». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Күңелемдә яз». Георгий Ибушев концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Казанның кадерле кичләре». Зөһрә Сәхәбиева концерты. 6+
15.10 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов турында телечерк. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Утрау». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «В БЕГАХ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ГОГОЛЬ. БЛИЖАЙШИЙ». 12+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ФАКИРА». 16+
22.40 «ЧУЖИЕ ДУШИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
13.50 К 90-летию Жан-Поля Бельмондо. «Бельмондо глазами Бельмондо». 16+
15.50 «Век СССР». «Запад». 16+
17.00 Памяти Владимира Жириновского. «Прямая речь». 12+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «На футболе с Денисом Казанским». 18+

«РОССИЯ»
6.10 «ПОЦЕЛУЕВ МОСТ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.05 «ЗОЛОТАЯ КЛЕТКА». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Лето Господне.
7.05 «Маугли».
8.40 «ОШИБКА ИНЖЕНЕРА КОЧИНА».
10.30 Диалоги о животных.
11.10 «ДАЧА».
12.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Елизавета Кульман.
13.05 «Забытое ремесло».
13.20 «Игра в бисер» «Н.В.Гоголь. «Женитьба».
14.00 «Коллекция».
14.35 Владимир Васильев, Людмила Семеняка, Борис Акимов в балете «Иван Грозный» на музыку С. Прокофьева.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.25 «Пешком...»
17.55 «Новат. Либретто в 15 картинах».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ».
21.25 Великие имена. Герберт фон Караян.
22.20 «ЧЕРНАЯ КОШКА, БЕЛЫЙ КОТ».

«НТВ»
4.55 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Актаныш районындагы Тәкмәк авылында гомер иткән Ринат ага Кәрамов эчү аркасында түбәнгә тәгәрәп, ахыр чиктә, аяныч әҗәлгә дучар булган кеше. Беренче хатыны, балалары белән күптәннән аерылышкан, беркайчан да аралашмаган, алар аны җирләргә дә кайтмаганнар. Кеше үтерү очрагы буенча кузгатылган җинаять эшендә зарар күрүче итеп аның күрше авылда яшәүче туганнан-туган сеңлесе билгеләнгән. Шул зәхмәт аркасында башка хатыннар белән дә озак яши алмыйча, гомер көзендә үзе генә калган ул. Күршеләре аның 2021-2022 елларда гына да ике мәртәбә «белая горячка» чире кичерүен әйтәләр, ләкин иң әүвәл үзе өчен хәтәр хирыслыгыннан арына алмаган. Янәшәдәге Югары Яхшый авылындагы кибет сатучысы Лилия 1955 елгы абзыйның 15 декабрь, димәк, гомеренең соңгы көнендә бер чәкүшкә, ике ярты аракы алуын хәтерли

Шешәдәге зәхмәт казасы

Икенче көнне иртә белән аның күршесе Рөстәм Гыймазетдинов Тәкмәккә атнага өч мәртәбә килә торган икмәк сатучы «автолавка»ны көтә. Бераз соңарып пәйда булган күчмә кибеттән азык-төлек алгач, дусты һәм, әйтүенчә, шешәдәше Ринатның хәлен белеп, бергәләп тәмәке көйрәтеп чыгарга уйлап барып керә ул аның өенә. Ишекне ачу белән идәндәге кан күлдәвекләре, пыяла ватыклары, иң шомлысы, диванда канга баткан хуҗаны күргәч, аның башындагы җәрәхәтләрне шәйләп алгач, кире борыла, бу хакта хәләл җефетенә җиткерә, анысы күрше ханымга хәбәр итә. Тиздән өч кешелек төркем абзыйның җансыз икәнен ачыклап, авыл фельдшеры Илсөяргә шалтырата. Аяныч яңалык Тәкмәкне бик тиз урап чыга, хәвефле йорт янына, полиция килеп җиткәнче үк, тагын кешеләр җыела.

Полиция, әлбәттә ки, эчкече абзый аралашкан кешеләрне барларга керешә. Әлеге йортка Тәкмәктән Р. Гыймазетдиновтан кала, Илфат, Федор, Югары Яхшыйдан Данил, Әнис атлы ирләрнең еш килүен әйтүчеләр була. Ләкин алар шикләләр исемлегеннән тиз сызыла. Рөстәм белән Илфат Р. Кәрамовны актык тапкыр ике көн элек күрүләрен әйтә, соңгысы хәвефле 18-19 декабрь төнендә эшендә була, калганнарның да катнашлары юк икәнне дәлилләгән «алиби»лары табыла. Ләкин оператив чараларның комга терәлүен белдерми бу. Участок инспекторы З. Хөснуллин шул көнне үк Виктор Рәхмиев дигән килмешәк белән әңгәмә кора, ул төнгә каршы Р. Кәрамов йортында булуын кире какмый, ләкин сәрхүш хуҗага эчәрене чиләктән су алып бирдем дә, исәнсау килеш калдырып чыгып киттем дип сөйли. Ләкин аннан шикләнерлек сәбәпләр була, иртә белән Р. йортына кереп барганда, икмәк сатучыны көтеп торучылар күреп калган кара курткалы кеше ул дип фаразлана. Чөнки төнне исерек В.Рәхмиев белән очрашкан тагын берничә кеше була.

33 яшьлек В.Рәхмиев Баулы якларында туган, Башкортстанның Бакалы районында яшәгән һәм берничә ел элек җирле авыл хуҗалыгы кооперативына килеп ялланган һәм фермер Т.Зиннәтуллин карамагындагы Югары Яхшый авылы читендә агач бинада гомер иткән кеше. Аның әйтүенчә, элегрәк шунда ук әтисе һәм тагын бер туганы да эшләгән һәм яшәгән. Ялгызак ялчы, башлыча, Зиннәтуллиннар хуҗалыгында маллар карау белән шөгыльләнгән, азык-төлек, вак-төяк кирәк яракларны авыл кибетеннән түләүсез алган, ошбу чыгымнарны, күрәсең, хезмәт хакы хисабыннан эш бирүче каплап килгән, сатучы Лилиянең әйтүенә караганда, аңа исерткеч эчемлекләр бирү генә тыелган.

Гаебен озак кире кагып тормый, мөгаен, фаш ителәчәген аңлый ул. Моның өчен аның курткасы, кроссовкаларындагы канның мәрхүмнеке икәнен дәлилләү дә җитә бит. Шул ук көнне аның теле ачыла һәм 18-19 декабрьдә кылган явызлыкларын ачыклау мөмкинлеге туа.

Эчәм дигән кеше, кибеттә аракы бирмиләр дип тормыйча җаен таба бит ул. 18 декабрьдә В.Рәхмиев тә өендә үзе кайнаткан эче бал белән сыйлана. Искәртеп үтмичә булмый, 1989 елгы ялгызак ир үзеннән бераз өлкәнрәк тол ханым белән якын мөнәсәбәттә була, алар икесе дә Рәхмиев торагында, аисә әнисе, балалары өйдә юк чакта ханым йортында очрашулары яшермиләр. Рәзинә (кайбер исемнәр үзгәртелә) исергәч йөгәннән ычкына торган ир затының көнләшүен, шул сәбәпле үзенең машинасын яньчүен дә искә ала. Аны Айрат атлы башка ир белән хыянәт итүдә шикләнүен Виктор үзе дә әйтеп тора.

Әгәр 18 декабрьдә төнгә каршы В.Рәхмиевне Тәкмәккә таба тәпиләргә этәргеч бирмәсә, бу кадәресенә кагылып торуның кирәге дә булмас иде. Эш шунда ки, Рәзинә шул көннәрдә аның янына килергә вәгъдә итә, әмма бер баласы чирләп китү сәбәпле, очраша алмаячакларын җиткерә. Менә шуннан соң исерек ирдә көнчелек хисләре кабынып китә дә инде, әйтүенчә, аларны икесен бергә эләктерү ниятеннән Тәкмәккә юл ала ул. Анда исә вакыйгалар башка төрле юнәлештән китә.

Барысы да төн уртасында утлары янып торган танышы Ринат агай өенә барып керүдән башлана кебек. Хак булса, хуҗа тәкъдим иткән аракыдан баш тарта да, үзе белән алып килгән ярты литр «брашка»ны эчеп бетерә ул анда. Болай да нык исерек абзый бер чәркәне бушатып куя. Сәрхүшләр арасында ызгыш чыкмый калмый, хуҗа чакырылмаган төнге кунакны әшәке сүзләр белән куган, вәзгыять кискенләшә, кыскасы, яшь ир-ат өлкән кешенең тетмәсен тетеп ташлый, кул-аяк белән тукмау гына түгел, тимер чиләк, чүмеч белән дә суга. Барысын да әйтеп бетерми ул, ләкин суд-медицина экспертизасы мәрхүмнең башына, күкрәгенә кимендә 16 тапкыр сугылуын, аның баш миенә, күкрәк читлегенә кан саву, 13 җирдән кабыргалары сыну һәм башка сәбәпләрдән җан бирүен белдерә.

Авыр хәл эчендәге кешене калдырып чыккач та, «разборка»га китә явыз. Әүвәл сөйгәне яшәгән йорт ишеген дөбердәтеп кычкыра. Аның холкын белгән ханым ишекне ачмый, шуннан соң ярсу егет күршедәге Айрат ишегалдына кереп тавыш куптара. Ул арада Рәзинә ошбу галәмәт турында кооператив башлыгы Зиннәтуллинга хәбәр итә, Айрат белән сугыша дип өстәп куя. Ләкин анда ирләрнең кара-каршы бәргәләшүенә барып җитми эш. Айрат котырынып дулаучы бәндәне «тынычландыру» әмәлен таба, ягъни ишекне ачу белән өч мәртәбә чүкеч белән тегенең башына кундыра һәм яраларыннан кан ага башлаган ирне капканың тышкы ягына чыгара. Кызганып сукканга охшый, чөнки Рәхмиев шул мәлдә телефонын эзли башлый, аңа Айрат та ярдәм итә, ләкин шалтыратып карагач та, «Самсунг»ның тавышы ишетелми. Шул арада килеп җиткән Җ.Зиннәтуллина, машинасына утыртып, аны Югары Яхшыйдагы йортына кайтарып куя.

Ул чакта Рәхмиев явызлыгы турында белүче булмый әле. Иртә белән эшенә дә бара ул, ләкин соңарып килү сәбәпле, маллар каралган була инде. Шуннан соң телефонын эзләп, Ринат агай йортына китә, аппаратны табып кесәсенә сала, идәндә яткан җансыз хуҗаны өстерәп алып килеп диванына күтәреп сала, имеш, күптән суынган кеше исән дип уйлый һәм кеше күзенә чалынмас өчен, арт капкадан чыгып бәрәңге бакчасы аша китә. Әйтелгәнчә, икмәк машинасы көтүчеләр аны барыбер күрә.

Үзе сөйләгәннәр генә түгел, дистәләгән экспертиза нәтиҗәләре, башка дәлилләр үтерүченең Рәхмиев икәненә шик калдырмый. Психиатрлар 2019 елга кадәр акыл ягыннан җиңелчә кимчелекләргә ия зат буларак исәптә торган егет үз гамәлләрен аңламаслык хәлдә түгел дигән нәтиҗә ясый, икенче төрлерәк итеп әйтсәк, барысына да шешәдәге зәхмәт, ягъни алкогольгә бәйлелек гаепле дип белдерелә. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Вилсур Сәлахов моңарчы хөкемгә тартылганы булмаган В. Рәхмиевка аңлы рәвештә кеше үтерүдә рәсми гаепләү белдерә.

Наил ВАХИТОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

Кем кемне куркыта?

Игътибарны отыры тынычлык планнары яулаган бер мәлдә, бер-берсен хәтәр корал белән куркытырга омтылучылар да юк түгел. Ни гаҗәп, янау сүзләрен башлап хатын-кыз авызыннан әйттерделәр: Бөекбритания саклану министрлыгыннан Аннабель Голди Украинага, Challenger 2 танклары комплектында, өтелгән уран (радиоактивлыгы рудадагыдан да кимрәк булган U-238 изотобы) кулланып ясалган, калын броняны да тишеп үтә торган снарядлар да куелачагы турында белдерде. Дөрес, АКШ андый адымнан баш тартты. Мәскәү исә ул коралның чәчү кырларына зур зыян салачагы, уран тузаны кеше организмы өчен дә куркыныч булуы, ә хәтәр адым хәлне тагы да катлауландырачагы турында да искәртте. Президент В.Путин хәтта, Мәскәүнең җавабы моңа бик катгый булачак дип тә кисәтте. Нәтиҗәдә, узган атнада ул Россиянең, АКШ үрнәгендә, Беларусь территориясендә атом-төш корылмалы тактик ракеталар урнаштырачагы турында белдерде. Берлинда моны атом-төш куркытуының дәвамы дип тә бәяләделәр.

Халыкара җинаять судының (МУС) РФ Президенты В.Путин һәм балалар омбудсмены М.Львова-Беловыны кулга алуга ордер бирүе хокукый коллизияләргә дә китерә. Әйтик, августта КАРда узачак БРИКС саммитында В.Путин катнашса, ул анда кулга алынырга тиеш була. Әрмәнстанда Рим статуты ратификацияләнгән очракта, димәк, В.Путинны бу илдә дә тоткарланырга тиеш. Кремльнең матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков исә журналистларның бу хактагы соравына, ул турыда Ереван белән әлегә сөйләшү булмады, уйлашырбыз, дип җаваплаган. Ә парламент рәисе В.Володин Россиядә МУС эшчәнлеген тыярга да өндәгән. СКР исә югарыда телгә алынган ордерны биргән МУС судьяларына карата җинаять эше кузгаткан. Искәртеп үтик, Рим статуты дөньяның 123 илендә ратификацияләнгән. 2003 елдан ул Россиядә дә гамәлдә иде. Әмма Кырым буенча МУС Мәскәүне гаепләгән билгеләмә биргәч, 2016 елда Россия Рим статутыннан баш тартты. АКШ, Кытай һәм кайбер башка илләр дә аны танымый.

Инде атнаның башка кайбер вакыйгаларын да санап үтик. БМО КШ «Төньяк агымын» шартлатуны тикшерү буенча Россия резолюциясен кире каккан (15 әгъзадан Россия, Кытай һәм Бразилия – хуплаган, калганнары – тыелып калган). Швеция парламенты илнең НАТО га керүен хуплаган. Венгрия дә Финляндиянең НАТО га кушылуына ризалык биргән. В.Путин Көнбатышның Украинага сугыш кораллары куюы Россиягә куркыныч тудыра, дип белдергән. Алмания Россиянең 30 дипломатын илдән сөреп чыгарырга җыена. Моңа җитди җавап бирелачәге турында Берлинны Мәскәү дә кисәткән.

Фоат УРАЗАЙ.

ИСКИТКЕЧ КАЛФАКЛАР

Декоратив-гамәли сәнгать остасы, рәссам Гөлназ АБДУЛЛИНА тегеп чиккән укалы калфакларны, түбәтәйләрне без әле дәүләт музейлары экспозицияләрендә күрәчәкбез! Чөнки бүген осталар арасында бу кадәр сыйфатлы, зәвыклы эшләнмәләрне иҗат итүчеләр бик аз. Әйе, калфак-түбәтәйләрне тегүчеләр саны кимеми, әмма әлеге эшләнмәләрнең бик күбесе – бик гади һәм гадәти итеп кенә чигелә.

Гөлназ Абдуллина Башкортстанның Караидел районы Кызыл Өреш авылында дөньяга килгән. Хәзерге көндә Әбҗәлил районының Аскар авылында яши. Гөлназ һәм Нур Абдуллиннар бер ул һәм бер кыз үстерә. Останың әти-әнисе Светлана һәм Тәфкил Рамазановлар инде лаеклы ялда. «Әниебез – башлангыч сыйныфлар укытучысы, әтиебез слесарь булып хезмәт куйды. Гаиләдә без ике бала – сеңлем Гөлшат бар. Авылыбызда сәнгать мәктәбе юк иде, шуңа күрә рәсем ясау сәләтемне куәтләр өчен, Бөре балалар сынлы сәнгать мәктәбе укытучысыннан дәресләр алырга туры килде. Урта мәктәпне 2009 елда тәмамладым. Аннары Бөре каласындагы Башкортстан дәүләт университеты филиалына имтиханнар тапшырдым һәм 2014 елда сынлы сәнгать укытучысы белгечлегенә ия булдым. Булачак һөнәремне мөмкин кадәр тәплерәк беләсем килде, шуңа күрә дә тырышып, яхшы билгеләргә генә укыдым. Гөлшат та шушы югары уку йортында белем алды, ул да укытучы, гамәли-декоратив сәнгать рәссамы, бүген макетлар ясау белән мәшгуль, – ди әңгәмәдәшем. – Мин бер ел педагогика көллиятендә белем бирдем, әмма укытучы һөнәренең күңелемә туры килмәвен аңладым. Шуннан соң Уфадагы бер фотостудиядә эшләп алдым, аннары өй җиһазлары җитештерү фабрикасында алтынлап бизәү остасы булып киттем. Гаилә тормышым башлангач, иҗат өчен вакыт калмады да диярлек.

Мин кечкенәдән ыргак белән дә, энәләр белән дә бәйләдем. Әниебез дә кул эшләре остасы, шунлыктан без дә аннан калышырга теләмибез. Сынлы сәнгать-графика факультеты укытучыларыбыз да безне декоратив-гамәли сәнгать өлкәсенә күбрәк этәрде, студент чакта киез эшләнмәләр, корама әйберләр, курчаклар, гобеленнар һ.б. иҗат итеп карадык.

Татар калфагын иҗат итүгә 2021 елда декрет ялында керештем. Мәгълүм рәссам-реконструктор, этнодизайнер Илдар Гатауллин миннән бөрәр төр борынгы татар хатын-кыз калфагын тегеп, чигеп бирүемне үтенде. Һәм мин «РФ музей фондының дәүләт каталогы» сайтындагы фотолар арасыннан бик катлаулы ысуллы борынгы калфак үрнәген сайлап алдым. Мондый чигүле калфак Башкортстан милли музеенда саклана. Аны, бәлкем, күпләрнең күргәне дә юктыр әле... Ул ука (канитель) белән чигелгән. Иҗатымда бер тапкыр да ука кулланып чигеп караганым юк иде, әмма тәвәккәлләдем! Хәзерге көндә әлеге калфак – «Millihasite» берләшмәсе коллекциясендә».

Гөлназ Тәфкил кызы әлеге катлаулы чигешле калфакны биш ай эчендә башкарып чыккан! «Ука да, сыйфатлы бәрхет тукыма да арзан товар түгел, – дип аңлата талант иясе. – Мондый чигүләр өчен балавызланган, чыдам җепләр куллану уңайрак, шуңа күрә гади тегү җепләрен үземә балавызларга туры килде. Хәзер инде мин шундый укалы, милли бизәмле өч калфак тегеп чиктем. Укаларның 0,8 һәм 1 мм булганнарын сайладым. Аларның һәммәсе дә тарихи калфакларыбыз үрнәгендә. Мондый баш киемнәре Башкортстан милли музеенда, Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. «Әлеге югары сәнгати дәрәҗәдәге калфакларыгызны сатуга куярга да җәлдер?!» – дим Гөлназга. Әмма аның җавабы милли кием-салымга мөкиббән гүзәлләрне сөендерерлек: «Юк, бер дә кызганыч түгел. Югары сәнгати кул эшләнмәсен алырга теләүче табылса, моңа шат кына булачакмын. Минем алардан башка эшләнмәләрем дә бар әле, әйтик, тамбур чигүле сумка, чигешле күзлек савыты, брошкалар, татар түбәтәе һ.б. Затлы калфакларым гадәти чараларда түгел, ә, бәлкем, тантаналы бәйрәмнәребездә генә киелсә дә, татар милли костюмнарыбызның никадәр югары дәрәҗәдә, матур булуын гавамга күрсәтәчәк бит».

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 31.03.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2611

16+